Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

07
июль 2017
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

БАКЫЙ УРМАНЧЕ.«САЛТЫК БОЛЫНЫ»

ИЗГЕ АЙ ИФТАРЫ

15 июньдә башкалабыз Казанда V Республика ифтары оештырылды. Анда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

7 (283)

июль 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

60

34 СЕБЕР КИҢЛЕКЛӘРЕ ЯДКӘРЛӘРЕ.
Фәнзилә Җәүһәрова, Гафур Сөнгатов

114 «ТАТАРНЫҢ ТЕЛЕ ОЗЫН...»

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Аяз Гыйләҗев*

4 **Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында»гы законы**

ТАРИХИ МИРАС

8 **XIX гасыр-XX йөз башында керәшен татары гаиләсе.** *Р.Исхаков*
14 **Керәшеннәрнең Корман бәйрәме.** *П.Знаменский*
18 **Бердәнбер изге керәшен.** *В.Кузнецов*
22 **Арыслан батыр.** *К.Акъегет*
27 **Революция елында Казан Сабан туе.** *Л.Гобәйдуллин*
32 **Мастякның асыл улы — Сәгыйть Сүнчәләй**
34 **Себер киңлекләре ядкәрләре.** *Ф.Җәүһәрова, Г.Сөнгатов*
40 **Куркыныч һәм хәвефле еллар.** *И.Таһиров*
43 **Олуг мирас эзеннән.** *Т.Гыйләҗев*

МӨҺАҖИРЛӘР МИРАСЫ

44 **Татарларны үтерү вә мөселманнарны бетерү сәясәте тарихы.** *Л.Сәлим*

ТАТАР ГАМЕ

48 **Ярату һәм тугрылык.** *Ә.Закирҗанов*
54 **Шыгырдан төене.** *Ф.Кутлу*
58 **Полковник, язучы, сынчы.** *Л.Лерон*

ДИНИ МИРАС

60 **Ислам дөньясы.** *Г.Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

64 **Кутадгу билик. (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

70 **Фәтхи Бурнаш**

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

74 **Татар хәрби разведчиклары.** *Р.Зарипов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ХӘТЕР САНДЫГЫ

82 **Утлы кисәү.** *Л.Гыйльфанов*

СӘНГАТИ МИРАС

88 **Киленнәрдән килгән гөсләләр.** *Э.Каюмова*
90 **Бар дөньяга гашыйк җырчы.** *А.Хәкимова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

94 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
96 **Сүз турында бер-ике сүз.** *Г.Бәширов*

ХӘТЕР САГЫНДА

98 **Яшә, авыл, мең яшә!**
102 **Тарих хәтере – мәңгелек.** *Г.Мостафина*
105 **«Архив эшен яңа югарылыкка күтәрергә кирәк».** *Ирада Әюпова белән Ләбиб Лерон әңгәмәсе*
108 **Ядкәрләргә – бер гасыр**
110 **Кала тау**

100 ЕЛ ЭЛЕК...

112 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның июль ае.**
114 **«Безнең мирас» хәбәрләре**

ШАЯН МИРАС

116 **«Татарның теле озын...»**
118 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Июль*
119 **Мирасворд**

Заказ №А-1513. Тираж – 2003 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 26.07.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Ул хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61
телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Салтык болыны». 1979 ел. Киндер, майлы буяу. *Б.Урманче.*



АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

(17.01.1928 – 13.03.2002)

***

Ике башыннан да яна торган шәм мин.

***

Милли каршылыклар – тарих төбенә салып калдырылган усал миналар алар, көне-сәгате җиткәч ярылалар да, дөньяга корбаннар бүләк итеп, каршылык дулкыннарын һаман көйрәтәләр.

***

Кыйнаганда барабан гына үз тавышы белән кычкыра.

***

Татарда сөенеч тә, кайгы-хәсрәт белән авыр шик-шөбһә дә өйгә сыймый, борынгы болгар бабайлар, кара кайгы иңгәндә яки салават күпередәй балкып куаныч килгәндә, дөньяга яңа җан иясе бәбәй тугланда, тирмәдән чыкканнар да, иярсез атка сикереп менеп, җайдак җилдергәннәр, киң Идел ярына басып җырлаганнар, җир селкетеп тыпыр-тыпыр биегәннәр, һич югында, кайгыдан бал эчкәннәр.

***

Үзенең бәхетле булуын күрмәгән кеше бигрәк бәхетсез.

***

Агач череп беткән икән, аның тамырына су сибүдән ни файда?

***

Өскә төкерсәң, мыекка эләгә,
Аска төкерсәң, сакалга эләгә.

***

Тозсызны күзсез дә күрә.

***

Көймәләрнең генә дәрьяда эзе калмый.

*Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 маенда
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектларын (алга таба – матди булмаган мәдәни мирас объектлары) ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) матди булмаган мәдәни мирас – этник, социаль яисә конфессиональ төркемгә хас булган, җәмгыятьнең мәдәни һәм милли үзенчәлегендә чагыла торган һәм, тарихи барлыкка килгән сюжетларда, образларда, аларны гәүдәләндерү стилистикасында гамәлгә ашырыла торган, телне, үз-үзеңне тоту, инану нормаларын һәм кагыйдәләрен, йолаларны, гореф-гадәтләрне, бәйрәмнәрне, фольклорны, халык декоратив-гамәли сәнгать предметлары, музыка кораллары, көнкүреш әйберләре әзерләү технологияләрен һәм халык сәнгать кануннарын кертеп, Татарстан Республикасында мәдәни төрлелекне ихтирам итәргә ярдәм итүче яшәү рәвешен, традицияләрне һәм аларны белдерү рәвешләрен үз эченә алган рухи, интеллектуаль һәм әхлакый-этик кыйммәтләр җыелмасы;

2) Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестры (алга таба – Реестр) – матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында белешмәләрне үз эченә алган мәгълүмат системасы, күрсәтелгән объектларны дәүләт тарафыннан исәпкә алу максатларында аларның бердәйлеге һәм чагыштыра алырлык мөмкин булуы Реестр булдыруның гомуми принциплары, аны алып бару ысуллары һәм рәвешләре хисабына тәэмин ителә.

2 статья. **Матди булмаган мәдәни мирас объектлары төрләре**

1. Матди булмаган мәдәни мирас объектлары төрләре түбәндәгеләр:

1) халык белеме, инанулар, гореф-гадәтләр, традицияләр, фольклор әсәрләре, билгеле бер территориядә даими булдырыла торган йола яисә бәйрәм;

2) башкару сәнгатенең, шул исәптән сүз, вокаль, инструменталь, бию сәнгатенең уникаль рәвешләре;

3) халык декоратив-гамәли сәнгать предметлары, музыка кораллары, көнкүреш әйберләре әзерләү технологияләре;

4) тарихи барлыкка килгән сюжетларда, образларда һәм аларны гәүдәләндерү стилистикасында гамәлгә ашырыла торган конкрет территориядәге халык сәнгать кануннары.

2. Матди булмаган мәдәни мирас объектлары төрләренә, әлеге статьяның 1 өлешендә санап кителгәннәрдән тыш, матди булмаган мәдәни мирас объектларының аларны Реестрга кертү өчен матди булмаган мәдәни мирас объектлары туры килергә тиеш булган, әлеге Законның 6 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән критерийларга җавап бирә торган башка төрләре дә кертелергә мөмкин.

3 статья. **Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасының хәзерге һәм киләчәк буыннары мәнфәгатьләрендә матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклауга, саклап калуга, өйрәнүгә, алардан файдалануга һәм аларны популярлаштыруга юнәлдерелгән сәясәт алып бара.

2. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендә норматив хокукый актлар нәшер итү;

2) Татарстан Республикасы дәүләт программаларын төзегәндә һәм раслаганда матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау мәсьәләләрен исәпкә алу;

3) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Реестр алып бару;

2) матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чараларын күрү;

3) матди булмаган мәдәни мирас объектлары торышын мониторинглау һәм тикшереп тору;

4) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Матди булмаган мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы**

1. Матди булмаган мәдәни мирас объектлары аларның юкка чыгуын, алар теркәлгән матди чыганакларның зарарлануын яисә бозылуын булдырмау максатларында, шулай ук аларны тискәре йогынтылардан яклау максатларында дәүләт саклавында булырга тиеш.

2. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) матди булмаган мәдәни мирас объектларының торышын мониторинглауны һәм тикшереп торуны;

2) матди булмаган мәдәни мирас объекты буларак кыйммәткә ия объектларны Реестр булдыру һәм алып бару юлы белән дәүләт исәбенә алуны;

3) әлеге Законның 1 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларны (алга таба – матди булмаган мәдәни

мирас объекты билгеләренә ия объектлар) ачыклауга, аларның көнкүрештә куллану рәвешләрен карауга һәм торышын бәяләүгә юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр оештыруны;

4) матди булмаган мәдәни мирас өлкәсендә дәүләт экспертизасы үткәрүне.

5 статья. **Реестр**

1. Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объекты буларак кыйммәткә ия объектларны дәүләт исәбенә алу, аларны саклап калу, өйрәнү һәм популярлаштыру максатларында Реестр төзелә һәм алып барыла. Реестр турында нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2. Реестрдагы белешмәләр башка мәгълүмат системаларын яисә әлеге мәгълүматтан файдалана торган (исәпкә ала торган) белешмәләр банкын булдырганда һәм алып барганда матди булмаган мәдәни мирас объектлары, мәдәни булмаган мирас объектларын көнкүрештә куллану һәм саклау алымнары (рәвешләре), шулай ук күрсәтелгән объектларга бәйле матди предметларны саклау урыннары турында мәгълүматның төп чыганаклары булып тора.

3. Реестрдагы белешмәләр ачык, гомуми файдалана алырлык була һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

4. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларны Реестрга кертү турында карар Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан кабул ителә.

5. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны Реестрга кертү турында гариза Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органына матди булмаган мәдәни мирасны саклау һәм популярлаштыру белән кызыксынган зат тарафыннан бирелергә мөмкин. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны Реестрга кертү яисә кертүдән баш тарту турында карар гариза Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органында теркәлгән көннән алып иң күбе бер ел эчендә кабул ителә.

6. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны Реестрга кертү турындагы гаризада күрсәтелгән объектның исеме, матди булмаган мәдәни мирас объекты буларак аңа характеристика, шулай ук Реестрга кертү зарурлыгын нигезләү күрсәтелгән булырга тиеш.

7. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларга карата матди булмаган мәдәни мирас объектын Реестрга кертүне (кертүдән баш тартуны) нигезләү максатында дәүләт экспертизасы үткәрелә.

8. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларга дәүләт экспертизасы үткәрү тәртибе, экспертлар буларак җәлеп ителергә мөмкин булган физик һәм юридик затларны билгеләүгә таләпләр, әлеге экспертиза кысаларында тикшеренүләр үткәрү тәртибе, шулай ук дәүләт экспертизасына түләү күләмен билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

9. Күрсәтелгән объектның әлеге Законның 6 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән критерийларга туры килмәве турында дәүләт экспертизасы бәяләмәсе матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны Реестрга кертүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан карар кабул итү өчен нигез булып тора.

10. Гражданнар Реестрдагы белешмәләр чикләрендә матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында мәгълүматны тоткарлыксыз алу хокукына ия.

6 статья. **Матди булмаган мәдәни мирас объектларын Реестрга кертү өчен сайлап алу критерийлары**

1. Матди булмаган мәдәни мирас объектлары аларны Реестрга кертү өчен түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

1) тарихи һәм мәдәни әһәмиятлелеге;

2) этник, социаль яисә конфессиональ төркемнең мәдәни традициясендә яисә мәдәният тарихында ныклап урнашу дәрәҗәсе;

3) мәдәни традициянең уникаль дәлиле буларак кыйммәте;

4) юкка чыгу куркынычы.

2. Матди булмаган мәдәни мирас объекты, әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән барлык критерийларга җавап бирсә, Реестрга кертелергә мөмкин.

7 статья. **Матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклап калу, өйрәнү, популярлаштыру һәм алардан файдалану**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклап калу, өйрәнү, популярлаштыру һәм алардан файдалану эшчәнлеген тәэмин итә һәм җайга сала.

2. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклап калу матди булмаган мәдәни мирас объектларының оригинал рәвештә яшәешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә ала.

3. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын өйрәнү фәнни, техник һәм сәнгати тикшеренүләр оештыру, матди булмаган мәдәни мирас объектларын нәтиҗәле саклау максатыннан фәнни-тикшеренү методологияләрен эшләү ярдәмендә, шулай ук федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка алымнар белән гамәлгә ашырыла.

4. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын популярлаштыру һәм алардан файдалану җәмәгать чаралары үткәреп, шул исәптән мәдәни алмашу буенча, шулай ук мирас өлешләрен аларның ияләреннән яшь буынга тапшыру өчен шартлар тудыру һәм фәнни, фәнни-популяр һәм уку-укыту эшләрен нәшер итү юлы белән тәэмин ителә.

5. Физик һәм юридик затлар Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклауда, саклап калуда, популярлаштыруда һәм алардан файдалануда ярдәм күрсәтергә хокуклы.

8 статья. **Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чараларын финанслау**

Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, шулай ук федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка чыганаклардан гамәлгә ашырыла.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты **Р.Н. Миңнеханов**
Казан, Кремль
20017 ел, 26 май
№ 34-ТРЗ

Безнең мирас №7 июль 2017

XIX гасыр-XX йөз башында керәшен татары гаиләсе

Радик Исхаков

Керәшен гаиләсе – җәмгыятьнең борынгы йола, гореф-гадәт һәм традицияләрне хөрмәт итеп яши торган бер кисәкчәсе. Зур гаилә берничә угыл, аларның хатыннары һәм бала-чагаларыннан тора. Гаиләнең җитәкчесе һәм йортның хуҗасы – гаиләдәге иң өлкән ир-ат.

Керәшеннәрдә ишле гаиләләрнең күп булуы йорт хуҗасының нәсел-ыруны таркатырга теләмәве һәм икътисади фактор белән аңлатыла. Аңлашыла ки, әгъзалары төрле һөнәргә ия булган зур гаиләгә авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнергә, моның өчен кирәкле корал тупларга, йортта уңай тормыш шартларын тудырырга күпкә җиңелрәк. Андый гаиләләр хәллерәк һәм хуҗалык җәһәтеннән дә куәтлерәк булган. Шулай ук ишле гаиләнең кимчелекле ягын да әйтергә кирәк: йортта яшәүчеләргә хуҗалык һәм көнкүреш мәшәкатьләре күбрәк йөкләнгән, хуҗадан кала, башка ир-атлар мөстәкыйльлекне дә югалткан. Бер түбә астында күп кеше яшәгәнлектән, көнкүреш сәбәпләре аркасында еш кына каршылык килеп чыккан, гаиләнең башка әгъзалары, шул исәптән өйләнгән угыллар да йорт хуҗасына карусыз буйсынып, аның басымы, күзәтүе астында яшәгән.

Җиткән балалары булган йорт хуҗасы гадәттә кыр эшләре белән шөгыльләнмәгән, төп игътибарны йорт-утар хуҗалыгына биргән. Үсеп килүче балаларның киләчәген кайгырту да аның өстенә йөкләнә. Нәкъ менә ул, әлбәттә, хатыны белән киңәшеп, бала һәм оныкларын башлы-күзле итүдә төп фикерне әйткән. Киленне сайлаганда аның сәламәтлеге, хуҗалык эшенә җаваплы каравы, эшкә сәләтле булуы, гаилә һәм җәмгыятьтә дәрәҗәле булуы – төп таләп. Хәлле гаилә киленне байлар арасыннан, ә ярлылар исә балаларына тиң ярны авылда яшәүчеләрнең түбән катлавыннан эзләргә мәҗбүр. Өлкән буын керәшеннәре арасында яучылар да киленне табып биргән. Әти-әниләр зур бәйрәм, ярминкә һәм базар көннәре вакытында кәләш сайлаулар үткәргән. Моннан тыш, кайбер

авылларда, булачак килен һәм кияүнең холык-фигылен тикшерү өчен гаилә советлары оештырганнар, шунда ук яучылык һәм никах мәсьәләләре дә хәл ителгән.

Киленне сайлаган вакытта аның тышкы кыяфәте бөтенләй игътибарга алынмаган диярлек, еш кына егет белән кыз арасындагы мөнәсәбәт тә инкарь ителгән. Тормыш тәҗрибәсе күпкә баерак булган ата-ана үз баласының кем белән бәхетле буласын яхшырак белә, дип саналган. Бу мәсьәләдә ата кешенең әйткән фикере бернинди бәхәскә дә урын калдырмый. Керәшеннәрнең мәгърифәтчесе Василий Тимофеевның бу турыдагы истәлеге игътибарга лаек. 1850 еллар азагында монастырьга китеп, гомерен илаһи мәхәббәткә багышларга җыенган Василий, әтисенең әмеренә буйсынып, бер чибәркәйгә өйләнергә мәҗбүр була. Авылның шактый зыялы укытучылары, дьякон һәм башка чиркәү әһелләренең дә өйләнү, башлы-күзле булу мәсьәләсен ата-аналары хәл иткән. Гомумән, керәшеннәрдә ата-ана белән килешенмәгән, аларның ризалыгыннан башка булган никах искиткеч зур гөнаһ.

Дөрес, яшь гаилә барлыкка килүне ата-ана эше генә дип санау берьяклы караш булыр иде. Күмәк бәйрәм, кич утырулар вакытында яшьләр мәсьәләне үзләре

Керәшен авылы. Казан губернасы. XX йөз башы

дә хәл итеп куйган. Керәшеннәр арасында кыз урлау бик еш булып, ата-анасы кызын сөеклесенә бирергә теләмәсә, булачак кияү, озак уйлап тормый, кәләш белән вакытын килешеп, эңгер-меңгер вакытта тиң ярын урлап качкан. Бу очракта ата-ана никахка ризалык бирергә мәҗбүр, чөнки урланган кыз егет белән якынлык кылырга өлгергәнме-юкмы, аның инде кире туган йортына әйләнеп кайтуы зур хурлык. Ярлы гаиләләрдәге егетнең кыз урлавы ата-ана белән килешеп башкарылу очраклары да булган, чөнки аларның туй, сый-кунак мәҗлесләре үткәреп торырга матди мөмкинлеге булмаган.

Егетнең үзенә ошаган кызны мәҗбүриләп урлап китү очрагы да күзәтелгән. XIX гасырда нагайбәкләрнең тормышын һәм гореф-гадәтләрен тасвирлаган Е.А.Бектеев: *«Аларда килен урлап алып кайту гадәте бар. Җиткән кыз ялгызы гына беркая да чыга алмаган, чөнки урлап китәргә уңайлы вакытны көтеп кенә торалар. Әгәр дә әти-әни шунда ук урлау очрагын белсә, кыз артыннан, аны эзләп йөгергән»*, – дип яза. Киленне мәҗбүри урлап алып кайту мәлки керәшеннәрендә дә киң таралган. Урлау гадәттә язгы һәм җәйге әйлән-бәйлән уеннары вакытында булган. Күрше-тирә авыллардан кунакка яки кич утырырга килгән кызлар да урланган, әмма мондый очрак бик аз күзәтелгән.

Гадәттә керәшен гүзәле 16-22 яшендә кияүгә чыккан, ә егет 18-22 яшьтә өйләнгән. Бу яшьне узып китеп тә кияүгә чыкмаган кызга хөрмәт булмаган, аның турында «сазаган кыз» дип әйткәннәр. Күп очракта мондыйлар физик яки психик яктан кимчелекле булган. Гомумән, керәшеннәрдә гаилә кормау илаһи тәртипне бозу – гөнаһ, гаиләсенә, туган-тумачаларына илтифатсыз мөнәсәбәт, дип саналган. Шул сәбәпле, никах яше җитү белән, балаларны тизрәк кияүгә бирергә яки өйләндерергә тырышканнар.

Кәләш кияүдән берничә яшькә кечерәк булган. Хатын олы яшьтә булган очракта, бу гаиләдә хатын-кыз булмаган һәм барлык йорт-хуҗалык эшләре дә киленгә йөкләнгән.

Никахка кадәрге җенси мөнәсәбәт кискен тәнкыйтьләнеп кенә калмаган, ә җәмгыять һәм гаилә әгъзалары тарафыннан кырыс җәзага да дучар ителә алган. Дөрес, егет язмышына бу гамәл әллә ни йогынты ясамаса да, кызлар өчен гаять куркыныч. Гыйффәтен югалткан туташ башкаларның кырын карашына, төрле мыскыллауларга дучар ителгән, тиз генә кияүгә дә чыга алмаган. Еш кына ул үз-үзенә кул салган. Никахка кадәрге җенси мөнәсәбәтнең татар халкы тарафыннан кырыс тәнкыйтьләнүе дәүләт статистикасы мәгълүматларында да чагылыш тапкан. Н.А.Бухалов тикшерүендә 1858-1891 еллар аралыгында Казан губернасында яшәүче татар һәм чуашларда никахсыз туган балаларның саны башка милләттәгеләр белән чагыштырганда шактый аз икәнлеге теркәлә. Кайбер елларда исә мондыйлар бөтенләй тумаган.

Калым киленнең гаиләсенә эшче кулны алган өчен компенсация буларак бирелгән. Нигездә ул билгеле бер суммадан һәм мал-туардан гыйбарәт. XIX гасыр дәвамы һәм XX йөз башына калымның күләме кимегән, бу авылларда кеше саны арту һәм элеккеге гаилә традицияләренең югала баруы белән аңлатыла. С.М.Матвеев күзәтүләренә караганда, XX йөз башында Минзәлә өязе керәшеннәре нибары 10-50 сум калым бирсә, күршедә генә булган бәләбәйлеләр 80 сумга кадәр түләгән.

Булачак килен бирнәне хезмәткә яраклы булгач ук әзерли башлый. Аңа кул эшләре әйберләре һәм гаилә башлыгы биргән мал-туар да кергән. Бирнә хатынның шәхси мөлкәте булып, ул аннан иренең, хәтта гаилә башлыгының да рөхсәтеннән башка файдаланырга хаклы. Килен белән килгән мал-туар да хатынның шәхси мөлкәте. Хуҗабикә вафатыннан соң гына әлеге байлык иренә яки балаларына мирас ителә. Ә инде балалар булмаган очракта, хатынның элекке гаиләсе иреннән бу мөлкәтне җәмәгать суды ярдәмендә тартып та алырга хокуклы. Әгәр дә аерылу очрагы булып, балалар төп гаиләдә калса, бирнә ир кеше милкенә күчкән, ә киресенчә булса, әлбәттә, хатын белән бергә киткән.

Керәшен гаиләсе. Мамадыш өязе, Чиябаш авылы. 1904 ел

Яшь килен иренең туган-тумачаларына да бүләксез килмәгән: ир-атларга өйдә тукылган күлмәк, кирәк-ярак өчен кечкенә капчыклар, хатын-кызларга баш киемнәре биргән.

Ир кеше хәерче гаиләдән булган очракта, аның калым һәм башка бүләкләргә акчасы булмау сәбәпле, туй уздырып мәшәкатьләнмәгәннәр. Килен дә иренең туганнарына нинди бүләк әзерлим икән дип баш ватмый: сандык төбенә вак-төяк кирәк-яракны гына сала да килә.

Чиркәүдә никахлашу мәҗбүри таләп булып, яшь парлар бер-берсенә мәхәббәтне балдак яки тәре алмашып ныгыткан. Әмма этнографик материаллар чиркәүдә никахлашуның XIX гасырның икенче яртысында, православие көчәеп, аның этик нормалары халыкка үтеп керә башлаган вакытта гына керәшен традициясенә әверелүе турында сөйли. 1879 елда студент Н.Заленцов мәлки керәшеннәре турында менә ниләр яза: *«Христиан дине буенча никах аларда сирәк. Киленне хәзер дә кияү калым түләп сатып ала, туйлар елның теләсә кайсы көнендә, хәтта пост вакытында да була. Яшьләрнең дә күбесе үзләренчә яши, әмма алар арасында чиркәүдә никах укылмаган»*. Н.Одингитриевский шундый ук күренешнең Мамадыш һәм Лаеш өязе керәшеннәрендә дә булуын яза: *«Керәшен татарлары никахка игътибар итми. Гаилә корганда алар православие чиркәве таләпләре турында аз белә»*.

Тол калган хатынга алты атнадан да иртә кияүгә чыгарга ярамаган. Бу вакыт аралыгында ул ире йортында яшәргә тиеш. Аеруча яшьләй тол калганнар кабат кияүгә чыгарга ашкынган, чөнки аңа хуҗалыкны алып барырлык, балаларына әти булырдай ир-ат кирәк. Ишле гаиләдәге тол хатынның кияүгә чыгарга теләве аның инде үзенә ят булган кешеләр арасында авыр тормышта яшәве белән аңлатыла. Мондый очракта ул гади хезмәтче дәрәҗәсендә генә калган.

Яңа ир тол хатын белән килгән балаларны уллыка һәм кызлыкка алган яки аларны кабул итмәскә дә хокуклы. Соңгы очракта ана һәм аның яңа гаиләсе элекке ирдән балаларга мирас булып калган мал-мөлкәтне дә калдырырга тиеш. Мондый очракта балалар һәм мирас малы туганнар карамагына тапшырыла. Ә якын туган булмаганда, балалар авыл җәмгате химаясендә кала, халык сабыйларны, аларның мөлкәтен кайгыртып торган кешене сайлый. Балигълык яшенә җиткәч, барлык мал-мөлкәт тә балаларга тапшырыла. Әгәр дә мөлкәт югалган яки сарыф ителеп беткән очракта, химая кылучы җавапка тартылган.

Керәшеннәр арасында катнаш никах турында да әйтми мөмкин түгел. Гадәттә, яңа чукынып, керәшен авылына

килеп урнашкан башка милләт вәкилләре үзләренең этномәдәни традицияләрен югалткан. Кире күренеш тә күзәтелгән: яңа җирләргә күченгән керәшеннәр, татар булмаган башка халыклар белән мәдәни бәйләнышка кереп, җирле халык белән туганлашкан, үз гореф-гадәтләрен, телне оныткан. Мәлки керәшеннәре, чуашлар белән күрше яшәү сәбәпле, алар белән туганлашкан. Бу күренеш мәлкиеләрнең телендә, матди һәм рухи мәдәниятендә сизелерлек эз калдыра. Ә алардан туган балалар үзләрен керәшен дип санаган, татарча сөйләшкән.

Урыслар һәм керәшеннәр бергә яшәгән авылларда катнаш никах бик аз санда һәм гадәттән тыш очракта гына булган. Дин уртак булса да, тел, гореф-гадәт, гомумән, менталитет башка булу урыс белән бер ятакка ятуны чикләгән.

Яңа кияүгә чыккан, әмма гаиләнең тулы хокуклы әгъзасына әверелеп китә алмаган яшь киленнең хәле аеруча мөшкел. XX гасыр башына кадәр диярлек керәшеннәрдә шундый гадәт саклана: кыз килен булып төшкәч тә өлкәннәр, аеруча каенатасы белән сөйләшергә хокуксыз. «Тел яшерү» каената сөйләшергә рөхсәт биргәнчегә кадәр дәвам итеп, бу бер йола рәвешен алган. Каенатасының нинди дә булса бәйрәм вакытында кунаклар каршында әлеге табуны бетерергә теләвен белгән яшь килен йорт хуҗасына стакан белән балдан ясалган алкогольле эчемлек китерә. Шулвакыт каенатасы: «Нәрсә бирә ул?» – дип сорый. Җавапны ишеткәннән соң, стаканга көмеш акча сала һәм кире бирә. Килен, эчемлекне эчеп, тәңкәне алганнан соң, яңадан эчемлек салып бирә, монысын инде каената үзе эчә. Шуннан соң гына хатын гаиләнең барлык әгъзалары белән дә сөйләшү хокукына ия. Нагайбәкләрдә дә шуңа охшаш йола бар: киленгә тәңкә биргәндә: «Алтынмы әллә көмешме?» – дип сорыйлар. Сорауга җавап биргәннән соң «тел яшерү» бетерелә.

1921 елда, гадәт буенча килгән хокукны өйрәнгән вакытта, Казан керәшен педагогик курсларында укучылар тарафыннан: *«Ир – хатынның хуҗасы, аның хакимияте бик зур һәм чикләнмәгән»*, – дигән нәтиҗәгә килена. Никах хатынның яңа хуҗага буйсынуын символлаштырган. Кияүгә чыгар алдыннан булачак килен һәм аның дус кызлары моңлы җырлар җырлаган, кызлык хөрлеген югалтканга елашкан. Ир хатынының әхлагы, гамәлләре өчен гаилә һәм җәмгыять алдында җаваплы. Кайбер очракта хатынның тәртипсез эшләре өчен ире җәзага тартылган. Ирнең дә үз хатынын кырын гамәл кылган өчен җәзалавы бер дә гаеп дип саналмаган, авыл халкының да мондый гаилә эшләренә тыкшынырга хокукы юк. Ирне әлеге кырыс адымнан фәкать гаилә башлыгы гына тыярга мөмкин. Әгәр дә хатын иреннән китеп барса, ул аның кире кайтуын үтенә алган, әмма хатынның иргә карата мондый хокукы юк.

Хатыннарга чит ир-атлар каршына башны капламый һәм аяк киемен кими чыгу рөхсәт ителми. Нагайбәкләрдә исә яшь килен берникадәр вакыт йорттагы бар кешенең дә аяк киемен кидерергә һәм салдырырга тиеш.

Табын артына гаилә башлыгы утырганнан соң гына ашарга рөхсәт. Икмәк һәм итне дә хуҗа кеше генә бүлгән. Иң зур һәм яхшы кисәкне өлкән угыллар ашаган. Кош итен бүлгәндә иң тәмле кисәк белән баш өлеш – йорт хуҗасына, ә арткы кисәк хатын-кызларга бирелгән. Моны керәшеннәр: *«Өйдә утырган кешегә арты да ярар»*, – дип аңлаткан.

Этнографлар керәшен гаиләсендә хатын-кызларның социаль һәм хуҗалык эшләрен хәл иткәндә шактый ирекле эш итүе турында яза. Аеруча йорт хуҗасы хатынының гаиләгә йогынтысы зур. Ул йорт эшләре, башка хатын-кызлар һәм балигъ булмаган балалар белән идарә итеп, ире вафатыннан соң да гаилә эшендә мөһим рольне саклап кала. Тол калган ана тирә-яктагыларның игътибары һәм хөрмәтенә лаек, аның сүзен һәркем, шул исәптән гаилә башлыгы булып калган улы да тыңларга мәҗбүр.

Аерылышу процессы чиркәү кагыйдәләре буенча, җитәрлек мотив булганда гына башкарылырга тиеш. Аерылган

хатын элекке гаиләсенә күченә. Ул үзе белән фәкать бирнә һәм башка шәхси әйберләрен генә алып китә. Сабыйлар ир кешенең гаиләсендә кала, кайбер очракта гына, аерылган иренең рөхсәте белән, хатын күкрәк баласын һәм кызларын алып китә алган. Улларны алып китә алмавы, аларга имана җир беркетелү белән аңлатыла булса кирәк. Керәшеннәрдә аерылышу бик сирәк очракта гына күзәтелгән, гадәттә, гаилә эчендә булган конфликтны тышка чыгармаска тырышканнар.

Керәшеннәрдә ата кеше балаларына гаять кырыс һәм таләпчән. Ул балаларны азыктан мәхрүм итә һәм аларга тән җәзасы бирә алган. Кырыс тәрбия һәм дисциплина җәмгыятькә лаеклы алмаш әзерләгәндә иң дөрес ысул, дип саналган. Балаларга әти кешенең йомшаклыгы хупланмаган – мондый мөнәсәбәт кире нәтиҗәгә китергән, бала иркә, ваемсыз һәм ялкау булып үскән.

Керәшен үз балаларын кечкенәдән үк хезмәт белән тәрбияли. Җиде яшьлек бала әти-әнисе белән урып-җыю эшләрендә катнаша, мал-туар карый һәм хуҗалык хезмәтен башкара, 12-13 яшендә исә җир тырмалый, көтү көтә, ә инде 14 тулгач, сука белән кырга чыга һәм иген чәчә. Кызлар исә, кул эшләренә өйрәнеп, бирнә әзерләгән.

Кыр эшләрендә вакыт үткәргән әтиәнинең сабыйларны тәрбияләргә әллә ни вакыты да калмаган, аеруча кечкенә гаиләләрдә хәл мөшкел. Цивиль өязенең Иске Корбаш авылында туган П.Томлеев яшьлек еллары турында менә ниләр яза: *«Эш вакытында балаларның үзләрен генә калдыралар. Кайберләренең күлмәкләре җыртылган, алар урам буенча мүкәләп йөри. Сабыйлар турында уйлаган кеше дә юк. Кич белән эштән кайткан әти-әни балаларның кайдадыр комлыкта йоклап ятканын яки уйнап утырганын күрә»*. Шулай итеп, сабыйлар күп вакытны урамда, башка балалар белән уйнап уздырган, әти-әниләре кушкан вак-төяк йомышны да үтәгән.

XIX гасырның икенче яртысыннан балалар тәрбиясе белән православие мәктәбе шөгыльләнә башлый. Миссионерларның тырышлыгы белән Казан, Вятка, Оренбург һәм Уфа губерналарындагы керәшен авылларында татар телендә белем бирә торган башлангыч мәктәпләр барлыкка килә. Анда укучылар Н.И.Ильминский системасы нигезендә укырга-язарга өйрәнеп, христиан рухында тәрбияләнә.

Керәшеннәрнең кунакчыллыгы турында аерым әйтергә кирәк. Гаиләнең матди хәле нинди булуга карамастан, теләсә нинди кунакны табынга чакырганнар. Йорт бусагасын атлап кергән кеше тәкъдимне кире кага алмый, югыйсә, бу нәсел-ыруны хурлау саналган. Табын артына утырырга теләмәсә, аны мәҗбүриләгәннәр, хәтта физик көч тә кулланганнар. Керәшен һәркемгә, хәтта үзара мөнәсәбәт начар, күпмедер дәрәҗәдә дошманы булган кешегә дә кунакчыллык күрсәткән. Бәйрәмнәр вакытында исә, табынга туган-тумача, дусиш, күрше-тирә һәм башка авылдашлар, хәтта якын авыллардан да кешеләр, шул исәптән мөселман татарлар һәм урыслар да чакырылган.

Чыганаклар:

1. Одигитриевский Н. Крещеные татары Казанской губернии. – М., 1895.
2. Ответы на анкету о семейных отношениях и обычном праве у кряшен (1921 г.) // Научный архив Чувашского государственного института гуманитарных наук (НА ЧГИГН). Отд.I. Фонд Н.В.Никольского. Д.305. Л.286.
3. Серебряков Н.А. Сочинение о семейных отношениях кряшен (дер. Кибечи Лаишевского кантона ТАССР) (1921 г.) // НА ЧГИГН. Отд.I. Фонд Н.В.Никольского. Д.314. Л.184.
4. Калмыков А. Ответы на анкету о семейных отношениях и обычном праве (с. Албаево Мамадышского кантона ТАССР) (1921 г.) // НА ЧГИГН. Отд.I. Фонд Н.В.Никольского. Д.310. Л.21.
5. Бектеева Е.А. Нагайбаки (крещеные татары Оренбургской губернии). (1895 г.) // Научный архив Русского географического общества (НА РГО). Разряд 26. Оп.1. Д.24. Л.8.
6. Осипова Л. Моя деревня (с. Молькеево Цивильского уезда ЧАО). (13 июня 1921 г.) // НА ЧГИГН. Отд.I. Фонд Н.В.Никольского. Д.309. Л.97.
7. Бабушкин И.Д. Казан губернасы Лаеш өязе Алан-Полянка авылының өйләнү йолалары турында язмасы (1921 ел) // ЧДГФИ МА. 1 бүлек. Н.В.Никольский фонды. 311 сак. бер. 155б. ■

Безнең мирас №7 июль 2017

КЕРӘШЕННӘРНЕҢ КОРМАН БӘЙРӘМЕ[1]

Петр Знаменский

(Православие миссионеры П.В.Знаменскийның Казан губернасы Мамадыш өязе Олы һәм Түбән Әрнәш авылы кешеләрендә сакланган йолалар һәм дини карашлар турында этнографик язмаларыннан. 1868 ел[2])

Карагруһчы урыс милләтчеләреннән торган «Урыс җыены» оешмасының Казан бүлекчәсе рәисе урынбасары, Урыс чиркәве тарихчысы Пётр Васильевич Знаменскийның (1836-1917) этнографик язмасында хәзерге Мамадыш районы Албай авылында яшәүче керәшен татарларның борынгы, гомумтөрки дини традицияләре – Күк Тәңре һәм агач культы белән бәйле «корман», ягъни корбан бәйрәме тасвирлана. 1868 елда миссионерның көндәлекләреннән кыскартып, Халык мәгарифе министрлыгы журналында басылган әлеге мәкаләне урыс теленнән тәрҗемә кылып[3], сезнең хозурга да тәкъдим итәбез.

Әрнәш авылы кешеләре чиркәү бәйрәмнәрен бик олылап бетерми, аларның борынгыдан калган үз бәйрәмнәре, мәҗүси-шаманлык заманыннан сакланган үзләренә башка дини гореф-гадәтләре бар. Болар – «чук» һәм «корман» йолалары. Алар белән бик җентекләп таныша алмасак та, байтак кына күрдек һәм ишеттек, шуларны сезгә дә җиткерәбез.

16 нчы июльдә Әрнәшкә килгәч, кич белән бер керәшен йортында безгә урман караучы урыс белән очрашырга туры килде. Сүз арасында ул безгә Әрнәш кешеләренең «изге имән»нәре, «изге чишмә»ләре барлыгын сөйләде. Шуның янында алар корман уздыралар, мал-туар иминлеген, бал кортлары үрчемле, иген уңышлы булуны үтенеп, имәнгә келәү итәләр. Шунлыктан имән «изге» санала, имәнне кискән яисә аның янында әдәпсезлек кылган кешенең аяк-кулы корый, гарип кала, дип ышаналар. Урман караучы йоланың башка вак-төяген җентекләп сөйли алмады, ул «чук»ка үзе дә әһәмият бирмәгән. Корман йоласына инде соңга калсак та (ул без килгән көнне уздырылган), «изге имән»не барып күрергә булдык.

20 июльдә, Илья пәйгамбәргә багышланган көнне (Элҗен) ниятебезне башкару өчен бик уңай шартлар да булды. Кичке сәгать алтыларда озата йөрергә укучы малайны алып, урманга киттек. Берәр чакрым ара узгач, без уртасыннан таулы яр чишмәләре суы җыелып аккан елгага төштек. Елганың икенче як ярында имәннәр үскән куе кара урманлык белән капланган таулык башлана. Тау итәгеннән елгага сузылган сөзәклектә урыны белән вак үлән үскән тигез мәйданчыклар күренә. Шул мәйданчыкларның берсендә без казыкларга беркетеп куелган ике ятма колга агачы күреп алдык. Шуларның берсендә корманга чалынган хайван туналганлыгы беленеп торса, икенчесенең астындагы көл бу урында әле күптән түгел генә нәрсәдер пешерелгәнен күрсәтеп тора иде.

Мәйданчыктан тауга менгән сукмак безне ике колачтан юанрак, җирдән өч сажин[4] биеклеккә кадәр ботаксыз, дәһшәтле зур имән агачы янына алып чыкты. Имәннең кәүсәсе, бер сажин биеклектән башлап, бер чирек киңлекле, дүрт аршын озынлыктагы имән кабыклары белән уратылган. Рәткә тезеп беркетелгән шундый кабыкларның санын без унга якын исәпләдек. Аларның берсе әле яңа, башкалары инде тузып, йомычкаланып теленеп беткән. Яңа кабык өстендә без хайван каны һәм төрле рәвештәге тамга сурәтләре күрдек.

«Изге имән»нән уңда, ике каен арасында, аршын ярым озынлыкта һәм ярты аршын киңлектә булган унга якын дүртпочмаклы имән тартмалар бар. Аларның берсе яңа, башкалары инде туз-

---

[1] Корбанны керәшен татарлары «корман» дип әйтәләр.

[2] О крещеных татарах дер. Большой Арняш (Извлечение из дневника) // Журнал Министерства народного просвещения. – 1868. – Ч.137. – №3. – С.360-364.

[3] Тексттагы кайбер сүзләрне керәшенчә калдырырга булдык: «корман», «бутка», «семья» һ.б.

[4] Бер сажин – 2 метр да 16 см озынлык.

ган, кайберләре череп таралып та беткән. Имәннән сулда – өсләренә такта яисә кабык куюу белән өстәл булачак озын ятма колгалар белән тоташтырылган дүрт казык тора. Корман уздыру урынының җиһазы шул.

Йола турында төрле кешеләрдән, күбесенчә укучы малайлардан менә нәрсәләр ишеттек. «Чук»тан бер көн алдан катнашырга теләүче семьялар «чук»ка ничә хайван чалырга һәм һәр семьядан тагын күпме нәрсәләр тиешлеген килешеп куялар. «Чук» көнне сайлап алынган картлар һәм карчыклар корманга лаеклы хайваннарны – өчәр баш сарык яисә бер яшь үгез бозауны алып, имән янына баралар. Без әйтеп үткән мәйданчыкта ятма колгалар корып ике-өч зур казан асалар. Шуннан соң картларның берсе, су буена төшеп, әзерләп куелган озын имән кабыгы өстенә салып, каннары кабыкны килкенли буярлык итеп хайваннарны чала. Бу эшне бышкарып бетергәч, ул канга буялган имән кабыгын «изге имән» янына алып килә дә, кабыкның канлы ягын агачның кәүсәсенә каратып уратып чолгап ала. Бу вакытта аның им сүзләре әйтү-әйтмәве безгә билгеле түгел. Туралган итне карчыклар казаннарга салып пешерәләр. Ит пешкәч, шул ук казаннарга алып килгән ярма, тоз салып, бутка пешерәләр. Корман ризыгы хәстәрләп әзерләнгәч, авылга «чук»ка җыелырга хәбәр бирәләр. Халык җыелган арада картлар, карчыклар бутканы табакларга, ә итне кабыктан ясалган кызау – тубал әрҗәләргә салалар да зур тантана белән мәйданчыктан имән янына алып киләләр. Табакларны корылган өстәл өстенә тезеп куялар. Барысы да имән янына җыелгач, өч карт бабай, өстенә ит һәм йомырка калҗасы салынган буткалы табак тотып, имәнгә карап башыра-башыра[5], табак тоткан кулларын бер күтәреп, бер төшереп келәү итә башлыйлар. Гыйбадәттә нинди сүзләр әйтелгәне билгеле түгел. Чирек сәгатьтән артык барган келәү вакытында барысы да тын тора. Келәү беткәч, чалучы, бутка белән ит алып, елга буена төшә, ризыкның беразын суга сала. Башкалар үз теләкләре белән елга суына ярма, тоз, кайберләре вак акча сала. Шуннан соң һәр семья, үз өлешен алып, мәйданчыкта ашарга утыра. «Чук» шуның белән бетә.

«Чук» уздыруда чалучының эше бик әһәмиятле. «Чук»ка корбан хайваннары сайлап алу һәм канга буялган кабыкны «изге имән»гә чорнау аңар йөкләнә, шунда ул безгә билгеле булмаган им сүзләре әйтә. Бу эшләрне ул гомере буе берүзе башкара, үлгәндә үзенең «осталыгын» олы улына мирас итә яисә, ир балалары булмаса, якын ир туганына яки үзенең ышанычлы танышына тапшыра. Әрнәштә «чук» ел саен уздырыла (июль ае урталарында атна көн – якшәмбе яки бәйрәм көнгә туры китерелеп). «Изге имән» ел саен канланган кабык белән чолгана, агач янында яңа кабык тубал әрҗәләр куела. Шул чолгаулар, әрҗәләр елдан-ел череми сакланып килсә, аларга карап «чук»ның кайсы заманнардан гадәткә кергәнлеген, ә кабыкка сызылган тамгалардан «чук»та кайсы семьялар катнашканлыгын белеп булыр иде. Инде Әрнәш кешеләре «чук»ка салкын карый башлаган: узган ел бу әмәлләрдә авыл халкының өчтән бере генә катнашкан. Тимофей Иванов һәм аның ишеләр бу гадәтне начар дип саныйлар, укучы малайлар да бу чаралардан читләшә.

Олы Әрнәш белән янәшәдәге керәшен авылында «чук»ның ничек уздырылуын да әйтеп үтәргә кирәк. Авыл – «Түбән Әрнәш» яки «Җылы Сазлык» атамалы. Ул Олы Әрнәштән бер чакрымда, калкулыклар арасындагы түбән урында урнашкан, исеме дә шуннан чыгып кушылган. Авыллары янында зур урман булуга карамастан, аларның «чук» урыннары Олы Әрнәш урманында, алар анда Олы Әрнәш аркылы йөри. «Чук» урыны Олы Әрнәшкә якын, элек урман булган ышна басуында, кыр түрендә кал-

[5] Башыра – баш ора.

ган бик зур агач төбе янында урнашкан. Агач төбе инде бик иске, тузган, череп таркала башлаган, үзәге янып, куышланып беткән, кул яссымы киңлектә кырыйлары гына калган. Төпне уратып имән кабыгы эленгән булган, аның канга буялган булуы да мөмкин, ләкин ул инде бик иске, тузган. Түбән Әрнәш картлары, төп янына җыелып, көньяк-көнбатышка карап[6] келәү итәләр. Төпкә акча, ярма, тоз һәм башка нәрсәләр куялар. Келәү беткәч, өлеш тарату, сыйлану башлана. Бу урында озак тормыйча таралышалар, өйләренә кайтып «чук»ны бәйрәм итәләр. Бәйрәм Троица көненнән соң, сөйләүләренчә, Олы Әрнәштән дә зуррак итеп уздырыла, башка авыл кешеләре дә җыела, мөселман татарлар да килә. Бу «чук» турында шундый риваять бар: *«Элек заманда берничә кеше шушы имәндә бал кортлары умартасы тапкан, балыннан хәмер (бал балы) ясап эчкәннәр, имеш. Шуннан соң ел саен бу урында имәнгә, аннан соң имән төбенә, бал кортларын үрчетүне үтенеп, келәү итеп «чук» уздыра башлаганнар. Байтак вакыт узгач, Олы Әрнәшнең бер керәшене агачны кискән, имеш, шуның белән Түбән Әрнәш кешеләренә зур борчу китергән. Соңыннан шул ук кеше агачның төбен дә яндырган. Шуннан соң яртылаш юләрләнгән»*. Без бу керәшенне күрдек, акылы зәгыйфьлеген сизмәдек, уйлары, сүзләре бик урынлы. Әйтүләренчә, аның акыл җитешмәве вакыты белән генә булгалый. Ул төрле юк-бар сүзләр сөйли башлый, имеш.

Олы Әрнәштә ел саен июльнең соңгы көннәрендә «корман» ясау йоласы да бар. Ул урманда түгел, авыл читендәге елга буенда уздырыла. Корманга әзерлек берике көн алдан, көрән төстәге печелмәгән үгез бозау сайлап алудан башлана. Аны җыелган акчага сатып алалар. «Корман» көнне сайланган картлар, карчыклар тиешле урынга баралар, картларның берсе («чук» чалучысы түгел) чалучы һәм бутка пешерүчеләрнең олысы була, башкалар аңа булышалар. Тагын берсе халыктан буткага кирәк кадәр ярма, тоз җыя. Узган җәйдә «корман» июльнең 30 нчы көненә билгеләнгән булган, сайлап алынган корман үгезләре качкан, шунлыктан корманны икенче көнгә – чиркәүнең Успенье көненә күчергәннәр.

Бу көндә халыкның күбесе эштә булганлыктан, картлар корманга әзерлекне соңлабрак, иртәнге сәгатъ алтылардан соң гына башладылар. Ит һәм бутка пешерелгәннән соң, бутканы ике рәт итеп җиргә тезеп куелган табакларга бүлеп салалар, ваклап туралган итне тигез итеп табакларга бутка өстенә куялар. Кояш баеганда, эштән кайткан авыл халкы әкренләп җыела башлады, бу бик күңелле күренеш иде. Барысы да шат йөз белән «корман»га сый мәҗлесенә барган кебек киләләр, ирләр табаклар куелган рәттән – бер якта, хатын-кызлар төрле чуар тукыма, милли киемнәрдән – икенче якта. Алар арасында күңелле әңгәмә бара. Янәшәдә, тау битендә яшүсмер егетләр җыелышып утырган, бераз арырак, тау итәгендә матур киемнәр кигән кызлар төркеме. Алар арасында бала-чагалар чабышып уйнап йөри. Көндезге эшләрдән соң, кичке аш алдыннан барысының да йөзләрендә сөенү, шатлык балкый. Менә ике бутка пешерүче, берәр табак ашамлык алып, якындагы йортка, тәреләр каршында келәү итәргә китә. Аннан тиз генә килгәч, тезелгән табаклар алдына басып, тагын келәү итәләр. Шуннан соң һәр семья үз өлешен алып, аланда ашарга утырды. Анда 300ләп кеше бар иде. Зәңгәр күк астындагы шундый искиткеч матур туган-ыру бәйрәмен күз алдыгызга китереп карагыз! Бәйрәм төн урталарына кадәр сузылды. Әрнәшләрнең бу йолалары бик борынгыдан килә, ел саен уздырылып бара.

Текстны басмага ***Радик Исхаков*** *һәм* ***Николай Петров-Текин*** *әзерләде.* ■

[6] Кыйбла якка карап.

Бердәнбер изге керәшен

(Священник Пётр Гавриловның тормыш юлы турында кайбер мәгълүматлар)

Владимир Кузнецов[1]

Пётр Гаврилович Гаврилов 1870 елны элеккеге Казан губернасы Мамадыш өязенә караган Лыя-Шыя (Уткино) авылында «иске чукынган татар» крестьяны гаиләсендә туа. Аның балачагы турындагы мәгълүмат сакланмаган. Пётр Гаврилович 1888 елда Казан үзәк керәшен мәктәбенең укытучылар әзерли торган беренче баскычын тәмамлый. Бу мәктәпнең икенче баскычында укуы турында мәгълүмат сакланмаган. 1895 елны аңа чиркәү иерархиясенең түбән иерей дәрәҗәсе бирелә.

Пётр Гаврилов 1903 елны миссионер курсларында укый башлап, 1905 елның августында бу курсларны тәмамлаганнан соң, юллама буенча Вятка губернасының Алабуга өязенә кергән Кырынды авылы чиркәвенә эшкә билгеләнә. 1909 елны шул ук өязнең Татар Чаллысы авылына күчерелә һәм анда 1919 елга кадәр эшли.

Соңрак ул Колчак гаскәрләре белән Көнбатыш Себергә киткән булырга тиеш. 1919 елның июлендә Томск епархиясенең Барнаул округына караган Тальмен чиркәвенә эшкә билгеләнә. Монда ул кулга алынганчы, 1929 елга кадәр хезмәт итә. Эшенә чын күңелдән бирелгәнлеге, җаваплы караганы, тырыш хезмәте өчен аңа протерий саны бирелә. Пётр Гавриловның алган хөкүмәт бүләкләре турында мәгълүмат юк. Шулай ук февраль-октябрь вакыйгалары, гражданнар сугышы һәм большевиклар сәясәтенә карата мөнәсәбәте дә билгесез.

Тарихтан белүебезчә, октябрь түнтәрешеннән соң хакимияткә килгән большевиклар партиясе, дин – халык өчен агу, ә дин әһелләрен агу таратучылар, дип саный. Дин әһелләрен эзәрлекләү сәясәте, узган гасырның 20 нче еллар башыннан 30 нчы еллар уртасына кадәр киң колач ала. Совет хакимиятенә каршы эш алып баруда гаепләнгән Пётр Гаврилович 1929 елны Томск өлкәсенең Нарым төбәгенә дүрт елга сөргенгә җибәрелә. Әйтүе буенча, аның белән бергә тагын 130 дин әһеле сөргендә булган. 1933 елны сөргенлек срогын тутырып кайткан Петр Гавриловичны Алтай краендагы Бийск шәһәренең Сретень чиркәвенә протоиерей итеп билгелиләр. Сретень чиркәвендә, икенче тапкыр кулга алынганчы, 1936 елның 1 ноябренә кадәр хезмәт итә.

Пётр Гаврилов «Япония тарафыннан хәрби интервенция булганда совет властена каршы кораллы баш күтәрүне максат итеп куйган контрреволюцион буржуаз оешманың актив әгъзасы» дип гаепләнә һәм «Архиепископ Иаков Маскаев эше» буенча кулга алына. Аны Бийск шәһәре төрмәсенә ябалар, 9 айга сузылган сорау алу, яла ягу, түбәнсетү, төрле җәзалаулар башлана. Җиденче дистә белән баручы Петр Гаврилович бу түбәнсетүләргә горур түзә, үзен гаепле санамый, бер кешегә дә яла якмый. Бийск шәһәр төрмәсеннән бирелгән медсправкадан күренгәнчә, ул бик еш чирли

[1] Кузнецов Владимир Николаевич – Мамадыш районы Җөри урта гомуми белем бирү мәктәбенең тарих укытучысы, музей түгәрәге җитәкчесе.

С. С. С. Р.
НАРОДНЫЙ КОМИССАРИАТ ВНУТРЕННИХ ДЕЛ
Управление Государственной Безопасности УНКВД по Запсибкраю
(наименование органа)

ПРОТОКОЛ ДОПРОСА

1936 г. Ноября мес. 4 К ДЕЛУ № 11808
Бутинцкий
Фамилия ... дня ... Уполном. вед. спо ...

«УТВЕРЖДАЮ» Зам. Нач. УНКВД ЗСК
27 октября 1936 г.
(УСПЕНСКИЙ)

Постановление

об избрании меры пресечения и пред'явления обвинения

Город Новосибирск 1936 г. октября „27" дня

я, Опер. Уполномоченный 6 отд—ния Секретно-политич. отдела
(должность и фамилия)
БУЛИНЦКИЙ Управления Государственной Безопасности УНКВД по Запсибкраю, рассмотрев следственный материал по делу № 11808 и приняв во внимание, что гр. ГАВРИЛОВ Петр Гавриилович – священник гор. Бийска

достаточно изобличается в том, что являлся ... к-р повстанческой организации ... ние соввласти ...

Протокол обыска

1936 г. Ноября 1 дня. Я, Пом. Оперуполномоченного сержант ... Бийского РО НКВД Храмов на основании ордера ОГПУ за № 168 произвел обыск у гр. Гаврилова Петра Гавриловича проживающего в г. Бийск Андреевская № 13 кв. № ...

При производстве обыска присутствовали ... Евдокимович и ...

Согласно полученных указ...

С. С. С. Р.
НАРОДНЫЙ КОМИССАРИАТ В...
Управление Государственной Безопасн...
(наименование органа)

ПРОТОКОЛ ...

1936 г. Ноября мес. 4
Бутинцкий допрос...

Фамилия Гаврилов
Имя и отчество Петр Гав...
Дата рождения 1870
Место рождения д. Уткино Мамадышского р...
Местожительство г. Бийск. Андреевская № 13
Нац. и гражд. (подданство) русский
Паспорт (когда и каким органом выдан, категория и место приписки)
Род занятий служитель ре...
Социальное происхождение из к...
Социальное положение (род занятий) до революции Священ...
после революции Священ...
Состав семьи Одинок. ...
(близкие родств...)
несудим...

1866 ... П. Гав...

V

ВЫПИСКА из АКТА

...становление тройки УНКВД Запсибкрая от „ 25 " июля ...
... о расстреле Гаврилова
Петра Гавриловича
приведено в исполнение" 29 июля месяца
в ... часов.

Подписи: Ст. помощ. прокурора ...
Зам. нач. УНКВД по Зап. ...
Нач. 8 отдела УГБ ...

Верно: ...

Семён Гаврилов гаиләсе

һәм төрмә больницасында дәвалана. 1937 елның 25 июлендә Көнбатыш Себер крае НКВД идарәсенә караган өчлек суды Гаврилов Пётр Гавриловичны РСФСР ҖК 58 маддәсенең 10-11 пунктлары буенча гаепле таба һәм атып үтерергә, дигән карар чыгара. 1937 елның 29 июлендә Барнаул архиепископы Иаков, священник Иоанн Можирин, монах Феодор Никитин, Иоанн Протоповлар белән бергә Пётр Гаврилов та атып үтерелә һәм билгесез каберлеккә күмелә.

Рухани СССР Югары Суды Президиумының 1989 елның 16 январенда чыгарылган указы нигезендә реабилитацияләнә. Газаплап үтерелгән Пётр Гаврилович Гаврилов 2000 елның августында Рус Православие Чиркәвенең юбилее уңаеннан уздырылган Архиерей Соборында Барнаул епархиясе тәкъдиме белән изгеләштерелә – чиркәүдә олылап мәҗбүри табынуга тиешле әүлияләр исемлегенә, дин өчен газап чиккән яңа изгеләр һәм Россиянең Аллаһ алдындагы эчкерсез гөнаһсызлары рәтенә кертелә[2].

Шулай итеп, мөхтәрәм авылдашыбыз хәзерге көндә керәшеннәрдән бердәнбер изге, дип санала. Рус Православие Чиркәве һәм Барнаул епархиясе әһелләре Пётр Гавриловичны канонлаштырганда аның татар икәнен белмәгәндер, мөгаен, чөнки кайбер документларда милләт турындагы графада атакайны «урыс» дип язганнар.

***

Өлкән яшьтәге авылдашларыбызның Пётр Гаврилович хакында мәгълүматы булмау өстенә, аның турында берни дә белмәүләре ачыкланды. Әби-бабайлар бары тик аның абыйсы, 1898 елның 2 маеннан 1916 елга кадәр Мамадыш өязенең Юкәче авылы – «Казанской иконы Божией Матери» чиркәве приходына караган сигез авыл халкына хезмәт иткән Семён Гаврилович Гаврилов турында гына хәбәрдар.

Җөри урта гомуми белем бирү мәктәбенең музей түгәрәгенә йөрүче укучыларның Алтай крае губернаторына язган хатына җавап буларак, Рус Православие Чиркәвенең Мәскәү Патриархатына караган Барнаул епархиясенең

[2] «Причислен к лику святых новомучеников и исповедников Российских для общецерковного почитания».

православие дини оешмасы, Алтай митрополиясе башлыгы, Алтай һәм Барнаул епископы Сергейдан алынган җавап хаты эшебезне дәвам итәргә ярдәм итте. Бу хатта Алтай крае Дәүләт архивының махсус документлар бүлегендә саклаучы эштән күчермәләр җибәрелгән иде.

Архив күчермәләрен анализлаганда, Пётр Гаврилович Гавриловның кулга алынганчы «Бийск каласы, Андреев урамы, 13 йортта» яшәгәнлеге мәгълүм булды. Шулай ук, сорау алу беркетмәсендә Пётр атакайның гаилә составы турындагы графада: «Ялгыз, балалары бар, ләкин бергә яшәми һәм алар белән элемтә тотмый», – дип тә язылган. Пётр Гаврилович аларның куркынычсызлыгын уйлап шулай җавап бирергә мәҗбүр булгандыр, мөгаен.

Руханиның балалары яисә оныклары белән элемтәгә керү максатыннан, югарыда телгә алынган адрес буенча җибәрелгән хатка җавап булмады. Әмма ярдәм безгә көтмәгән-уйламаган җирдән килеп төште. Хәзерге көндә Киленчәк (Геленджик) шәһәрендә яшәүче эшкуар, әбисе ягыннан Пётр Гавриловның оныкчыгы Александр Безбородько нәсел тамырларын барлау эшенә керешә. Бу эштә ярдәм итүен сорап, дустына, Казан шәһәрендә яшәүче журналист Фәрит Вәлиулловка да мөрәҗәгатъ итә. Фәрит Вәлиуллов, үз чиратында, урау юллар аша минем электрон адресны эзләп таба һәм анда Александр Безбородько төзи башлаган нәсел агачының бер өлеше белән бергә хат калдыра.

Нәсел агачыннан Пётр Гаврилович Гавриловның Александра (Шура), Соня, Тоня, Анна (Нюра), Ольга исемле биш кызы һәм Василий исемле улы булуы ачыкланды. Шунысын әйтеп үтәргә кирәк: анда атакайның һәм барлык балаларының да фотографияләре урнаштырылган, ә бу безнең өчен бик әһәмиятле.

Авыл халкыннан бөртекләп җыелган мәгълүматны анализлаганнан соң мондый нәтиҗәләргә килдек: 1) Мамадыш районының Уткино авылында Гаврилов фамилиясен йөртүче, ана белән улдан гына торучы бер генә гаилә бар; 2) Гавриловлар нәселеннән ике дистәгә якын бала Казан үзәк керәшен мәктәбендә белем алган; 3) Бу нәселдән ике чиркәү әһеле, берничә дистә укытучы, мәктәп һәм завод директорлары, табиблар, эшкуарлар һәм башка һөнәр кешеләре чыккан; 4) Казанның цирк аренасында чыгыш ясаган, бөтен дөньяга танылган рус баһадиры Поддубныйның үзе белән бил алышкан «Русский лев – Василий Гаврилов» та шул нәселдән.

Кызганыч, заманында яртысы Гавриловлардан торган, халык гөрләп яшәгән Уткино авылы бүген пыскып янган учакны хәтерләтә: биредә карткоры гына калып, канонлаштырылган бердәнбер керәшен священнигы туган җир бетүгә таба бара. Безнең белән очрашуда үзенең керәшен татары икәнен белгән Александр Безбородько бабасы туган нигездә часовния төзергә теләвен белдерде. Ходай аның изге нияте гамәлгә ашуын насыйп итсен!

Файдаланылган әдәбият һәм чыганаклар

1. Деяние Юбилейного Освященного Архиерейского Собора Русской Православной Церкви о соборном прославлении новомучеников и исповедников Российских XX века. – Москва, 12-16 августа 2000 г.
2. Гришаев В.Ф. Невинно убиенные: к истории сталинских репрессий правосл. духовенства на Алтае. – Барнаул, 2004. – 240 с.
3. Революциягә кадәрге керәшен священниклары исемлеге http://www.missiakryashen.ru/history/figures/lists-priests/
4. Фаст М. В., Фаст Н. П. Нарымская голгофа: Материалы к истории церковных репрессий в Томской области в советский период. – Томск; М.: Водолей Publishers. – 2004. – 560 с.
5. Алтай крае Дәүләт архивының Махсус документлар бүлеге. 6153пф номерлы тикшерү эше материаллары.
6. Канонлаштыру буенча Барнаул епархиясе материаллары.
http://www.pstbi.ru/bin/db.exe/ans/nm/?HYZ9EJxGHoxITYZCF2JMT...eCQ
http://days.pravoslavie.ru/Life/life4809.htm ■



Арслан Палкайга бирелгән «Алты авыл»

АРЫСЛАН БАТЫР

(«Алты авыл» төбәгенә нигез салган сержант Арыслан Палкай)

Кадир Акъегет

Пенза өлкәсенең көнбатышында «Алты авыл» дип аталган татар төбәге бар. XVIII гасырда бу авыллар Верхоломов өязенә кергән. Пенза губернасында яңа өязләр барлыкка килгәч, татар авылларын өч өязгә аералар. Хәзерге вакытта Кикын (русча – Кикино), Кабылкин (Кобылкино), Мачали (Мочалейка), Тәләтен (Телятино) авыллары – Каменка, Ришитен (Решетино) – Пачелма районына, Качкару (Кутеевка) исә Белинск районына керә.

Бу авыллар XVII гасыр азагы-XVIII гасыр башында барлыкка килгән. 15-20 еллар элек әлеге даталар безгә билгеле түгел иде. Әмма шунда яшәүче картлар: *«Безнең авылларга Арыслан Палкай җирләр алган»*, – дип сөйли. Биләмәнең кайсы патша тарафыннан бирелгәне дә билгеле түгел: кемдер – Явыз Иван, ә кайберләре Петр I яки Әби патша бүләк иткән, дип әйтә. Бу риваятьләр һәр авылда үзгәчә сөйләнә, әмма аларның барысын да Арыслан батыр берләштерә. Мәсәлән, Кикында шулай сөйлиләр иде: *«Патша Арыслан Палкайга: «Бер көндә, кояш чыгып кире батканчы, үз атыңда күпме җирләр уза алырсың – шул җирләр синеке булыр», – дигән. Арыслан Палкай шул сәяхәтендә булачак Кикын авылы урынында, сазда киек казлар күрә, имеш, һәм: «Бирédә Кикын авылы булыр», – дип әйткән, тагын да бераз баргач, аңа кыргыйланган мәче очраган һәм ул: «Ә бирéдә Мачали булыр», – дигән...»*

Чаллыда яшәүче Билал Абдрахман улы Канеев 1991 елда «Татарстан» журналында басылган (№8) «Арыслан Палкай җирләрендә» исемле хикәясендә Мачали авылындагы бабайлар сөйләгәнне язган: *«Арыслан Палкай бу җирләрне әйләнеп чыккач, шунда ук татарларны төрле яктан үз канаты астына җыя башлый. Беренче башлап авылга нигез салучылар Бәхтияров, Тинчурин, Акмаев, Дәүләткилдиев, Бикяшев, Тактаровлар була. Алар башта мунчала ясау, бау ишү һөнәре белән шөгыльләнә. Тирә-якта урман, бигрәк тә юкә урманы күп була. Монда яшәүчеләр, юкә кабыгын суда тотып, мунчала ясыйлар, бау, аркан ишәләр. Бәлки, авылның исеме шуннандыр, диләр...»*

Качкару авылында яшәүче Шакир Караяков болай сөйләгән: *«Арыслан Палкай патшадан өч ат арытырлык урын сораган, ягъни бер ат арыгач, икенче ат белән, аннары өченче ат белән китәргә – круг буйлап. Патша риза була. Арыслан Палкай, атлар узган эзгә алмагачлар утыртып, граница ясаттыра. Ул алмагачлар колхозлашу елларында гына бетте. (Алмагачлар 300 ел тормый инде, билгеле. –* ***Авт.иск.****) Шул кругка Арыслан Палкай алты авыл оештыра: «Менә син монда, син монда урнаш», – дип, якыннарына өләшә. Безнең авылга иң әүвәл Котый дигән бабай килгән, аның белән биш-алты гаилә дә күчеп килә. Халкы төрле җирдән җыйнала: Тамбов губернасы, Пенза ягыннан да... Күпчелеге Ломов һәм Темников якларыннан килә. Бу авыллар урнашканчы, бирéдә буш җир булган...»*

Галим Сәлим Гыйләҗетдинов та «Риваятьләр – белем чишмәсе» исемле мәкаләсендә шуңа охшаш мисал китерә:

«Тирә-яктагы җирләрне элекке рус патшаларыннан берсе Арыслан Палкаевка (ул полковник булган, диләр) бирә. Ул патшага яхшы службада була. Дворецта патша сорый:

– Ни бирим бүләккә?

Арыслан сразу җавап кайтармый. Өч көн вакыт сорый уйларга. Уйлый бу: «Акча сорасаң – бетә, кием сорасаң – туза, мал-туар – мәшәкатьле, җир сорыйм», – ди. Патшага бара да әйтә:

– Миңа суга батмый, утта янмый торган бүләк бир син, падишам, – ди.

Теге аптырый хәзер. Нәрсә бу... уйлый, таба алмый, аннары әйтә:

– Иртәгә кил, – ди.

Иртәгәсен килгәч, Арыслан сорый:

– Җир бир, – ди.

– Күпме?

– Өч ат арытырлык урын, ягъни бер ат арыгач, икенче ат белән, аннары өченче ат белән китәргә, круг буйлап, – ди. Патша риза була. Арыслан, атлар узган эзгә алма агачлары утыртып, граница ясаттыра... Шул кругка Арыслан Палкаев алты авыл оештыра».

Халыкның Арыслан Палкайны риваятьләрдә яд итүе урынсыз түгел. Ул чыннан да реаль кеше булган икән. Бу архив документлары белән дә раслана. 1898 елда Петербург шәһәрендә А.Барсуков мөхәррирлегендә дөнья күргән «Десятни Пензенского края 1669-1696гг.» исемле җыентыктагы документтан бер өзек тәкъдим итәбез.

Арыслан Палкай җирләнгән дип саналган урында истәлек билгесе ачу тантанасы

ВЕРХОЛОМОВСКЫЯ ДЕСЯТНЯ.
1681-1696 ГГ.

Верстанные солдаты из татар, которые бывают на службе великих государей в выборном полку до отпуску, а живут они в Ломовском же уезде:

Деревни Новоселок: сержант Арсланъ Палкаевъ (сын Акжигитов). Рядовые: Смольян Уразовъ (сын Курмышев), Тохтар мурза Босаевъ, Борис Козякаевъ, Искердин Баженов, Курманалей Тулунбаев, Кидарь Ишелеевъ.

Деревни Печеевки: Якуш Енаевъ, Лукаш Романовъ, Ивакай Тулувакаевъ, Батей Ишмаевъ, Дауш Тимаевъ, Умряк Махаевъ, Утямиш Найденовъ, Сюндюк Акмакаевъ, Исянгиндя Акингиндинь, Умряк Бектемировъ, Сверзизя Бангузинь.

Нововерстанные татары же, а служат по разным городам в рейтарском строе, а живут они в Ломовском уезде в деревне Новоселках, а по Ломовской черте никокой службы не носят: Бикбулат Палкаевъ (сын Акжигитов),Черучей Тереeметеевъ, Леонтий Неверовъ, Ишмай Битудинъ (сын Акжигитов), Нехорош Чураевъ, Тюняш Кудабахтеевъ, Такташ Четмаевъ (сын Акжигитов), Клим Шабаевъ, Уразгиндя Шабаевъ, Сюдюк Сюнбаевъ (сын Бареев), Токтар Терябердин (сын Девликамов), Исай Миняшевъ (сын Акжигитов), Исян Тулбаевъ, Бикбулат Кудашев (сын Баткаев), Алексей мурза Мусаловъ, Исянгиндя Борисовъ, Токбулат Токташевъ.

Алдагы биттә Арыслан Палкай урядник дип күрсәтелгән. Җәя эчендәге фамилияләрне, эзләнүләр нәтиҗәсендә ачыклагач, мин куйдым.

Менә шушы документтан Арыслан Палкайның Верхоломов өязенең Новоселок авылында сержант буларак яшәгәнлеген беләбез. 1723 елгы беренче халык санын алу документында Кабылкин авылы – «Кобылкино, Новоселок тож», дип язылган, ягъни ике авылчыкны бергә теркәгәннәр. Мөгаен, Арыслан Палкай үзенең иптәшләре белән 1698 елдан соң шул авылда – хәзерге Кабылкинда яшәгәндер, дип уйлыйм. Әмма катгый итеп әйтә алмыйм, чөнки биредән 40-50

чакрым ераклыкта тагын бер «Новоселок» авылы була. Чыганакларда, хәзерге Вадинск районындагы Каргалейка авылы да Арыслан Палкайныкы булган, дип әйтелә. Соңрак, 1710 һәм 1718 елларда татарлар киткәннән соң, бу авыл һәм Бортас елгасының югары агымындагы бу җирләр урысларга бирелә.

1698 елда сержант Арыслан Палкай һәм иптәшләренә – барлыгы 169 ир-атка ата-бабаларыннан калган печәнлекләр («ухожий») урынында патша Петр I тарафыннан хәрби хезмәт өчен җир бүленә. Шулай итеп, алда әйтелгән авылларга нигез салына. Аларның бабалары «ухожий»ларны 1623 елда ук алган була.

Безнең мирас №7 июль 2017

Выпись с отказных книг из Приказа Болшаго дворца Арслану Палкаеву сыну Акжигитову с товарищи ГАПО.ф.196,оп. 2.д.1702.

«В прошлом (7)207-м (1698) году, сентября в 22-и день, по Нашему, Велякаго Государя, указу и по грамоте ис Приказу Болшаго дворца за приписью дьяка Нашего Григорья Постникова и по наказной помяти столника Нашего и воеводы Пракофья Боранчеева и челобитью Верхне-ломовскаго уезду деревни Коргалеи да деревни Новоселок служилых беломесных мурз и татар сер-жанта Арслана Палкаева сына Акжигитова с товарыщи, верхоломовец Афонасеи Скуратов да под(ъ)ячеи Григореи Смирнов ездили за Ломовские воловые крепости в степь на дикое порожжее поля и в челобитчиковы вотчинные ухожьи в урочищи по Ченбарской дороге на Юрьевской верх, по обе стороны, по Колоновскои дороге сквозь Сернялскаго липяга да устья Кевды реки вниз по обе ж стороны до устья реки Ятмиса по обе стороны до середнего липяга на верхней конец, идучи по правой же стороне на Малой Ченбарец и вниз того Малаго Ченбарцу, и перешед Болшую Ченбарскую дорогу с урочищи. А не доехав тех вотчинных ухожьев и вышеописанных урочищ, имали с собою сторонних людей и сторожилых, и с теми сторонними людми дикое поля и вотчинные ухож(ъ)и досматривали сыскивалися. И по осмотру и по сыску дикое поля измеряя в десятины и положили в четверти, а сенные покосы в копны, отвели челобитчиком сержанту Арслану Палкаеву...

Татарлар килгәнче бу җирләрнең хуҗалары мукшылар булган, диләр. Шулай дип әйтсәк, Арыслан Палкайга бирелгән «Отказная грамота» белән капма-каршы фикер туа, чөнки грамотада җирләр «кыргый кырда» («на Диком поле»), «вотчина» печәнлекләрендә бирелгән, дип язылган. Ягъни моңа кадәр дә бу җиргә татарлар хуҗа булган. Тарихи чыганакларда бирелә 1623 елларда хәзерге Рязань өлкәсендәге Алгамазово, Подлясово һәм Пичиморга авыллары халкының «ухожий»лары булган, дип язылган. Мөгаен, ул авылларда мордва белән татар бергә яшәгәндер.

Ә хәзерге заманда авылларның исемнәренә килсәк, Кутеевкадан (Качкару) башкасы татарча түгел. Кутеевка – Кутеев фамилияле йомышлы татардан. Ә Кикын авылының исеме ПетрI киңәшчесе

Александр Васильевич Кикиннан булуы мөмкин. 1701 елда Кикиннардан биш агай шунда җир алган. Дөресрәге, Кикиннар һәм Аргамаковлар Арыслан Палкайга бирелгән татар җирләрен алып, шунда крепостнойларын да китереп, булачак авылларга нигез сала. Кутеевка белән Кикын авыллары уртасындагы Аргамак авылында хәзер дә урыслар яши. Кикыннан исә, Александр Кикинның хыянәтеннән соң, крепостнойлар китә, җирләр хөкүмәткә күчерелеп, кире татарларга кайтарыла, әмма авыл исеме сакланып кала. 200 метр чамасы ераклыкта Ендовище исемле кечкенә генә татар авылы да була, аны хәзер Каргалы урамы дип йөртәләр. Тора-бара әлеге татар авылы, зураеп, Кикын белән кушыла.

Чыганакларда Мачали авылы «Мачелейка, Максютовка тож» дип язылган. Бу авыл 1715 елда ук булган инде. Ә менә Ришитен белән Тәләтен авыллары беренче халык санын алу документларында теркәлмәгән, алар якынча ун ел узгач кына барлыкка килә. Ришитенга Кутеевка халкы нигез сала, ә Тәләтенгә, мөгаен, Кикынныкылар күченгәндер. Авыл исемнәре якындагы елга атамалары белән бәйле. Бу елгаларга кайчан мукшы исемнәре тагылган – анысы безгә билгесез.

Архив чыганакларында Решетин, Кобылкин фамилияле йомышлылар булганлыгы турында да әйтелә. Мәсәлән, 1667 елда Литва походында һәлак булган урядник Федор Николаевич Кобылкин. Күрәсең, шуларның якыннарына татарлар арасында җир бирелә, ә соңрак алар бу биләмәләрне татарлар белән алмашкандыр. Кабылкин авылының исеме шуннан калган.

Йомышлы кешеләр җирне алмаша алган, ә тулысынча сатарга хокуклы булмаган. Кайчакта алмаша торган җирнең күләме тигезсез булып, аерма акчалата түләнгән, ягъни җир алмашу яшерен рәвештә сату-алу процессына әйләнгән. Җир белән шундый алыш-бирешләр Явыз Иван заманында ук булган.

Арыслан Палкайның исеме элеккеге картада да теркәлеп калган. Бу урын хәзерге Мачали бакчаларына (Арыслан Палкай урманы) туры килә. Ул борынгы картада «Арыслан кывагы» дип язылган.

***

Риваятьләрдә, Арыслан Палкайны мукшылар үтергән, дип әйтелә. «Алты авыл» уртасындагы «Арыслан кывагы» урманында бер кабер бар. Аны бирεдә яшәүчеләрнең күбесе Арыслан Палкайныкы дип саный. Кабер янына истәлек билгесе дә куйдылар, әмма дөрестән дә Арыслан батырның җәсәде шунда җирләнгәнме – монысы төгәл билгеле түгел.

Арыслан Палкай яшәгән еллар да билгесез, фәкать архив чыганаклары нигезендә генә якынча фаразларга мөмкин. 1697 елда аның 6 яшьлек Сөләйман исемле улы була. Батырның тагын Кодралей һәм Бикбулат исемле уллары да билгеле. 1723 елгы беренче халык санын алу документларында Арыслан Палкай турында мәгълүмат очрамады. Шунлыктан ул 1660-1718 еллар арасында яшәгән булырга тиеш. 1717 елда бу авыллар кубаньлылар һөҗүменә дучар була, күп халык үтерелә, әсир ителә. Мөгаен, безнең Арыслан Палкай да шушы сугышта батырларча һәлак булгандыр.

Редакциядән: *Татар әдәбиятының күренекле язучысы, беренче татар романы «Хисаметдин Акмелла»ның авторы Муса Акъегетзадә дә Арыслан Палкай нәселеннән.* ■

РЕВОЛЮЦИЯ ЕЛЫНДА КАЗАН САБАН ТУЕ

Ленар Гобәйдуллин

Казан шәһәрендә гасырлар дәвамында оештырылып килгән Сабан туе бәйрәменең бай һәм һәр чорга хас үзенчәлекле тарихы бар. 1912-1917 еллардагы Казан Сабан туйларын хәйрия җәмгыяте оештырып, милли бәйрәм аның табыш чыганагына әйләндерелү сәбәпле, мәйданга билет сатып алып кына керү мөмкин булган. 1917 елда билетның хакы 40 тиеннән башлап 3 сумга кадәр, балаларга исә 30 тиен тәшкил иткән. Бәйрәмне уздыру утыз кешелек комиссиягә тапшырылып, анда хәйрия җәмгыяте әгъзалары аз, күбрәк сәүдә хезмәткәрләре, яшьләр хезмәт иткән. Сабан туе алдагы еллардагыча – 19, 23, 26 нчы майда хәйрия җәмгыяте арендага алган «Аркадия» бакчасында уздырыла. «Кояш» һәм «Йолдыз» газеталарында басылган хәбәрләрне бергә җыеп, бәйрәмнең тулы картинасын тергезергә мөмкин.

Бер-берсенең сәләтен (җыгу рәтен) белергә тырышулары

Көндезгә өчтә башланып киткән бәйрәмнең беренче көне менә ничек тасвирлана: *«Бакчаның агачлы өлеше төрле кибетләр, ашамлык сатучылар белән тулы. Күл буенда 30-40 самовар кайнату өчен кухня әзерләнгән. Анда самоварлар тезелеп тора. Эчкәрәк кергәч, җәйге театр бинасының алды койма белән әйләндереп алынган мәйдан урыны күренеп тора. Аның читләре бер-бер артлы эскәмияләр белән чолганып, утыра торган урыннарына номер сугылган. Мәйдан уртасы ямь-яшел чирәм. Мәйдан капкасының башында төрле төстә, төрле күләмдә флаглар асылынып тора. Капканы кергәч тә артта – театр сәхнәсенә арт биреп утырган президиум өстәле. Рәис – Исхак Карташев, сәркатип – Галимҗан Әмирхани, хәзинәдар Габдерахман Үтәгәновлар утыралар. Аларның сул ягында мөселман гаскәриләреннән төзелгән оркестр группасы. Халык шулкадәр күп, әзерләнгән эскәмияләр җитмәү генә түгел, мәйдандагы чирәм дә кеше белән тулы. Көрәшергә иркен генә урын да юк. Урынлы билетлар әллә кайчан сатылып беткән. Гаскәриләргә мең билет бушлай өләшенгән. Шулай да халык килүдән туктамый, пароход килгән саен агылып кына тора. Буфет эшли. Анда Гыйльман Гобәйдуллин, Камал Іләр идарә тә. Милиционерлар тәртип саклау өчен өзлексез йөгереп эшлиләр. Аларның башында Касыйм Туйбакин тора. Музыка уйный, халыкның бер өлеше тышкы якка чыгып, агачлар арасында рәхәтләнеп җәелеп чәй эчә, бер өлеше буфетта утыра, бер өлеше кибетләр артында чикләвекләр ярып йөри»*.

Гадәттә бәйрәмнең һәр көне балалар көрәше (батыр – 12 яшьлек Габделкәбир Бикбауов) белән башланып киткән, ә аннары – зурлар көрәше (баш батыр – Габделхак Ногманов). Сабан туеның бу көнендә безнең өчен берникадәр сәеррәк булган бер ярыш та үткән, аның турында менә ниләр язалар: *«Вареньега буялган булкины мәйдан уртасына нәзек кенә җеп белән асып куялар. Аны ашарга кирәк, ул авыз җитәр-җитмәс хәлдә югары. Авыз тисә, хәзер икенче якка әйләнеп китә. Ягъкуб Ягъкупов исемле бер егет чыгып, булкиның башын өзеп ала. Аннан бөтенләй ашап бетерүне таләп итәләр, ул каршы килгәч, Хәсбиулла исемле кеше яртылаш ашап, беренчелекне ала. Халык бу уенны яхшы ук кәефләнеп карый»*.

Таяк өстеннән сикерү уены тәмамлангач (ничек сикергәннәрдер, бу турыда язылмый), милли җырлар җырланган. Вакыйга шаһитының игътибарын унике кеше җырлап та әллә ни уңыш казанмавы, ә Монасыйпов фамилияле берәүнең, тавышы булмаса да, онытылып бара торган «Өзелә ич үзәгем, сандугач» исемле моңлы гына бер иске көйне башкаруы җәлеп иткән. Аның артыннан Габдулла Килдешев:

«Арысландай киек һич моңаймас,
Каршысында аның тау булса.
Яшь каһарман егет һич кайгырмас,
Газиз башы аның сау булса»,

– дип сузып җибәргән.

Аннары, күз бәйләп чүлмәк вату, аркан тартышу, соңрак, капчык сугышына охшашрак, «аршын чамасы биеклектәге ике казык өстенә куелган агач өстенә утырып, махсус ясалган салам себерке белән сугыш уены» тамаша кылучыларның игътибарын аеруча җәлеп иткән: *«Иң әүвәл ике солдат чыгып кулларындагы себерке белән битләренә сугышалар. Закир Галимов дигән яшь кенә бер солдат, 4 кешене кыйнап төшергәч, зур гына, таза гына бер мужикка очрый... Бу уенда сугышучыларның яңакларны кызарткан-чы сугышуларына халыкның кәефе килә, халыкның көкрәгеннән чыккан көлке тавышлары өзлексез гөрелдәп тора»*.

Бәйрәмнең чираттагы өлеше – йөгерүгә бәйле уеннар. Капчык киеп йөгерү һәм зурларның ераклыкка чабышыннан соң – велосипед узышы. Анда 7 кеше катнашып, өчесе – мөселман, дүрте урыс булган. Беренчелекне Николай Райпин алып – көмеш сөт савыты, Михаил Тирсов – кечкенә көмеш бокал, өченче килгән Андрей Павлов көмеш тоз савыты белән бүләкләнә, дүртенче

булып килгән Әхмәд Галиевка берничә сум акча бирелгән.

Бәйрәмнең иң тантаналы өлеше ат чабышы булып, ат хуҗалары бүләкне акчалата алган. Сабан туеның бу көнендә унбер ат җибәрелеп, Закирҗан Җиһаншин атына – 25 сум, Кәшшаф Гайнетдинов атына – 15 сум, Хәбибулла Төхфәтуллин атына – 10 сум, Гариф Латыйпов атына 5 сум бирелгән.

1917 елның 22 маенда Сабан туе, татар халкы тарихында беренче мәртәбә, Казан мөслимәләр җәмгыяте тырышлыгы белән хатын-кызлар өчен махсус оештырыла. Монда, балалардан кала, ирләргә килергә хокук булмаган. Газетага басылган игъланнарда да, комиссия әгъзаларыннан башка, мәйданда бер генә чит-ят ир-ат та булмаячагы вәгъдә ителә. Хатын-кызлар Сабан туеның программасы ике кисәктән торган. Аның беренчесе «әдәби һәм милли концерт»тан гыйбарәт: *«Газиз Мусин скрипкада «Зиләйлүк» һәм «Баламышкин»ны, Камал I нче тоткын көйләрен, Камал II нче «Бай кызы» шигырен, Камал II нче вә Искәндәр әфәнделәр «Өйләнү түгел, сөйләнү» шигырьләрен декламировать итте»; «Насыйр әфәнде Исхак курайда һәм американский биюләр, һәм башка кызыклы гына программалар башкарды»; «Насыйр әфәнде ялгызы, Нури әфәнде белән Фәхрия Әхмәтовалар кара-каршы чыгып биеделәр. Монда иң зур осталык күрсәтеп, нәкъ милли рәвештә биючеләр соңгылар булды. Әхмәтованың нәкъ авыл хатыны, Нури әфәнденең нәкъ авыл егете калыбында чыгып, яулык болгашып биюләре авыл өйләрендә качып эшләнгән милли мәҗлесләрне искә төшерәләр иде»; «Насыйр әфәнденең биюе дә яхшы гына чыкты. Сәхнә ул көнне төрле агачлар вә үләннәр белән бизәлгән иде. Концерт күңелле генә чыкты».*

Бәйрәмнең икенче өлеше мәйданда уза. Анда балалар көрәше, таяк тартышу, чүлмәк вату, сыбызгы белән куышу, сыбызгы тавышы белән күз бәйләп сугыш (бу уеннарның ничек булганлыгы тасвир ителми), капчык киеп йөгерү, балалар йөгереше булган. Сабан туеның баш батыры булып Сәләхетдин Шакирҗанов исемле бала калган. Милли уеннарда хатын-кызлар да актив катнашып, бүләкләр алган.

26 нчы майда узган өченче көн Сабан туе да балалар көрәше белән башланып, анда Исмәгыйль Әхмәтов исемле 10 яшь-

Сабан туенда көрәшергә әзерләнгән балалар

лек бала батыр калган. Зурлар көрәше җентекләбрәк тасвирланган: *«...байтак кына көрәшкәч, көчле батыр иттереп аерып калдырылган Арыслангали, Вафа, Габделхак, Шакир, Әкмали исемле кешеләр үзара көрәштереләләр. Иң ахырга Арыслангали белән Габделхак кала. Боларның көрәше уен гына түгел, бу ике кешенең артында мең кеше көчәнеп куәт биреп ята. Озак кына көрәшелгәннең соңында Габделхак Ягъкуб җиңә, мөкяфәт аңар бирелә. Арыслангали мөсәлләм (канәгать) булмый, нәкъ әүвәл мәйдандагыча чүгәләп утыра да, кулындагы билбау белән битен сөртеп, көрәшергә иптәшен көтә. Габделхак белән Арыслангали янәдән көрәшәләр. Бусында Арыслангали ега... Оста гына көрәшкән фәкыйрь егетнең матур гына егуын күргәч, халык түзә алмый, президиум әүвәлге батырга биргән мөкяфәтне моңар да бирә. Читтә иганә җыю башлана. Тагын бер тапкыр сынашырга керешәләр. Егетләр берсеннән-берсе матур көрәшә. Инде күтәреп алып бәрә генә, дигәндә, Арыслангалинең итек асты кубып китмәсенме! Халык бераз көлеп торгач, арадан берсе җеп чыгарып, итекне бәйләп биргәннең соңында, Арыслангали янәдән күтәреп салып, батырга чыгып кала».*

Катыктан тәңкә эзләүне, кайчандыр РФ Президенты В.В.Путинны башы белән катыкка чумдыргач, милли уен түгел, дип, шактый тәнкыйтьләсәләр дә, бу революциягә кадәр үк булган икән: *«...мәйдан уртасына өстәл чыгарып, аның өстенә тирән тәлинкә белән катык куялар. Катык эченнән акчаны алырга чыккан кеше, кулын артка куеп, куе катык эчендә авыз-борын белән бераз йөргәннең соңында, көмеш тәңкәне авызга кабып, башын һавага күтәрә дә, янында тастымал тотып торган егетне битен сөртү өчен кулын болгап-болгап ярдәмгә чакыра. Халыктагы шатлыкның иге-чиге юк, алардан чыккан көлке тавыш белә күрше күршенең сүзен ишетә алмый... Ләкин, тәлинкә сайлыктан булса кирәк, монда чыккан һәр кеше бер тәңкәне ала тора...»*

Аяк көрәше уены да шактый кызыклы, аны исә иске мәдрәсәләрдә шәкертләр эч пошканнан уйнарга яраткан икән: *«Җәелгән брезент өстенә ике кеше берсенә каршы берсе ята да, култыклашып, җилкәләреннән тотышканнан соң, һәр икесе аякларын әйләндереп каплашалар. Бар көч белә аякка-аяк терәшеп тартышканнан соңында берәүнең итек табанына каза ирешә...»*

Бәйрәмнең бу көнендә исә «Карурман», «Сакмар көе», «Тәфтиләү», «Зиләйлүк», «Мәдинәкәй» кебек милли көйләрне башкарганнар, салмак җырларны дәртле, милли биюләр алмаштырган: *«Милли биюләр башлангач та, егетләр сикерешеп чыгалар. Ул чыккан егет аякларын шулкадәр матур баса ки, җиргә тигәне дә күренер-күренмәс кенә күзгә чагыла. Җитмәсә, мәтәлчек атып-атып бии...»* Шунысы игътибарга лаек: «Әтнә көе» башлангач, гармунчы уйный белмәү сәбәпле, президиумдагыларның урысча бию, дип, биючене туктатуы бу чорда ук халык бәйрәмен оештыручыларның миллилекне кайгыртуы турында сөйли.

Багана өстендә селберке сугышы бәйрәмнең бу көнендә дә иң көлкеле уен була: *«Ашаган саен ашыйсы килә, дигән кеби, бу уенны да халыкның күргән саен күрәсе килә, багана өстендә салам селберке белән берсен-берсе сыйлашып хәлдән тая, боларга – үлем, халыкка – көлке. Берничә минут сугышып торганнан соң, Кәримов белән Ногмановлар икәве дә батыр булып калалар. Берничә тапкыр сугышып акча алган Галимов акчасын балаларга бирә...»*

Велосипед узышына алты кеше җибәрелеп, беренче килгән Мөҗид Әҗимовка – 10, 15, 20 тиенлек акча белән тутырылган көмеш акча савыты, икенче килгән Андрей Павловка – көмеш зур савыт, өченче килгән Әхмәд Галиевкә чәй сала торган көмеш калак бирелә.

Атлар узышына җиде чакрым арага 8 ат җибәрелеп, беренче Закирҗан Җиһаншин, ә аннары Сираҗетдин Латыйпов, Гыйльметдин, Гаязетдин атлары килгән.

Сабан туеның соңгы, 26 майда уздырылган көне алдагыларыннан әллә ни аерылмый, программага ераклыкка сикерү генә өстәлгән. Бәйрәмгә газета мөхәррирләре, имамнар һәм урыслардан да берничә зат мөхтәрәм кунак буларак чакырылган. Шунысын да әйтергә кирәк: Сабан туеның бу көнендә дә хәзерге **Арча районының Түбән Мәтәскә авылыннан Арыслангали Әүхәдиев исемле солдат** батыр кала. Халык аны һавага күтәреп чөеп, 19 сум акча иганә җыеп та бүләкләгән. Велосипед ярышында беренчелекне Николай Райпин, ат чабышында исә шул ук Закирҗан Җиһаншин аты ала. Әмма бу көндә фаҗигаләр дә булган икән: *«2 нче килгән атның малае егылып калган иде. Ат үзе мәйданга килеп керде. Узышка йибәргән атлардан Габдулла Шәфигуллин аты симезлектән, атның дагалы булуыннан булса кирәк, Мәлихә куаклыгыннан чыкканда егылып үлде...»* – дип языла чыганакта.

***

Шулай итеп, ямьле май аенда Казан халкы пароход белән, тарантаска ат җигеп яки җәяү Кабан күленең аргы ягындагы «Аркадия» бакчасында Сабан туе үткәргән, күңел ачкан. Халык саны, бәйрәмгә керү түләүле булуга карамастан, шактый күп булган. Мәсәлән, беренче көндә генә дә 5-6 мең кеше тамаша кылган (1917 елда Казанда 45 меңнән артык татар яшәгән), дип хәбәр ителә, араларында шәһәр Сабан туен күрергә килгән авыл кешеләре дә шактый булган. Гадәттә, Сабан туе бертөрле программа буенча барып, анда 15ләп уен уйналган, әмма алар ел саен яңарып, игъланнарда да «моңарчы һич күренмәгән кызыклы милли уеннар» булачагы турында хәбәр ителгән. Велосипедта ярышудан кала, башка бер генә уенда да урыслар катнашмаган. Катнашучыларга акчалата бүләк, балаларга исә вак-төяк призлар бирелгән. Бары тик велосипед узышында җиңүчеләр генә көмеш әйберләр алган һәм бу Казан Сабан туеның иң зур бүләгеН тәшкил иткән. Аның шулай югары бәяләнүе, велоспортның татарлар арасында яңа күренеш булуы һәм әлеге төр техниканың да кыйммәтлеге (әйтик, «Россия» маркалы велосипед 85 сум торган), мондый милек иясенең шактый хәлле кеше булуы белән аңлатылса кирәк. Ә инде аннан кала зур бүләк беренче килгән атның хуҗасына (25 сум) бирелгән. Хәзерге акчага әйләндерсәк, бу якынча 32 мең сумны тәшкил итәр иде. Мәйданның баш батыры булган көрәшчегә якынча 19 сум акчаны бәйрәмгә килүчеләр иганә итеп җыеп биргәне аңлашыла, хәзергечә тәкә яки затлы бүләкләр аңа тәтемәгән. Башка еллардан аермалы буларак, баш батыр ярлы булса да, ниндидер байның химаясендә торган (әйтик, Әтнә ягыннан Хафиз батыр кебек), дип уйларга нигез юк, чөнки ул солдат булган һәм көрәштә тактиканы, әлбәттә, халык хуплавы белән, мөстәкыйль хәл иткән. Баш батырның даны комиссия тарафыннан әллә ни игътибарга алынмаса да, халыкның аңа булган хөрмәте һәм ихтирамы чиксез булган. Сабан туеның һәр көнендә дә милли уеннарда бер үк кешеләр катнаша алган.

Хатын-кызлар өчен махсус Сабан туе уздыру яңа күренеш булып, тарихта мондый очрак бүтән кабатланмаган. Бәйрәмнең тагын бер үзенчәлеге: башка көннәрдә гади халык тарафыннан милли көйләр генә башкарылса, бу көнне, гүзәл затларны агарту өчен булса кирәк, хөррият җырлары башкарылган, ә иң соңыннан митинг оештырылып, нотыклар сөйләнелгән. Шулай итеп, милли бәйрәм күпмедер дәрәҗәдә сәяси пропаганда чарасына да әверелгән.

Чыганаклар: Кояш. – 1917. – №1120, №1121, №1123; №1124; Йолдыз. – 1917. – №1794; №1795; №1796; №1797; Ак юл. – 1913. – май. ■

[1] Газеталарда басылган текстлар белән beznenmiras.ru сайтыннан танышырга мөмкин.

Мастякның асыл улы – Сәгыйть Сүнчәләй

1889 елның 2 августында Саратов губернасы Иске Мастяк авылында (хәзерге Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районына керә) дөньяга килгән мәшһүр шагыйрь, музыкант, тәрҗемәче, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Сәгыйть Хәмидулла улы Сүнчәләй балачагын Әстерханда уздырса да, туган авылын онытмый.

Сәгыйть Сүнчәләй. Хвалын. 1917 ел

Кайберәүләр аның иң якын дусты Габдулла Тукай белән 1911 елда Иске Мастяк авылына килүе турында әйтә. Мәгълүм булганча, шушы елның май-июнь айларында бөек шагыйрь Әстерханда, «Идел» газетасы редакциясендә була. Шуннан кайтканда ул Хвалын пристанендә тукталган һәм Иске Мастяк авылына да барып килгән, дип уйларга нигез бар. Бу елларда Пермь төбәгендәге Сараш авылында (Барда районы) балалар укыткан Сәгыйть Сүнчәләйнең җәйге ял вакытында туган авылына яки Әстерханга кайтканлыгы турында әйтергә мөмкин.

Шагыйрьнең 1917 елгы бер фотосы Иске Мастяк авылы кергән өяз үзәге – Хвалын шәһәрендә төшелгән. Бу аның туган җире белән элемтәдә булуына янә бер дәлил.

1931 елда ун елга хөкем ителгән Сәгыйть Сүнчәләй, тоткынлыкта язган хатларында да Мастяк авылын берничә мәртәбә телгә ала. Мәсәлән, 1934 елның 25 сентябрендә хатыны Әминә һәм кызы Таһирәгә язган хатында ялгызлыктан интегүен, китап укып, радио тыңлап һәм гармун уйнап күңел газабын басуын, дүрт мәче үстереп юануын белгертә. Шунысы игътибарга лаек: мәчеләрнең берсенә шагыйрь **«Мастяк»** дип исем кушкан икән. 1935 елның 21 февралендә хатыны Әминәгә язган хатында: *«Лишь в театре играл на днях (на фортепьяно) наши* ***мостякские*** *мелодии: «Высоки Сибирские горы» и «Красная лисица»»*, – дип яза. 1936 елның 16 февралендә Уфа шәһәрендә яшәүче энисе Һаҗәргә: «Бер вакыт табып, **Мастякка** яз инде, насыйп итсә, бергә барырбыз», – дип хат юллый. Кызганыч, Сәгыйть Сүнчәләйгә якыннары белән очрашырга һәм туган җирен кайтып күрергә насыйп булмый, шагыйрь «өчлек»нең 1937 елгы 9 октябрь карары белән атып үтерелә.

Игътибарыгызга Сәгыйть Сүнчәләйнең туган ил, туган җир турындагы ике лирик шигырен тәкъдим итәбез.

ИЛ ҖЫРЫ

Аерылганда гына туган илдән,
Сөеп калдым матур таемны;
Кемгә генә сөйлим, дускайларым,
Күңелемдәге каты кайгымны?

Таң алдыннан чыктым илемнән мин,
Газиз әнкәм үпте күземне;
Әлдә булса ишетәм, әнкәй генәм,
«Балакаем» дигән сүзеңне!

Чит илләрдә кайгым, сагышларым
Саргайттылар күркәм йөземне;
Күрергә генә насыйп булыр микән
Тагы да миңа газиз илемне.

АВЫЛДА АКТЫК КИЧ

Моңлы аулым, торган аулым! Бул бәхил! Инде китәм!
Талпына күңлем иреккә, мин бүтән илгә күчәм.

Читкә китсәм дә сине мин һич онытмам, әнкәем!
Син ни әйтсәң дә, ана, тапсам да чит илләрдә ямь.

Әрнү, рәнҗү, яшь кисте мине синдә, авыл!
Мин ничек түздем! Хәзер инде ачык алдымда юл.

Мин китәм, тик син, оям, искә төшәсең дә — эрим!
Айрылып китмәс идем, алда бүтән тормыш телим.

Аһ, туган, моңлы авыл! Китмәс күңелдән күрнешең,
Кайгы-михнәт җырлый-җырлый шаулаган моңлы кышың;

Язгы эссе көндә ауган ул сәрең, яңгырларың,
Ямь-яшел хәтфә кебек киң-киң уҗымлы кырларың;

Ярдагы шат чишмәнең серле агымлы уйнавы,
Ул күңелнең тын гына йоклап борынны уйлавы;

Ул бабайлардан калып килгән бәхет — урманнарың,
Ул бабайлар таптаган сукмакларың, тәхтең-тавың;

Ул кадер кичтә теләкләр берлә нечкәргәндә җан,
Таңда яңраучы әтәчләр таушы һәм моңлы азан;

Һәр үләнең, һәр җиләк, чәчкәң, агачың, яфрагың,
Язгы милли туй белән шатлыкта ямьләнгән чагың;

Шул җыенда — бәйгедә ул яшьләреңнең шатлыгы,
Ул — сиңайтим — кызларыңның күңленең йомшаклыгы;

Ул аларның йөзләренә балкыган ямь — җан яме,
Ул аларның язгы, иркен, яшь мәхәббәт бәйрәме?..

Әй, авыл! һәрбер җирең, һәрбер төшең, һәр байлыгың,
Һәр балаңның тормышы, ач кышларың, һәр бар-югың —

Барсы да күп күңлемә изге, якын кардәш булыр;
Һәммәсен сагъныр, онытмас, китсә дә читкә улың!

Мескин аулым! Күн балаңнан! Кич! Аңар син рәнҗемә,
Ул бәхет эзли, аңар юл бир, йөреп баксын, тимә!

Дәртле, яшь җанга һаман бер җир генә җитми; аңар
Тәңре биргән дөньяны — йөрсен рәхәт үз иркенә... ■

Әдәбият:
1. Рашитов Ф.А. Мостяк (1713-2013). Страницы истории татарского села. – Саратов, 2013. – 220 с.
2. Сәгыйть Сүнчәләй. Әсәрләр һәм хатлар / Төз.: Зөфәр Рәмиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 367 б.

Безнең мирас №7 июль 2017

СЕБЕР КИҢЛЕКЛӘРЕ ЯДКӘРЛӘРЕ

Фәнзилә Җәүһәрова, Гафур Сөнгатов

Хәзерге вакытта Европа дәүләтләрендә мәдәният белән идарә итә торган оешмаларның иң әһәмиятле юнәлеше булып халык авыз иҗатын, үз милләтенең борынгырак чорларга караган тормыш-көнкүреш үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнү санала. Мөмкин булганнарын яңадан гамәлгә ашыру кебек проектлар бу тармакларга караган иң әһәмиятле проблемалар рәтенә куела, чөнки Европа халыкларының рухи мәдәнияте тулысы белән юкка чыгу куркынычы, фараз кылулар чиген узып, аяныч чынбарлыкка әйләнде.

Бу яктан караганда безнең хәлебез дә Европа халыкларына якынлаша – татарларда бүгенге көндә халык авыз иҗатының күп кенә жанрлары бөтенләй югалып бара. Европа галимнәре Россия империясендә рухи мәдәният ягыннан иң бай булган төрки кавемнәрнең дә шул хәлдә калачакларын алдан ук белеп эш иткәннәр, рухи мәдәният үрнәкләрен көчләре җиткән кадәр киләчәк буыннарга да саклап калу юлына басканнар.

Шундый асыл затларның берсе – Вильгельм Фридрихович (Василий Васильевич) Радлов. Ул 1837 елда Германиядә Берлин шәһәрендә туа, яшьтән үк бик тырыш һәм сәләтле була. В.Радлов 1854 елны гимназияне уңышлы тәмамлап, Берлин университетының фәлсәфә факультетына укырга керә. Ул вакытларда мондый факультетларда тел, тарих, антропология фәннәре дә укытыла торган була. Төрле телләрнең килеп чыгышларына багышланган хезмәтләре белән дан тоткан, телләрне чагыштырма-тарихи өйрәнү фәненә нигез салучы мәшһүр Август Поттның лекцияләрен йотлыгып тыңлау Фридрихка гомерлек шөгыльне сайлап алырга этәргеч бирә. Шулай да аның нәкъ көнчыгыш телләр белгече булып китүенә, урал-алтай теориясен үстерүгә гаять зур өлеш кертүенә В.Шотт белән якын мөнәсәбәтләрдә булуы сәбәп була. Остазларының тел белеменең серле сәхифәләре турында сөйләгәннәре яшь егеткә бөтен тормышын, эшчәнлеген Россиянең Азия өлешендә яшәгән төрки халыклар, беренче чиратта, себер татарларының теле, тарихы белән бәйләргә дигән карарга килергә ярдәм итә.

В.В.Радлов 1858 елны, ул вакытта дөньяның иң атаклы Берлин университетын тәмамлаганнан соң, мәшһүр остазы В.Шотның Россиянең атаклы төрек телләр белгече О.Бётлингка шәкерте Фридрихка ярдәм итүләрен сорап язган хатын алып, мең бәлаләр белән Санкт-Петербургка килеп җитә. Аның иң зур хыялы Көнбатыш Себердә яшәүче, моңа кадәр фәнни яктан беркем тарафыннан да өйрәнелмәгән татарлар янына барып, аларның тарихы, теле, гореф-гадәтләре турында фәнни-тикшеренү эшләрен башлап җибәрү була. Ләкин ул вакытта ук инде рус хөкүмәте бу якларга чит ил кешеләрен кертмәскә тырыша. Тормыштагы иң бөек хыялын тормышка ашыру өчен ул, Германия ватандашлыгыннан баш тартып, Россия паспортын алырга мәҗбүр була. Вильгельм Фридрихович шул минуттан рус кешесенә әйләнеп, Василий Васильевич булып китә. Яшь егетнең мондый тәвәккәллеген рус җәмәгатьчелеге гаҗәпләнеп, тетрәнеп кабул итә. Бу хәлләрдән соң өч көн дә үтми, яшь галимгә Себергә юл ачыла һәм Европаның җылы табигатенә күрә җиңелчә генә киенгән Василий, атлы чанага утырып, Барнаулга юл тота.

В.В.Радлов кышларын Барнаулның һөнәр училищесында (хәзерге политехника институты тибындагы югары уку йорты) алман, латин телләрен укыту белән шөгыльләнсә, җәйләрен татар һәм башка төрки халыклар яши торган төбәкләргә фәнни экспедицияләр оештыра. Шушы экспедицияләрдә туплаган материаллар нигезендә В.В.Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи. Часть IV. Наречие барабинцев, Тарских, Тобольских и Тюменских татар» (Санкт-Петербург, 1872) китабы дөнья күрә. Әлеге хезмәт белән Россия тюркология мәктәбе, аерым алганда, татар фольклористика фәне башланып китә дип исәпләнә. Китапка себер татарларының әкиятләре, 680 юлдан торган 29 җыры, риваятьләре һәм дастаннары – барлыгы 121 әсәр кертелгән. Галимнең тууына 175 ел тулу уңаеннан бу күләмле хезмәтне 2012 елда Казан федераль университеты профессоры Ф.Ю.Юсупов Казанда бастырып чыгарды.

Кызганыч ки, В.В.Радловның әлеге китабыннан соң, аның принципларына нигезләнеп эшләнгән, ягъни себер татарларының халык әдәбияты әсәрләре җирле сөйләмдәгечә язып алынып, транскрипциядә бирелгән мәкаләләре

Вильгельм Фридрихович (Василий Васильевич) Радлов

дә басылмады, галимнең фидакарь эшчәнлегенә тиешенчә бәя биргән хезмәтләр дә дөнья күрмәде. Ниһаять, соңгы елларда бу өлкәдә алга китеш сизелде: Казан федераль университеты профессоры Фәрит әфәнде Юсупов галимнең тормышы һәм фәнни иҗаты буенча дистәдән артык фәнни мәкалә бастырып чыгарды, чит илләрдә һәм Россиядә үткәрелгән халыкара симпозиумнарда чыгышлар ясады.

Соңгы елларда, халыкларның аралашуы активлашу, аерым илләргә, төбәкләргә генә хас үзенчәлекләрнең җуела бару чорында, аларның рухи кыйммәтләрен барлау, өйрәнү, элекке

йолаларын, гореф-гадәтләрен, ышануларын, идеалларын ачыклау һәм аларга чагыштырып бәя бирү ихтыяҗы тагы да артты. Татар һәм башка төрки халыклар галимнәре-тикшерүчеләре бу юнәлештә шактый эш башкара. Филология фәннәре докторы, профессор, Төрек лингвистик җәмгыятенең мөхбир-әгъзасы Ф.Ю.Юсупов тарафыннан төзелеп бастырылган «Сибирские татары. Из сокровищницы духовной культуры. Антология фольклора сибирских татар: дастаны, мунаджаты, баиты. – Казань: изд-во Казанского ун-та, 2014. – 648 с.» исемле китап – шундый зарури һәм мөһим эшләрнең берсе. Фәрит әфәнде үзе туплаган һәм әлеге китапка керткән материалларның теркәлү вакытына игътибар итсәк, мөнәҗәт һәм бәетләрнең бер өлеше – XX гасырның 80 нче елларында, тагын бер өлеше 2010 нчы елларда язып алынганлыгын күрербез. Димәк, күп кенә төбәкләрдә әле буыннар чылбыры өзелеп бетмәгән, ул аерым фидакарьләрнең ихлас тырышлыгы, әби-бабалары мирасына булган мәхәббәте белән әлегә һаман яңартылып тора.

Эчтәлеген һәм төзелешен карауга ук, китап концепциясенең дөнья һәм төрки тел белеме казанышларын исәпкә алып һәм күпьеллык тәҗрибәгә таянып, яңача фәнни нигезгә корылган булуы турындагы фикер туа. Иң беренче шуны искәртү мөһим: бу хезмәт – себер татарларының халык әдәбияты әсәрләре туплап бирелгән беренче антология. Ул моңа кадәр бу өлкәдә яшәп килгән бушлыкны тутыруга зур адым ясавы белән дә үзенчәлекле, чөнки татар халкын оештыручы төп өч этносның – казан татарларының, мишәрләрнең һәм себер татарларының халык авыз иҗаты тупланган аерым антологияләре юк иде. Фольклор текстларының, В.В.Радлов хезмәтендәгечә үк, себер татарлары сөйләмендәгечә транскрипциядә бирелүе – китапның тагын бер зур әһәмиятле ягы. Бу себер татарларының рухи мәдәниятен саклап калуда мөһим чараларның берсе булып тора. Мондый алым, һичшиксез, алга таба нәшер ителәчәк хезмәтләрнең


ОПЫТЪ
СЛОВАРЯ ТЮРКСКИХЪ НАРѢЧІЙ.
В. В. Радлова.
ТОМЪ ПЕРВЫЙ.
ГЛАСНЫЕ.
VERSUCH
EINES
WÖRTERBUCHES DER TÜRK-DIALECTE.
VON
Dr. W. Radloff.
ERSTER BAND.
DIE VOCALE.
САНКТПЕТЕРБУРГЪ. 1893.

дә нигезендә ятарга тиеш. Төрки фольклористика буенча шөгыльләнә торган күп кенә галимнәр фольклор текстларын татар әдәби теленә тәрҗемә итеп бирүне бик гаҗәпләнеп кабул итәләр иде. Автор В.В.Радлов, Н.Ф.Катанов, Д.Г.Тумашева, Л.В.Дмитриева һ.б. кебек күренекле тюркологлар кулланган һәм хәзерге заман галимнәренә яхшы таныш булган рус академик транскрипциясеннән файдалана. Галимнәр арасында киң таралган транскрипцияне куллану текстларны укуны шактый җиңеләйтә. Мондый фәнни ысул халык авыз иҗаты әсәрләрен язып алынган вариантындагыча укырга, һәр сүзнең аһәңен билгеле бер сөйләштәге яңгырашта тоярга мөмкинлек бирә. Текстлар, юлга-юл тәрҗемә итеп бирелүләренә карамастан, рус телендә дә матур яңгырый. Моңа, һичшиксез, авторның себер татарлары диалектын яхшы белүе ярдәм иткән.

Китапның шактый өлеше себер татарларының килеп чыгышын, формалашу тарихын яктыртуга багышланган. Себер татарларын автор татар халкы оешуда катнашкан өч төп этник төркемнең берсе буларак карый һәм аларның Көнбатыш Себер киңлекләрендә б.э. кадәр үк яшәгән борынгы төрки кабиләләргә барып тота-

шуын, I меңъеллыкта дәвамлы рәвештә килеп торган сөннәр, кыпчаклар һ.б. белән катнашканлыкларын ассызыклый. Моннан тыш, гасырлар дәвамында себер татарлары Идел-Урал буйларыннан күчкән болгарлар, күрше башкорт, казакъ, нугай ырулары белән дә тыгыз аралашканнар. Аларның формалашуында төрле чорда, бигрәк тә Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, көнчыгышка таба күчә барган казан татарларының да роле зур булган. Ф.Ю.Юсупов Идел-Урал якларыннан килгән казан татарларының яңа авыллар нигезләве яки себер татарлары авылларында яшәп китүләре турында яза. Әлбәттә, аларның тиз катнашып, бердәй булып китүләренә бер телдә сөйләшүләре генә түгел, дин уртаклыгы да сәбәп булган. Ислам дине исә, Ф.Ю.Юсупов китабында күрсәтелгәнчә, болгарлар аркылы ук керә башлый. Моннан тыш, Себер ханнары соравы буенча Урта Азиядән махсус китертелгән ислам миссионерларының да эшчәнлеге зур була. Галим әлеге мәгълүматларны күп санлы тарихи-этнографик, мәдәни чыганакларга таянып китерә. Борынгыдан бер-берсенә якын кардәш ыругкабиләләрдән булган татарлар тубылиртыш җирлегендә мөстәкыйль рәвештә үз дәүләтчелекләрен булдыра алганнар, Рус дәүләте тарафыннан басылып алынганнан соң, алар гасырлар буена милли һәм дини изелүгә дучар ителгәннәр. Идел буе татарларыннан ерак яшәү, татар әдәби теленең тәэсире кимү дә (XX гасырның 60 нчы елларыннан татарча укыту туктатыла), себер татарларының бик киң таралып урнашуы да – әлеге кардәшләребезнең милли-мәдәни үсешен тоткарлаучы факторлар. Югыйсә, автор билгеләгәнчә, идел буе татарларындагы кебек үк, себер татарларында да терлекчелек һәм игенчелек эшләре алга киткән була, алар хәтта металл җитештерү белән дә шөгыльләнгәннәр.

Әлеге җыентыкта себер татарлары диалектларының төп фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре турында да мәгълүмат бар. Автор себер татарлары сөйләшләренең татар теленең урта һәм көнбатыш диалектларыннан аера торган төп классификация билгеләрен күрсәтә.

Китапта урын алган лиро-эпик әсәрләрнең зур күпчелеген дастаннар тәшкил итә. Заманында аларны беренче булып В.В.Радлов язып кала алган һәм үзенең мәшһүр «Халык әдәбияты үрнәкләре...»нә түмән, тара, тубыл, бараба татарларыннан теркәлгән 16 дастан керткән. Галим шул вакытта ук себер татарларында таралган дастаннарның күп төрки халыкларда сакланган шундый ук лиро-эпик әсәрләр белән охшаш булуын әйткән. XX гасырның икенче яртысында татар фольклорчылары Х.Ярми, Ф.Әхмәтова, Ф.Урманчеев, Х.Гатина, Л.Җамалетдинов, Н.Ибраһимов, Х.Мәхмүтовлар бөек галимнең эзләре буйлап экспедиция оештыралар һәм ул XIX йөздә дастаннар язып алган авылларда аларның күбесенең инде сакланмаганын күрәләр. Ф.Ю.Юсуповка да югалып баручы дастаннарның аерым өлешләрен генә язып алырга мөмкин була, шулай да бу өзекләр дә фән өчен гаять әһәмиятле материал булып торалар.

Дастаннар турында сүз алып барганда, автор-төзүче аларның нәкъ менә себер татарларында күбрәк таралуын һәм саклануын искәртә. Казан татарлары, төрки халыклар арасында гыйлемлерәк булып, язма мәдәниятне үстерүгә йөз тотканнар. Себер татарлары фольклоры соңгы дәвергә кадәр дастан жанрының аз күләмдә булса да сакланып килүе белән үзенчәлекле. Ф.Ю.Юсупов фикереннән аңлашылганча, моңа себер татарларының олы юллардан читтә, сазлыклы урыннарда, күлләр-елгалар арасында яшәп, үзләренең гадәти тормыш рәвешләрен дәвам иттерүләре, башкалар йогынтысын аз тоюлары сәбәп булган. Автор, дастаннарны максатчан тикшергән галимнәр фикеренә таянып (В.В.Радлов, Ф.В.Әхмәтова, М.И.Әхмәтҗанов, М.Х.Бакиров һ.б.), себер татарларыннан язып алынган эпик әсәрләргә жанр буларак күзәтү ясый, игътибарны материалның әһәмиятле якларына юнәлтә. Әйтик, дастаннарда, ислам традицияләре белән бергә, җирле

Фәрит Юсупов

гореф-гадәтләр, йолалар да чагылыш тапкан.

Төрле жанрларга караган әсәрләр турында мәглүмат бирү китапның азагында урнашкан «Искәрмәләр» бүлегендә дә дәвам итә. Биредә антологиягә кертелгән халык җәүһәрләренең кайчан һәм кем тарафыннан язып алынулары, вариантлары, русчага тәрҗемә итүчеләре һәм басылганнарының чыганаклары күрсәтелгән. Мәсәлән, «Караца» дастанына китерелгән искәрмәдә тәрҗемәче, җыентык авторы булган А.В.Преловскийның Карачаның рус елъязмаларында еш телгә алынуы турындагы фикерләре китерелә. Иң әһәмиятлесе – дастанның сюжет тамырлары VIII йөзгә караган, күп гасырлар үткәч В.В.Радлов тарафыннан өйрәнелгән һәм укылган борынгы төрки енисей каберташ язмаларына барып тоташуын күрсәтү. А.Преловский Карачаның ике яшь сугышчы улы үтерелгәннән соң хәсрәтен сурәтләү «Геройларга багышланган язмалар»да Билге каһанның энесе Күлтәгин үтерелгәч елавын тасвирлауга бик охшаганлыгын әйтә, әлеге ике әсәрне мең елга якын вакыт аерып торса да, аларның төзелешләре һәм кайгы-хәсрәт көчен, тирәнлеген чагылдырулары ягыннан бик якын булуларына гаҗәпләнүен белдерә. Галим: *«Борынгы шигырьләрне сүзгә-сүз саклау өчен халык хәтеренең никадәр көчле һәм ныклы булуы кирәк! – чыннан да поэзия мәңгелек!»* – дип язган.

Ф.Ю.Юсупов күрсәтүенчә, себер татарлары мөнәҗәтләре һәм бәетләре халкыбызның башка төбәкләрдә таралган әсәрләренә авазадаш. Себер татарларында таралган, Казан ханлыгының җимерелүе афәт буларак сурәтләнгән «Хан мәчет пәйет» кебек мисаллар татар милләтенең төрле этник төркемнәренең уртак тарихи язмышлы булуларын күрсәтә, рухи мәдәниятебезнең бер икәнлеген тагын да ныграк аңларга ярдәм итә. Йомгаклап әйткәндә, моннан йөзләрчә ел элек тә, хәзер дә халык аңын, күңелен чагылдырган, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, әчке кичерешләрен образлы сурәтләгән һәм кешеләрнең үз авызыннан көйләнгән җәүһәрләрнең китап булып дөнья күрүе халкыбызның мәдәният тарихын төрле юнәлешләрдә чагыштырып тикшерүгә бай, ышанычлы материаллар бирә. ■

Безнең мирас №7 июль 2017

КУРКЫНЫЧ ҺӘМ ХӘВЕФЛЕ ЕЛЛАР

Индус Таһиров

Бу илдә гасырлар дәвамында бетмәс-төкәнмәс гаделсезлекләр кылына килде. Шушы язмамда мин совет чорындагы репрессияләр турында сүз алып барырга ниятлим. Дөрес, алар хакында күп язылды һәм әле язылачак та, чөнки җәмгатьчелегебезгә төрле рәвештәге эзәрлекләүләрнең бик күбесе мәгълүм түгел. Ә бит бу афәтләр шаукымы миллионлаган кешене корбан итте.

Сәнәкчеләр хәрәкәтендә катнашучыларның репрессияләнгәннәренең генә дә саны 3 меңнән артык. Бу санга репрессиягә дучар булган тагын 800 совет хезмәткәре гаиләсен дә өстәргә кирәк. Болары – әле мәгълүм булганнары гына...

«Сәнәкчеләр» дип мөһерләнгәннәрнең исән калганнары да, хәтта аларның гаиләләре дә, гомер буе кыйналып, рәнҗетелеп яши.

Ә «кулак» мөһере сугылган, җәберләнгәннәрнең саны Татарстанда гына да 1 миллионнан артып китә. Динне, руханиларны эзәрлекләү – үзе бер аерым, әле дә булса аз тикшерелгән темаларның берсе. Совет чоры корбаннары булган муллаларның да язмышларын, ни кызганыч, тулысы белән белеп бетермибез.

Бу язмамда мин фәкать берничә фактка гына тукталам. Аларның берсе 1929-1930 елларны Буа кантонындагы хәлләргә бәйле. Менә ГПУ органының әлеге кантондагы Яңа һәм Иске Чүкәле, Иске Шәйморза, Татар Саплыгасы, Яңа Илмә, Каракитән һәм тагын берничә авылны үз эченә алган контрреволюцион оешма хакындагы 63 биттән торган белешмәсе. Анда контрреволюцион эштә катнашуда гаепләнеп кулга алынган 95 кешенең, тикшерү беткәнчегә кадәр авылларыннан беркая да китмәскә тиешле 13 кешенең һәм эзләү игълан ителгән 2 кешенең исемнәре теркәлгән.

Бу «эш», вакыты буенча, **Мирсәет Солтангалиев** икенче мәртәбә кулга алынып, аңа һәм «Мәскәү үзәге» дигән оешмага карата «эш» кузгату вакытына туры килә. Солтангалиев «эше» буенча күренекле мәгърифәтче һәм тарихчы **Һади Атласи (Атласов)** да кулга алына. Аны башта фәкать тумышы белән Буа кантонынннан булуы аркасында гына тоткарлыйлар. Ә инде соңрак бер гаеп өстенә икенчесен өя башлыйлар[1].

«Буа эшен»[*] тикшерүчеләр Казанда яшәгән буалыларны да онытмыйлар. Аларны бигрәк тә «Яңа китап» «эше» буенча гаепләнгән **Ибраһим Бикколовның**[**] һәм **Шиһап Әхмәровның** Солтангалиев белән булган элемтәләре кызыксындыра.

«Буа эше» Иске Задоровка ишаны **Әхмәтсафа Бикколов** исеме тирәсендә укмаштырыла. Бу турыдагы документта: «Аның тирәсендә күп еллар буе эшен дәвам иткән, авыл кулакларыннан, сәүдәгәрләрдән, дини фанатиклардан торган оешма булган», – диелә. Алар, имештер, оешмага үзләренең остазлары Сафа Бикколовка тугрылыклы булырга ант итеп кергәннәр[2].

Чыннан да, кем соң ул әлеге зур гөнаһларда гаепләнгән Әхмәтсафа Фәтхулла улы Бикколов? Ул 1854 елны Чүпрәле волостеның Яңа Задоровка авылында туган. Урта дини белем алган һәм утыз елдан артык вакыт эчендә халыкка дин вә мәгърифәт тараткан. Революцияне, халыкны җәберләгәне һәм динне кысканы өчен, танымаган. Курыкмаган, үз халкын гаделсезлекләрдән яклаган. Аны яратканнар, аңа тартылганнар. Өенә атна саен тирә-як авыллардан

[1] Архив КГБ, ф.109, д.2, л.318

[2] Архив КГБ, ф.109, д.2, л.318.

[*] Бу хакта «Безнең мирас»ның 2015 елгы 3 санынннан («Буа эше». Ә.Камалов, И.Әхмәтҗанов) укый аласыз.

[**] Ибраһим Бикколов хакындагы мәгълүматны һәм аның үз язмаларын журналыбызның төрле саннарыннан һәм www.beznenmiras.ru сайтыннан таба аласыз.

гына түгел, хәтта Чуашстан һәм Ульяновск округы крестьяннары да киңәшкә килә торган булган. Белешмәдә Солтангалиевне яхшы белгән һәм аның белән аралашып яшәгән **Санат Айнуллинның** һәм аның Буа кантонындагы бертуганнарының исемнәре дә искә алынган.

Бу документка ышансаң, шул очрашулар вакытында Татарстан, Башкортстан, Төркестан республикаларының берләшү мөмкинлекләре турында да сүз булган. Булгандыр, нигә булмасын, татарларны һәрвакыт тугандаш халыкларның язмышы кызыксындырып торган лабаса.

Сафа Бикколов бик күп гөнаһларда гаепләнә. Белешмәдә, тирәсенә кара һәм реакцион элементлардан Советларга каршы төркемнәр туплаганлыгы расланды, диелгән[3].

Анда шул төркемнәрнең берсен Сафа Бикколовның кызына өйләнгән Яңа Чүкәле авылы мулласы **Шакир Галләмов** җитәкләгәнлеге дә күрсәтелгән. Төркем 13 кешедән торган. Бу документта аларның һәрберсенә тулы характеристика бирелгән. Анда мулланың хатыны Сара Галләмовага, аның кызы Әминәгә дә урын табылган. Алар да Советка, күмәкләшү кампаниясенә каршы торуда гаепләнгәннәр.

Мирсәет Солтангалиев

Чыннан да, алар һәрвакыт Шакир Галләмов тирәсендә булалар. Хатыннар авылдан куылырга хөкем ителгән авылдашларын, муллаларны, мәчетләрне саклап калуны яклап чыгалар.

Татар Саплыгасында авылдашларын сөргүгә каршы көрәшне дә хатын-кызлар башлап җибәрә. 1930 елның 3-4 гыйнварында **Мәрфуга Вәлиханова**, **Мәликә Хәйруллова**, **Нурлыгаян Кәлимуллина** һәм тагын берничә хатын, өйдән-өйгә йөреп, хатын-кызларны авыл Советына җыелышка чакыралар. Халык җыелган арада, Вәлиханова Совет председателе Хәмидуллинга, өстәлгә суга-суга, болай ди: «Мәчетне алдыгыз, колхоз булдырдыгыз, безне талыйсыз, бетсен колхозыгыз! Бездә байлар да, ярлылар да юк. Барыбыз да – бертигез!» Шул арада җыелган 30-50 хатын аның сүзләрен «Долой Советларны!», «Долой колхозны!», «Ура!» авазлары белән хуплап торалар[4].

1929 елның декабре – 1930 елның башында Югары Каракитән авылында коммунистлар мәчетнең манарасын кистерәләр. Моңа каршы төшеп, мәчеткә халык җыела һәм манараны коммунистларның үз хисабына янәдән торгызырга, дигән карар кабул ителә. Җыелышны алып баручы А.Хи-

[3] Архив КГБ РТ, ф.109, д. 2,л.45.
[4] Шунда ук, 368 бит

саметдинов сүзен болай дип башлый: «Крестьян халкына бернинди яхшылык та эшләми торган бу власть кайчан бетәр икән?! Бетүгә күп калмады. Менә шунда инде без ул коммунистларны нишләтергә кирәклеген белербез!». Һәм ул, халыкка мөрәҗәгать итеп, сүзен болай бетерә: «Мин дөрес әйтәмме, җәмәгатъ?!» Моңа җавап буларак: «Дөрес, дөрес!» – дигән авазлар яңгырый. Шул арада коммунистларны үтерергә чакырган өндәмәләр дә таратыла.

Илдәге хәрәкәт белән яхшы таныш булган Әхмәтсафа Бикколов авылдашлары алдында Советларның гаделсезлекләре турында чыгышлар ясый торган булган. Менә шул чыгышларның берсеннән өзек: *«Динебезнең иреге буылу чоры килеп җитте. Соңгы вакытта дини мәктәпләребезнең ябылуы, дингә тугры кешеләрнең кулга алынулары, авыл хуҗалыгы һәм подоходный налоглар белән буулар, көчләп облигацияләр тарату, халыкның икмәген талаулар – күз алдыбызда. Боларга каршы без нәрсә дә булса эшләдекме? Дөресен әйтергә кирәк, без йокладык. Моннан болай без түзеп торырга тиешбезме? Әгәр дә без Совет властеның шушы эшләренә каршылык күрсәтмибез икән, Аллабыздан баш тарткан булабыз. Без дин кардәшләребезгә шушы этзәрлекләүләр турында аңлатырга, аларның миләренә моңа каршы торырга кирәклеген сеңдерергә, барлык мәхәлләләрнең бергә булу кирәклеген аңлатырга тиешбез»*.

Фактлар Советларның шушы сәясәтенә каршылык күрсәтүнең ни дәрәҗәдә киң таралуы турында сөйли. Коммунистларны һәм комсомолларны аноним рәвештә куркыту очраклары, өндәмәләр тарату фактлары да ачыклана. Шул аноним куркытуларның берсе Ульяновск округындагы «10 төркеме»неке була.

Әхмәтсафа Бикколовның боларга турыдан-туры катнашы булмаса да, барлык гаепне аның өстенә өяләр. Гаепләүчеләр нигәдер бу вакыйгаларның аның туган авылында түгел, ә күрше Яңа Чүкәледә булуын да искә алырга теләмиләр. Ә бит анда инде яңа хакимияткә каршы тору кораллы төс алган була.

Җыелышларның берсендә **Шәрәф Фәхретдинов**, коммунистларга ишарәләп, болай ди: «Белеп торыгыз, сез авылыбызда колхоз төзи алмаячаксыз. Сталин белән Калинин үзләре килсәләр дә, үлсәк – үләрбез, аларга сәнәкләр белән каршы чыгарбыз».

Күрше Иске Шәйморза, Татар Саплыгасы һәм башка авыллардагы вакыйгалар да шуңа охшаш төс алган. Авыллар арасындагы элемтәне мулла Шәрифҗан Абитов җайлап җибәргән.

Башка авылларда да Советларга, колхозлаштыруга каршы хәрәкәт киң тарала. Яңа Ишлән авылында Советларга каршы төзелгән, башында **Габделәхәт Шәрифҗанов**, **Бари Ногманов** һәм **Нургали Гарифуллов** торган яшерен яшьләр оешмасы барлыкка килә. Мәчетне мәктәпкә бирүгә каршы оештырылган җыелышта Шәрифҗанов болай ди: «Без шушы мәктәптә укыдык. Безгә ул бик тә җитә иде. Ә хәзер менә, нигәдер, аңарга мәчет кирәк булган. Әгәр дә Совет властена мәктәп кирәк икән, ул аны үзе төзесен, ә без мәчетне мәктәпкә бирмибез!»[5]

Шушы һәм башка авыллардагы Советларга, колхозлашуга каршы хәрәкәт җитди төс ала. Боларның барысында да Әхмәтсафа Бикколовны гаеплиләр. 1930 елның 30 гыйнварында аны кулга алалар. Аның артыннан башка муллаларга һәм активистларга да чират җитә. Муллаларны кулга алырга җибәрелгән оператив хәрби төркемгә каршы чалгы, сәнәк, балта белән коралланган халык күтәрелә. Аларның башында **Шакирә Гәлләмова** җитәкчелегендәге авыл хатын-кызлары була.

Бикколов эше буенча 5 кеше 10 елга сөргенгә озатыла. Аларның язмышлары билгесез. Әхмәтсафа Бикколовның үзен атып үтерәләр.

Шакирә Галләмованың һәм ике кызының да язмышы билгеле түгел. Ләкин, ничек кенә булмасын, алар да – шушы ачы язмыш корбаннары...

Ахыры бар ■

[5] Шунда ук

Күренекле әдәбият галиме, тюрколог-шәркыять белгече, әдәби тәнкыйтьче, педагог, текстолог, җәмәгать эшлеклесе һәм дистәләгән мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслеге авторы Хатип Йосыф улы Миңнегуловның шушы көннәрдә рус телендә «Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей» (Х.Миннегулов. Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей (Монография). – Казань: Изд-во «Ихлас», 2017. – 360 с., с фотоиллюстрациями) дигән монографиясе дөнья күрде. Энциклопедик гыйлемгә ия булган галимнең фундаменталь хезмәте шушы юнәлештә дистә еллар буена фидакарьлек белән алып барылган гыйльми эшчәнлегенең нәтиҗәсе булып тора.



Олуг мирас эзеннән

Таһир Гыйлаҗев

Хезмәт структура-композиция һәм тема ягыннан бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән ике кисәктән тора. Беренче өлештә масштаблы һәм аналитик фикерләүгә сәләтле Х.Миңнегулов мең елдан да артык бай тарихы булган татар әдәбиятының үсеш баскычларын аерып чыгарып, аларга кыскача күзәтү ясый. Һәр этапның төп закончалыклары һәм сыйфатлары шул чорның алтын баганалары булган язучы-шәхесләр, әйтик, XIX гасыр Г.Кандалый, К.Насыйри, Ш.Зәки, М.Акмулла иҗатлары мисалында ачыла. Татар әдәбият фәнендә генә түгел, ә төрки халыклар һәм дөнья әдәбиятлары тарихында да аерым әдәби күренешләрне өйрәнүдә һәм бәяләүдә, аек акыл үлчәвенә салмыйча, вакытлы хис белән эш итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән берьяклы мавыгуларга, субъектив моментларга зур тәҗрибә туплаган әдәбият тарихчысының кыю һәм гадел мөнәсәбәте укучыны сокландыра. Галим әдәби ядкәрләр-әсәрләрнең, нинди генә чорда булмасын, язучылар тарафыннан үз кавем-милләттәшләренең эчке ихтыяҗлары һәм аларга хезмәт итү идеалы ноктасыннан иҗат ителүе хакында нәзари гомумиләштерү ясый. Х.Миңнегуловның милли сүз сәнгате, шәрык әдәби-мәдәни диалогында каралган монографик эзләнүләреннән аермалы буларак, китапның икенче бүлегендә татар әдәбиятының төрки халыклар әдәбияты белән күпгасырлык бай һәм киңкырлы бәйләнешләры җентекле шәрехләнә, шушы уңайдан төрле милли әдәбиятларның зур чорлары иңләнеп алынган материалда төрки әдәбиятларның корифейлары-сүз осталары – Әхмәт Ясәви, Габдулла Тукай, Абай Кунанбаев, Мәхтүмколый, Чыңгыз Айтматов һ.б.лар иҗатлары әдәби-эстетик һәм фәлсәфи планда яктыртыла. ■



ТАТАРЛАРНЫ ҮТЕРҮ ВӘ МӨСЕЛМАННАРНЫ БЕТЕРҮ СӘЯСӘТЕ ТАРИХЫ

Ләбиб Сәлим

*26 май көнне язучы, тарих фәннәре кандидаты **Фәүзия Бәйрәмова** шәхси архивында моңарчы сакланган тарихи материалларны Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә тапшырды. Алар арасында Берлинда Гаяз Исхакый тарафыннан нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналы да бар. Журналның берничә еллык төпләнмәләре Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең «Татар мөһаҗирләре коллекциясе»ндә урын алды. Игътибарыгызга журналның 1930 елдагы май санында басылган бер мәкаләне тәкъдим итәбез.*

Казан ханлыгын барлыкка китерүче Олуг Мөхәммәд хан Алтын Урда ханы булган чакта, ягъни урысларның татарларга көче йитмәгән бер вакытта, урысларда үзләрен коткарырлык кына да көч юк иде. Хәтта урыс кенәзләре үзара сугыш, талашып бозылышкан заманда, кычкырышлы эшләрен хаклау өчен, Алтын Урда ханнарына хөкемгә киләләр, ханның дигәне буенча шау-шуларын бетерергә тиешле булалар иде. Урыс кенәзләреннән Василий илә Юрий олуг кенәзлек өчен кычкырышып, үзара бу эшне төгәлли алмагач, ул вакыт Алтын Урда ханы булган Олуг Мөхәммәд янына хөкемгә килгәннәр иде. Василий 1431 нче елның 15 нче августында, Юрий өч атна соң, 8 нче сентябрендә Сарай шәһәренә таба юлга чыгып, икесе дә Алтын Урда ханының күңелен табар өчен ялагайланып, хан тирәсендәге зуррак түрәләрнең күңелен табарга тырышып, бер елга якын тарелка тотып ялварып яттылар. Иң соңында Олуг Мөхәммәд хан Василийны олуг кенәз ясагач, 1432


ئويسز — عائيله،
ئيلسز — ميللەت،
ميللەتسز — دەولەت
يەشى آلمى

بر حالق
ئوز ئيلى بولغانداغنا ئوز دەولەتن قورا آلا

تارتشدا
بر بولب اويشقان حالق
هەم
بر بولب برلەشكەن ئيلگنه
جيڭب چغاچاق

حالقڭنى تانى !

ئيلڭنى ئويرەن !

Chefredakteur und Herausgeber: A. Ishaki.
Verantwortlich für Verlag und Redaktion: Ernst Kiesewetter, Berlin SW 29, Fürbringer Straße 26.
Druck: Buchdruckerei Karl Schulz, Charlottenburg 1, Schul-Straße 3. Tel. C 4 Wilhelm 8894.

Өйсез – гаилә, илсез – милләт, милләтсез дәүләт яши алмый. Бер халык үз иле булганда гына үз дәүләтен кора ала. Тартышта бер булып оешкан халык һәм бер булып берләшкән ил генә җиңеп чыгачак. Халкыңны таны! Илеңне өйрән!

нче елның июнь ахырында Русиягә кайтып киттеләр.

Менә шул ук кешеләрнең бер-берсенә каршы мөнәсәбәтләре биш елга соң нинди күп үзгәргән була. Чөнки 1437 нче елда Олуг Мөхәммәд хан Кечкенә Мөхәммәд тарафыннан Алтын Урда ханлыгыннан куылган вә урысның шул ук Олуг Мөхәммәд тарафыннан олуг кенәз ясалган Василийсы урынын шактый ныгытып зур вә көчле бер патша булган иде. Олуг Мөхәммәд хан өч мең кадәр янындагы чәрисе[1] берлә Дон елгасы буенда күчеп йөреп, урысларның Белёв шәһәренә кышларга дип кергәч тә, урыслар аны куып чыгарырга 20-30 мең чәри йибәрделәр. Шулай да булса, һавалы Олуг Мөхәммәд хан кичәге үзенең колларыннан тиз генә өркеп китмәде. Баштанаяк чын мөселман булган ул мөбарәк хан, ике рәкәгать намаз кылып, Тәңрегә дога иткәннән соң, үзенең бар көче берлә урыслар берлә сугышыр өчен атына менгән чагындук, урыс чәрисе куркуыннан тетри башлады. «Бисмилла», «Аллаһу әкбәр!» – дип кылычын селтәп, урыслар өстенә һөҗүм итү берлә тегеләр кача башлады. Татар исемен хөрмәт итеп өйрәнгән урыс колларының, бөтен дөньяга гайрәте берлә танылган татар чәриләре берлә буй үлчәшүе мөмкинме иде? Бер көнлек сугыш соңында урыслар җиңелеп, качып беткән иде.

Шуннан соң Олуг Мөхәммәд хан ул тирәләрдән тагы да төньяккарак китеп, әлеге Казан шәһәре янына килә. Анда урысларның талавыннан бизар булган йирле халык, Олуг Мөхәммәд ханның килүенә сөенеп, бик тиз аның янына җыйналалар. Шулай итеп, Олуг Мөхәммәд хан тагы үзендә көч тапкач, ашаган табагын пычраткан урыс олуг кенәзе Василийның әдәпсезлегенә ачуы килеп, аңа бераз тәрбия бирергә теләде. Угылы Мәхмүд командасында чәри җыйнап, Мәскәүгә каршы сугыш ачты. 1445 нче елның 7 нче июлендә булган бу сугышта Василий җиңелеп, Олуг Мөхәммәд ханга тоткын төште. Ләкин, бәхетсезлеккә каршы, ул начар еланны шунда үтермичә, азат итеп зур ялгышлык ясыйлар. Чөнки урысларны бер кулга җыйнап, бер дәүләт хәленә китергән вә көчле һәм дә татарларга каршы бик дошман бер урыс дәүләте ясаган кеше шушы Василий булды. Әгәр ул кеше юк ителгән булса иде, Русиянең эчендә зур кенәзлек тартышы берлә балта-пычак килеп торучы төрле кенәзләр, үзара кычкырышлары вә бер-берсе берлә сугышлары сәбәпле, көчле бер Русиянең тууына тагы бераз ирек бирмәячәкләр иде. Менә шушы Василий заманыннан бирле татарларны вә Казан ханлыгын юк

[1] Чәри – чирү, гаскәр.



۱۹۳۰ نچی یل

طوتقان یولبزعه اوحشاعان یازولارنی قوانچ برله باصابز. باصلماعان یازولار کیری قایتاریلماسلار.

باش محرری: عیاض اسحاقی بك

یاڭا

ملی یول

۱ نچی نویابر

„MILLI YOL"
Nationaler Weg

آبونه شرطی: بر یللعی ۳,۵ دوللار یارتی یللعی ۲ دوللار

بره ملهب ۱۵ سەنت

صاده ۱۱ — ایدل اورالنك قونولوینه یاردەم اینكەده توشونچه و خبرلرنی بازاتورغان آیلق مجموعەدر — یل ۲

« ملی یول »

ملی یول : اوزینك اوچونچی یلینه کرەدر . ایکی یل بوینچا مجموعەمزنی هیچ بر کون کیچکدرمەینچه ، سەعەتی سەعەتنده چعارب کیلدك . کیلەچەكدەدە شولای باراچاقمز .

ملی یول : ایکی یل بوینچا اوزینك مەسلەگندەن آزعنەدا تایپلمیچا ، میللی دەعوالرمزنی آلب کیلدی . اوچونچی یلندادا شول مەسلەگندەن آیرلماینچا دەوام ایتەچەكدر .

ملی یول : ایکی یل بوینچا اوزمزنك میللی دوشمانلارمزنك یەشرین یوزلەرن آچب ، یالعانلارن مەیدانعه چعارب کیلدی . اوچونچی یلندادا شول أزدەن باراچاقدر .

ملی یول : ایکی یل دەوامده آچق و یابق ایسملرده یازا تورعان بیك کوب ایمانلی محررلرمزنی تیرەسینه توپلادی . اوچونچی یلندادا بو أشنده دەوام ایتەچكدر .

ملی یول : دونیانك جیدی پوچماعنه تارالعان میللەتچی مهاجرلر آراسندا ، برسن برسینه تانشدرا تورعان بردەن بر مەجموعه بولوب کیلدی . اوچونچی یلندادا شول یولدا بارب ، تورلی یردەگی قالونیالارمزنك طورموشندان حەبەر و مقالەلرنی نەشر ایتب باراچاقدر .

ملی یول : قارت بووننی یواتوچی ، یەش بووننی میللی رەوشده تەربیه ایتوچی بردەن بر میللی مەجموعەدر . آنك دەوامی ، اچندەگی یازمالارینك بای بولوی ، بتون مهاجرلرنك قیممەتنی زورایتا ، روحنی کوتەره تورعان بر أشدر . شونك اوچون بتون مهاجرلر « ملی یولنك » ماددی و مەعنەوی آلعا کیتوینه طریشورعه تییشدر . قوللارندان کیلگەنلری قەلەم برله ، قوللارندان کیلگەنلری آبونه جیبەرب ، باشقالاردان آبونه جییب یاردەم ایتەرگه تییشدر . « ملی یولنی » کوب اوقوتو ، کوب تاراتو هەر میللەتچینك بورچیدر .

میللەتچی قەردەش ! بردەن بر « ملی یول » مەجموعەسن اوقو !

میللەتچی قەردەش ! چیت ایللرده میللی بایراقنی توشرمیچه آلب باروچی بردەن بر « ملی یولنی » ایبدەشلرىڭه ، تانشلارىڭا اوقوت !

میللەتچی قەردەش ! میللی دەعوامز اوچون بردەن بر طریشوچی ، تارطیشوچی « ملی یولنی » کوبلەب تارات ، آبونه یازدر !

میللەتچی قەردەش ! میللی وظیفەڭنی آڭلا !

« ملی یول » باشقارماسی .

«Милли юл» – карт буынны юатучы, яшь буынны милли рәвештә тәрбия итүче бердәнбер милли мәҗмугадыр

итү сәясәте йөртелә башлый. Бик озын гомерле вә акыллы булган бу Василий иң элек Русияне бер кулга җыйнап көчле бер дәүләт корганнан соң, 1461 нче елдук Казан өстенә йөрер өчен зур чәри җыйнап юлга чыга. Әле ул вакытларда Казанның көчле чагы булса да, Василийга илчеләр йибәреп, бу сугышны булдырмыйча калалар.

1462 нче елда Василий үлеп, аның урынына угылы Иван (өченче) олуг кенәз булды. Менә Казанны бетерү, татарларны юк итү сәясәте шушы өченче Иван заманында башлана. Әлдә чукындыру сәясәте башланмаган иде. Ләкин бу чукындыру вә урыслаштыру сәясәте татарларны бетерү сәясәтенең бер нәтиҗәсе булып чыкты. Чөнки сугышларда тоткын ителгән татарлар, ул заманның башка дәүләтләрендә булган төсле авыр эшләрдә генә кулланылмый, туп-туры үтерү нияте берлә камакларга (зинданга) ябыла иде. Ач, сусыз вә һәртөрле башка кыенлыклар берлә җәзалап, әллә нинди вәхшилекләр берлә азаплап үтереләләр иде.

Соңыннан урысларның дин башлыклары аларны чукындыру юлын таптылар. Үләргә дә, котылырга да ирке булмаган бичара тоткыннар өчен чукынудан башка юл калмый иде. Беренче мәртәбә татар зурларыннан ханзадә Ходайкол чукындырылды вә Петр исеме бирелде. Ходайкол – Казан ханнарының Олуг Мөхәммәдтән соң дүртенче булган Ибраһим ханның угылыдыр. Мөхәммәд Әмин хан Казанга хан булыр өчен урыс чәриләре берлә килеп, Илһам ханны вә бөтен туганнарын (Ходайкол, Миңлетаһир) вә хатын, бала-чагасын тоткын иткәч, урыслар аларның һәммәсен дә Мәскәүгә алып киткәннәр иде. Өченче Иван аларның барсын да камакларга яптырып бик авыр азаплады.

Һәр кешенең диндәге ныклыгы вә чыдамлыгы бертөсле булмый бит, бигрәк тә өйләнмәгән, яшьрәк кешеләрне кызыктыру да, куркыту да җиңел була. Илһам хан берлә кардәш Миңлетаһир өйләнгән вә бала-чагалы булганга, алар бөтен азапларга түзә алса да, Ходайкол йитешкән егет булганга, аны бер яктан азапласалар, икенче яктан урыс патшасының кызын бирү берлә кызыктыралар иде. Иң соңында өченче Иванның угылы Василий заманында, 1505 нче елда Ходайкол чукындырылып, өченче Иванның кызы берлә өйләндерелде. Аның чукыну вакыйгасы ничек булганын күрсәтер өчен, Ходайколның үзе кул куйган бу тарихи язуның кайбер йирләрен күчерәм: *«...минем патшам Олуг кенәз Василий Иванович митрополит Семёнга мине чукындырырга кушты. Мин, ханзадә Петр, шушы хак диндә бик нык булып, ахыр гомеремәчә аңардан күчмәскә, Василий Ивановичка вә аның балаларына хезмәт итеп, аларга яхшылык теләргә, һәр эштә туры булып, аларга начарлык теләмәскә, кылмаска вә уйламаска һәм дә ул хакта һичкем илә хәбәрләшмәскә, патшалык зарарына тырышучыларның һичбере илә дустлашмаска, Казанга,*

Литвага ахыр гомеремә чаклы китмәскә, патшам хакында татардан, Литвадан яхшы-яман бер хәбәр ишетсәм, кенәз Василийга вә аның балаларына һичбер хәйләсез, яшермичә ирештерергә, Казан яисә Литва кешеләреннән, кем дә булса бирәүдән яисә Казан ханы булган туганымнан бер ярлык берлә килүче булса, аны ярлыгы илә тотып, патшам олуг кенәзгә тапшырырга...» Менә бу язу шушы чукынуның (христианлашу) нинди рәвештә булганын бик ачык күрсәтә. Монда бер дә православный диненең хаклыгы роль уйнамаганлыгы күренеп тора. Миңлетаһир үзе ислам динендә улса да, үзеннән соң аның хатынын вә балаларын көчләп чукындырдылар. Аның ике угылы Василий вә Федор дип исемләнде.

Мөхәммәд Әмин хан урыс көче берлә Казанга хан булган булса да, аның атаана бертуганы Габлеллатыйф камакта ята иде. Мөхәммәд Әминнең Казан ханлыгыннан куылганы чагында Казанга хан ителгән Габделлатыйф, Мөхәммәд Әминнең икенче мәртәбә Казан ханы булганында, Казан тәхетеннән туры урыс камагына атылды. 7 ел ябылып ятканнан соң, анасы Нурсолтан бикәнең тырышуы вә үгәй атасы – Кырым ханы Миңлегәрәйнең үтенүе буенча, олуг кенәз Василий Габделлатыйфны 1505 елда азат иткән булса да, 1512 елда Кырым ханының Мәскәүгә һөҗүме сәбәпле, тагы тотып ябылган иде. Бичара тагын биш ел тоткын яткач, Казан ханы Мөхәммәд Әминнең үтенече буенча, яңадан 1516 елда азат ителсә дә, азап, каһәр эчендә бик җончып вә картаеп беткәнлек сәбәпле, күп яшәмәде. Бер елдан соң – 1517 нче елда үлеп котылды.

Урыс патшалары вә урысларның татарларны үтереп яисә чукындырып бетерү вә дөнья йөзеннән юк итү сәясәтендә никадәр каты вә аяусыз булганлыкларын күрсәтү өчен, түбәндәге вакыйганы хикәя итү үзе генә дә җитә. Кирәк казан вә кирәк кырым татарларының каршы сугышулары вә кирәк Казан ханлыгын бетерешүдә вә иң соңында урысларга Казанны бөтенләйгә алып бирешүдә урыстан күп хезмәт иткән Касыйм ханы Шаһгалигә каршы Мәскәү Олуг кенәз Василийның кылганын вә Шаһгалинең багынчыклары булган татарларга эшләгән коточкыч усаллыкларын шунда сөйләп китик. Касыйм ханы Шаһгали бер мәртәбә генә Василийдан рөхсәтсез Казан татарларыннан хат алган вә аларга җавап язган иде. Шуңа ачуланып, кенәз Василий, 1533 нче елда Шаһгалине дер селкетеп, ханлыктан төшереп, хатын, бала-чагасы берлә Белозер шәһәренә *(бу шәһәр искедән бирле татар ханнарының, Илһам ханның, туганы Миңлетаһирның вә Габделлатыйф ханның тоткын-камакта яткан шәһәредер)* камакка салды. Шаһгалинең янында булган түрәләреннән, чәриләреннән вә багынчыкларыннан бик күпләрен төрле шәһәрләргә йибәреп, камакларга япты. Новгород камагында булган вә бер гөнаһсызга ябылган 80 татарга бик авыр азаплар ясалып, барысы да үтерелде. Псков шәһәре камагында 73 татарның сигезе яшь балалар иде. Боларның күбесе бер тәүлек эчендә үтерелеп тышка ташланды. Ул көн үтерелми тере калган 8 татарга бер кабым ашарга вә бер тамчы эчәргә бирмичә, ачка вә сусызлыкка үтерелде. Хәсән исемле берсе генә хатын вә бала-чагасы берлә бергә чукынып үлми котылды. Новгород вә Псков шәһәрләрендә үтерелгән татарларның хатын вә балалары башка камакларда иде. Аларның барысы да көчләп чукындырылды вә хатыннары урысларга иптәшлеккә бирелде. 1536 елда Новгородта 43 хатын вә 36 бала чукындырылды. Псковта – 51, Орешекта – 12, Корелда 30 татар хатыны вә балалары көчләп чукындырылды вә урысларга таратылып бирелде.

Дәвамы бар ■

ЯРАТУ ҺӘМ ТУГРЫЛЫК

Әлфәт Закирҗанов

Хәзерге татар драматургиясендә төрле буын авторлар иңгә-иң торып, тәҗрибә алмашып хезмәт итә. Сәхнә әдәбиятында үз сүзен әйтеп, аны җитди яңалыклар белән баеткан өлкән буын әдипләр Р.Батулла, Р.Хәмид, М.Маликова, Ф.Садриев, Ә.Гаффар һ.б. янәшәсендә 1980 нче елларда әдәбиятка килгән Р.Зәйдулла, Л.Лерон М.Гыйләҗев, Д.Салихов, Р.Сәгъди, Аманулла, З.Хәким, Ф.Галиев, Ш.Фәрхетдин, Г.Каюмов, Р.Сәлимҗанов һ.б. актив иҗат итеп, бүген инде әдәбиятның әлеге төрен әйдәп баручылар булып танылды.

Әдәбиятка һәркем үз юлы белән килә, табигать биргән талантына, тырышлыгына нисбәтле әдәби-эстетик эзләнү-өйрәнү алып бара. Тормышяшәешнең күптөрлелеген уңышлы сәнгати эзләнүләр, җитди табышлар, яңа сурәтләр, жанр формалары белән баеткан авторлар арасында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рәдиф Сәгъди дә бар. Киң катлау укучылар аны прозаик һәм драматург буларак яхшы белә. «Канга буялган алтыннар», «Гаилә сурәте», «Кыйммәтле килешү», «Алло, хәлләр ничек?» детектив повестьлары, «Ике кояшлы дөнья» исемле фантастик романы, «Ирдәүкәләр» әсәре белән ул эпик төр үзенчәлекләрен яхшы үзләштергән, заманның гыйбрәтле, җитди сорауларына сәнгать чаралары ярдәмендә җавап эзләүче язучы буларак танылу ала. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге җитди тикшеренүгә лаек. Әмма безнең сүзебез Р.Сәгъдинең драматургиясе турында.

Мәктәп елларында ук театр студиясендә шөгыльләнү Рәдифне Казан театр училищесына алып килә. Әлеге уку йортын тәмамлагач, ул Әлмәт һәм Казандагы К.Тинчурин исемендәге театрларда артист булып эшли. Күңеле әдәби иҗатка тартылган яшь егет студент елларында ук беренче пьесаларын яза. Алдагы елларда ул заман мәсьәләләренә кыю мөрәҗәгать итеп, замандашның рухи дөньясына, күңел кичерешләренә гаять игътибарлы, сәхнә закончалыкларын яхшы белүе белән аерылып тора, остазы Р.Хәмид язганча, «балалар өчен әкият таулары төзегән» драматург булып таныла. «Баһадурның бәхете», «Баһадурның яңа дуслары», «Гүзәл Аппаксылу», «Иске курчакларда Яңа ел», «Ана күңеле балада...», «Соңгы шүрәле» дигән әкиятпьесалары, тамашалары сәхнәләрдә уңыш белән куелып, җәмәгатьчелектә киң яңгыраш ала. Аның төрле татар театрлары сәхнәсендә куелган «Сынган беләзек», «Бакчасарай гөлләре», «Алсу томан», «Финляндиядә рәхәт, ди», «Кызлар кайтмый авылга» һ.б. спектакльләре уңыш казана. Әлеге һәм башка пьесалары тупланган (арада «Яз галәмәте» комедиясе, «Ирләр яуга киткәндә», «Кыргын» тарихи драмалары һ.б. бар) «Гүзәл Аппаксылу» (2012) һәм «Сынган беләзек» (2015) җыентыклары, Татарстан китап нәшриятында басылып чыгып, киң катлау укучыларга барып иреште.

Р.Сәгъди – сәхнә әдәбиятының иң авыр тармагында – балалар өчен пьесалар язуда танылу алган аз санлы авторларның берсе. Әйе, бу өлкә язучыдан, тырышлык белән бергә, бала психологиясен һәм физиологиясен яхшы белүне, бала дөньясын даими өйрәнүне таләп итә. Балалар өчен язылган пьесалар ялганны, ясалмалылыкны кабул итми. Бу төр әсәрләр, тормышчан булу белән бергә, сабыйның рухи дөньясына йөз тотып язылуы, яшь укучы-тамашачыны әлеге вакыйгаларда яшәтүе белән дә аерылып тора.

Р.Сәгъдинең нәниләр өчен язылган әсәрләре бертөрле генә түгел: берләрендә, яшәешнең җитди мәсьәләләре балалар психологиясенә, аларның теләкомтылышына бәйле куелып, балалар өчен генә түгел, ә зурлар өчен дә гыйбрәтле вакыйгалар аша ачыла һәм гаять җитди уйлануларга китерә, икенчеләрендә исә балалар тормышына хас хәл-күренешләр уен, тамаша формасында тәкъдим ителә. Беренче төркем әсәрләр арасында «Гүзәл Аппаксылу», «Ана күңеле балада...» пьесалары аерылып тора.

Р.Сәгъдинең балалар өчен язылган «Гүзәл Аппаксылу» пьесасында, халык авыз иҗатының гаять киң таралган һәм яратып укыла торган жанрларыннан берсе булган әкиятләргә хас булганча, фантастик күренешләр, маҗаралы вакыйгалар сурәтләнә. Сәхнә өчен язылган әсәрдә персонажларның көрәш-бәрелешенә, үзара мөнәсәбәтенә нисбәтле рухи дөньяларын, күңел кичерешләрен ачуга да киң урын бирелә. Ә инде вакыйгахәрәкәтнең җыр-музыка белән кушылып китүе эмоциональ тәэсирлелекне тагы да арттыра, хәл-күренешләрнең укучытамашачы күңелендә тирән эз калдыруына, андагы шатлык-кайгыны үзенеке кебек хис итәргә, шулар тәэсирендә булырга, спектакль дәвамында әлеге

«Сычуанның мәрхәмәтле кешесе» (Б.Брехт) спектакленнән күренеш. Сулдан икенче – Рәдиф Сәгъдиев Өлкән абзалары ролендә. 1981 ел

геройлар белән «яшәп» алырга җирлек тудыра. Сюжетка салынган вакыйгалар түбәндәгедән гыйбарәт: Таңбатыр белән Аппаксылу бер шәһәрдән икенчесенә барган вакытта, кызның гүзәллеген күреп, аңа Дию пәрие гашыйк була һәм аларны адаштыра. Таңбатыр үзенең көче, гаскәре белән мактана, халык телендә йөргән дию-пәриләрне хурлый, кимсетә. Шуларга ачуы чыккан Дию пәрие Аппаксылуны урлап китә.

Пьесада вакыйгалар үзара тыгыз бәйләнгән әхлакый һәм фәлсәфи яссылыкларны иңләп үтә. Сүз сәнгатенең төп максат-вазыйфасы һәм әсәрнең балалар өчен язылуы әхлакый катламны, билгеле инде, алгы планга чыгара. Ул исә әсәрнең төп конфликтын тәшкил иткән яхшылык һәм явызлык көрәшенә нигезләнә һәм Таңбатыр белән Дию пәрие каршылыгында ачыла. Әлеге геройлар янында тарафдарлары туплана. Бер мөһим үзенчәлеккә игътибар итик. Әкиятләрдә, гадәттә, персонажлар ачык күренеп торган ике төркемгә бүленә һәм аларның көрәше яхшылык-дөреслекне яклаучыларның җиңеп чыгуы, явызлык тарафдарларының юк ителүе белән тәмамлана. Без тикшерә торган пьесада геройларның төркемләнүе күзәтелсә дә, алар бертөрле һәм үзгәрешсез, катып калган сыйфатлары белән генә бирелмиләр. Киресенчә, драматург хәдисләрдән килә торган караш-фикерне калкытып куя – асылы белән явыз булган җан иясе юк. Тере табигатьнең аерым вәкилләрендә өстенлек алган кыргый сыйфатлар яшәеш өчен көрәш, тормыш шартлары нәтиҗәсе булып тора. Алардан котылу юлы бер генә – әлеге җан ияләре күңеленә яхшылык, изгелек, миһербанлык, ярату, хөрмәт һ.б. кыйммәтләр орлыгы салу.

Пьесадагы каршылык иң югары ноктасына дуслары белән килгән Таңбатырның Дию пәрие белән бәрелешендә җитә. Дию пәриенең сихере беткәч, Аппаксылу яшь кызга әйләнә. Шул рәвешле, пьеса бәхетле финал белән тәмамлана. Конфликт яхшылыкның явызлыкны җиңүе рәвешендә чишелә. Күргәнебезчә, балалар өчен язылган пьесада җитди проблемалар күтәрелә. Югарыда күрсәтелгән әхлакый һәм фәлсәфи сораулардан тыш, драматург яшәештәге башка катлаулы мәсьәләләр турында да уйланырга этәрә. Шуларның берсе – мәхәббәт. Әлеге табигый хис барлык җан ияләренә хас. Автор сурәтләвендә ул – бөтен тереклек дөньясын үзгәртергә сәләтле көч. Әсәрдәге барлык геройлар да аның йогынтысын кичерә. Ярату хисе Таңбатырга бөтен каршылыкларны җиңеп чыгарга ярдәм итә, Аппаксылуга ул өмет-ышаныч, ныклык бирә. Мифологиядә, фольклорда адәм балаларына дошмани көч буларак сурәтләнеп килгән дию-пәриләргә, җеннәргә дә хас икән әлеге тойгы. Вакыйгалар барышында нәкъ менә бер-берсенә булган

Безнең мирас №7 июль 2017

Туфан ага Миңнуллин әсәре буенча куелган «Төш» спектакленең премьерасыннан соң. 2011 ел

ярату хисе һәм Таңбатырның кешелекле, ярдәмчел мөнәсәбәте алар күңелендәге усаллык-явызлыкның бетүенә һәм матур сыйфатларның өстенлек алуына китерә.

«Гүзәл Аппаксылу» эчтәлеге белән гаять тә заманча. Автор традицион образларга яңа йөкләмә сала. Аллегорик формада бирелсәләр дә, без бүгенге тормышта очрый торган таныш типларны очратабыз. Кызына бай кияү эзләүче Җенлебикә, «банкларда акчасы буа буарлык куркыныч мафиозник» Салыптаптар, Диюнең ялагае Куштанбек һ.б. – барысы да бүгенге яшәеш белән тыгыз бәйле. Гомумән, фантастик күренешләр чынбарлык белән кушылып киткән, әкият геройлары бүгенге көнкүрештә хәрәкәт итәләр. Автор, татар теленең бай мөмкинлекләреннән уңышлы файдаланып, балалар психологиясенә туры килә торган кызыклы диалог-ситуацияләр кора, тамашачыны мавыктыра, хәл-күренешләргә «катнаштыра».

Автор балалар алдына яшәешнең җитди фәлсәфи сорауларын куюдан читләшми. Бу яктан маҗаралы вакыйгалар белән тулы «Ана күңеле балада...» пьесасы игътибарга лаек. Кыпчак даласында барган вакыйгаларда без халык авыз иҗатының төрле жанрларында урын алган традицион образлар белән очрашабыз. Драматург аларның үзара каршылыклы мөнәсәбәтләрен сурәтләп, бүгенге заман сорауларына да җавап эзли: «Мәхәббәт

«Рәдиф Сәгъдинең үз теле, үз стиле бар».

Туфан Миңнуллин

«Рәдифнең пьесаларында һәр җөмлә – драматургия».

Ринат Әюпов

нәрсә ул?», «Ничек бәхетле булырга?», «Кеше бәхете яисә бәхетсезлеге алдан билгеләнәме?», «Кешенең эчке һәм тышкы матурлыгы нәрсәдә?» һ.б. Шуңа да Ана, Ак әби, Бәбкәч, Гөлҗан образлары гына түгел, Карарух дөньясына караган пәри, җен образлары да гаять тормышчан булып, үзгә бер яңгыраш ала. Яшь буын өчен кызыклы булган вакыйгаларда геройлар җитди, кискен шартларга куелып, матурлыкта, батырлыкта, Анага тугрылыкта сынау үтә.

Драма әсәре көчле каршылыкны, гадәттән тыш булуы белән аерылып торган, шәхсән сыйфатлары калкытып куелган геройларны ярата. Әлеге пьесада конфликт Бәбкәч белән Жения эшгамәлләренә бәйле үстерелә. Бәбкәчнең җен-сихердән котылуы бары тик дуслары, әнисе, туган җире кадерен аңлау аша гына мөмкин була. Монда аңа Гөлҗанның олы, саф мәхәббәте дә ярдәм итә. Әсәрнең сәнгати эшләнеше дә уңышлы. Автор геройларның исемнәреннән дә бик оста файдалана: алар тирән мәгънәгә ия булып, герой характерын ачарга, аңларга ярдәм

«Гүзәл Аппаксылу» әкияте. Аппаксылу – Гөлнара Әбитова, Таңбатыр – Әмир Гайфуллин

итә. Катнашучыларның күңел дөньясын, уй-хисләрен, теләк-омтылышларын билгеләүдә йорт, дала, юл, төш хронотоплары, шулай ук пейзаж күренешләре дә пьесага уңышлы кертелә. Төп идеяне ачуда җыр-музыка мотивлары, халыкчан биюләр дә әһәмиятле роль уйный. Гомумән, Р.Сәгъди ярату һәм тугрылык кебек гомумкешелек кыйммәтләре турында җитди уйланып, аларны гыйбрәтле вакыйгалар аша укучылар алдына куя һәм һәркемне уйланырга, эзләнергә, нәтиҗә ясарга этәрә. Шулай итеп, драматург әсәрләрне кызыклы, мәгънәле итүнең төрле юлларын, алымнарын эзли. Традиция буларак урын алган композицион формадан – вакыйгаларга балаларның үзләрен дә катнаштыру алымыннан уңышлы файдалана. Геройлары әледән-әле залга – тамашачыларга мөрәҗәгать итә, теге яисә бу әхлакый мәсьәләгә җавап сорый. Бу исә баланы тагы да мавыктыра, үз гамәлләренә бәя бирү теләге дә тудыра.

Р.Сәгъди драматургиясенең төп үзенчәлеге, яшәешнең җитди мәсьәләләрен алга чыгарып, каршылыклы һәм индивидуаль йөзе белән аерылып торган геройларны чагылдырган, җыр-музыкага, мелодраматик эстетикага мөрәҗәгать иткән әсәрләрендә аеруча тулы чагыла. Бу урында драматургның «Сынган беләзек», «Бахчасарай гөлләре», «Алсу томан» кебек театрларда уңыш белән барган пьесаларын күздә тотам.

Р.Сәгъди үзен сюжет кору, вакыйга-интрига оештыру остасы итеп күрсәтә. Аның Буа театры тарафыннан сәхнәләштерелгән «Алсу томан» моңсу драмасында игътибардан читтәрәк калып килгән, әмма гаять мөһим, кирәкле тема – афәт булып бүгенгебезгә үтеп кергән наркомания мәсьәләсе һәм ятим, сукбай балалар, яшүсмерләр тормышы сурәтләнә. Әлеге мәсьәләләрне автор җәмгыятьтәге социаль-иҗтимагый шартлар белән бәйләнештә өйрәнә. Чечен сугышы кайтавазы, Чернобыль фаҗигасе, әнкече әти-әнисеннән качып киткән яисә ятим калып, интернатта чит-ят кулында үскән балалар язмышы өчен борчыла драматург. Чарасызлык, һәртөр кимсетелү аларны җимерек йорт подвалына җыйган. Әлеге «тормыш төбендә» яшәүчеләрне ничек итеп наркомания, әнкечелек, фахишәлек сазлыгыннан саклап калырга, тартып алырга? Пьеса әнә шуларны бөтен кискенлегендә куюы белән иҗтимагый яңгыраш ала.

XX гасырның ахырында җәмгыятьтәге иҗтимагый-тарихи вакыйгалар тулы бер буынның «югалуына» китерде. Автор, бер яктан, әлеге күренешнең сәбәпләрен ачуны һәм алардан котылу юлын эзләүне максат итсә, икенче яктан, үзен югалткан, һәртөр түбәнлеккә төшкән кешене аңлау, аңа ярдәм итү кирәклеге турында укучы-тамашачы белән җитди әңгәмә алып бара. Әсәр геройлары Марат һәм Артур кебекләр күңелендә барган хис-теләк һәм акыл-бурыч каршылыгы җитди иҗтимагый мәсьәлә булып калка һәм ата-бабадан килгән әхлаклы яшәеш белән җәмгыятьтәге шартларга бәйле рәвештә барлыкка килгән хезмәт куймыйча гына рәхәт, мавыктыргыч тормышта яшәү каршылыгы булып үсә. Пьеса ахырында геройларның бер ишләре күңелендә рухи яңару, үз-үзен табу фикере җиңеп

чыгып, алар яңа тормышка аяк атласа, икенчеләре, кызганыч ки, наркомания сазлыгыннан чыга алмыйлар. Шул рәвешле, Р.Сәгъди тормышның кеше күзенә бик үк күренеп тормаган караңгы ягын ачып, заманга, әсәр геройлары яшәгән җәмгыятькә бәя бирә.

Кырым татарларының фаҗигале язмышы – төрки-татарларның төзәлмәс әрнүле ярасы булып тора. Сталин төзегән тоталитар дәүләтнең кешелексез сәясәте символына әверелгән кардәшләребез кичергән афәткә мөрәҗәгать итеп, М.Юныс үз вакытында бер рухи батырлык күрсәткән иде. Бу юнәлештә тагын бер адым ясалды, ул – Р.Сәгъдинең «Бахчасарай гөлләре» мелодрамасы. 1944 елдан алып 1990 еллар башына кадәрге вакытны үз эченә алган вакыйгаларда бер гаилә язмышына бәйле кырым-татар халкы фаҗигасе ачыла. кырымдагы Симферопольдә, Төркиядәге Әнкарада, НКВД зинданнарында барган күренешләрдә чын мәхәббәткә, кеше бөеклегенә дан җырланса, әхлаксызлык-кешелексезлек гамәлләренә җан әрни.

Автор Кырым татарлары кичергән коточкыч афәтне, вәхшилекләрне, гаилә бәхетсезлекләрен сурәтләү аша тулы бер халык язмышын, фаҗигасен укучы-тамашачы каршында ача. Пьеса үткән, бүгенге һәм киләчәкне ачык итеп күз алдына бастыра. Кимсетелгән, туган җиреннән сөрелгән кешеләр язмышы аша олы мәхәббәткә мәдхия җырланса, түбәнлек-хыянәткә, мәкергә исә нәфрәт белдерелә.

Пьесада алгы планга чыгарылган Мостафа һәм Фазима образлары кешенең рухи көче, батыр йөрәге, чыдамлык-түземлек үрнәге буларак ачыла. Аларга туган җир, үзара яратышу, киләчәккә өмет көч бирә. Ә инде ятимнәр йортында тәрбияләнеп, соңрак «халык дошманы» баласы буларак эзәрлекләнгән кече улларының юлдан чыгып, эчкечегә, сукбайга әйләнүе – совет режимының кешелексез йөзен чагылдыра. Публицистик эчтәлек өстенлек иткән пьеса кырым татарлары фаҗигасенең кайтавазы булып яңгырый, сталинизмның, аның дәвамчыларының нинди куркыныч булуын аңларга, ирек-азатлык, гаделлек, хакыйкать идеалына тугры калырга чакыра.

Пьесадагы җыр-музыка, ярату символы буларак, лейтмотив ролен үти һәм эмоциональ халәт тудырып, укучы-тамашачы күңелендә явызлыкка нәфрәт һәм гаделлеккә өмет-ышаныч тәрбияли.

Р.Сәгъди драматургиясендә тулы бер катламны комедия жанрына караган пьесалар алып тора. «Кызлар кайтмый авылга», «Изге Мөҗбирнең күккә ашуы», «Минем Капурым», «Их сез, хатын-кызлар», «Гашыйклар утравы» һ.б. пьесаларда тормыштагы һәм кешеләр характерындагы кимчелекле якларны фаш итү, үткен итеп көлү аша алардан арыну теләге чагыла. Автор кызыклы ситуацияләр, яңгырашлы вакыйгалар таба, көлүнең төрле алымнарыннан, аерым алганда, геройның үз-үзен фаш итүе, бер-берсенең чын йөзен ачу, чиктән тыш арттыру яисә киметү, бөеклек һәм түбәнлекне аңлаткан сыйфат-билгеләрнең янәшә килүе кебек чаралардан уңышлы файдалана.

Шулай итеп, хәзерге татар сәхнә әдәбиятында 30дан артык пьеса язган. Рәдиф Сәгъдинең үз урыны бар. Аларның да күпчелеге – балалар әкиятләре. Ул заман укучы-тамашачысының рухи ихтыяҗларына йөз тотып иҗат итә. Проза һәм драматургия, публицистика төрләрендә уңышлы эшләп килүче язучы, яшәешнең төрле якларына мөрәҗәгать итеп, җитди мәсьәләләрне алгы планга чыгара, укучысы белән фикер алыша, бәхәсләшә. Рәдиф Сәгъдинең пьесаларына тема һәм жанр төрлелеге хас. Бүген ул мелодрама жанрын яңадан-яңа эзләнүләр белән баетып килә. ■

РЕДАКЦИЯДӘН: **Хезмәттәшебез һәм каләмдәшебез Рәдиф СӘГЪДИНЕҢ 17 июльдә гомер бәйрәме – 60 яшь тула! Без аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз.**

Галим Әлфәт Закирҗанов язмасының тулы вариантын www.beznenmiras.ru сайтында укый аласыз.

Фидания Әхмәтҗанова укучылары белән. Шыгырдан авылы, 1951 ел

Шыгырдан төене

Фатих Кутлу

Алабуга дәүләт педагогика институтында укыткан остазым Мөнир абый Нигъмәтнең мәрхүм булуына да биш ел үтеп киткән икән. И-и, гомерләр! Хәтерем ялгышмаса, истәлек-хатирәм[1] «Безнең мирас»та басылып чыкканнан соң, төштә күрдем үзен. Чаллы дәүләт педагогика институтына Казаннан ниндидер конференциягә килгәнмен, имеш. Коридор буйлап барганда күзем яртылаш ачык ишеккә төште. Яхшылап карасам, ни күрим: бүлмә эчендә кәләпүш кигән Мөнир абый басып тора.

Өнсез калдым: «Бөтен кеше аны үлгән, дип белә, ә ул исән икән!» Янына йөгердем, дулкынланып: «Сез бит исән! Бөтен кеше Сезне үлде дип белә!» – дидем. Ул елмаеп карап торды, бер сүз дәшмәде. «Әйдәгез, бергә фотога төшик, мин Сезне туган-тумачаларыгызга күрсәтеп, ул исән, юкка кайгырасыз, диярмен», – дидем. Телефонга икебезне фотога төшердем. Ләкин фотога карасам – янымда ул юк! Берничә мәртәбә кабатладым. Нәтиҗәсе – шул ук... Бу сәер төшне мәрхүмнең рухы шат булуга юрадым. Урынны җәннәттән әйләсен! Амин.

Быел 19 март кичендә Мөнир абыйның җәмәгате Рәмзия ападан телефонга хат килде: *«Фатих, хәерле кич. Әтисенең (сүз Мөнир абый турында бара. – Ф.К.) Корьән ашын уздырдым (18 мартта). Шыгырданнан Дамир абыйлар килде (мәрхүмнең бертуганы. –* **Ф.К.***). «Безнең мирас» журналында басылган мәкаләгезне Батыр районының[2] «Авангард» газетасында бастырып чыгарганнар. «Дәвамы бар», дип берничә санда бастырганнар. Шыгырдан халкы газетаның*

[1] Ф.Кутлу. Мөнир абый Нигъмәт турында истәлек // «Безнең мирас» журналы, №3, 2016. – Б.88-93.
[2] Чуашстан Җөмһүрияте.

Безнең мирас №7 июль 2017

һәр санын түземсезлек белән көтеп алган. Зур рәхмәтебезне җиткерәбез. Сәламәт булыгыз, тату яшәгез. Рәхмәт».

...Безнең гаилә март ахырында Чаллыга, әби-бабайлар янына кайтырга ниятләгән иде. Соңгы кабат Төркиягә баргач, мин Татарстанга төрле яшелчә орлыгы җыеп кайттым: янәсе, ничек, татар җирендә тамыр җәярме икән? Шуны тапшырырга теләп, Чаллыда яшәүче мөгаллимәм, шагыйрә Рәзинә апа Мөхиярга шылтыраттым: «Шундый-шундый хәлләр, ничек күрешербез икән?» Бу 22 март иде. Ул иртәгәсен Үзәк китапханәдә язучы Факил Сафинга багышланган кичә узачагын, үзенең шунда катнашачагын әйтте. Мин бик теләп шунда килергә, күрешергә килештем.

Чәршәмбе исән-имин Чаллыга килеп җиттек. Пәнҗешәмбе ГЭС бистәсендәге (дөресе: ҺЭС бистәсе) китапханәгә юл тоттым. Нәкъ вакытында анда идем. Коридорда Факил абыйны очраттым. Ул киләсемне белми иде. Мине күргәч, сөенде. Рәзинә апа, рәхмәт яусын, үз янында миңа да урын алып куйган икән. Янәшә утырдык. Әманәтне тапшырдым. Зал тулы иде. Кичә бик җылы, самими барды. Хозурланып карап утырдым. Ахырдан хөрмәтле Фәүзия апа Бәйрәмова сәхнәгә икенче мәртәбә менеп:

– Безнең арада Казаннан килгән тәрҗемәче Фатих Кутлу да бар бит. Әйдәгез, аңа да сүз бирик әле, – дип, мине чакырды. Беравык югалып калдым. Һич көтелмәгәнчә булды бу. Әзерлегем юк иде. Шулай да, сәхнәгә менәргә туры килде. Факил абыйны котлап, кичә турындагы тәэссоратымны җиткердем. Аннан «Горбәт илдә һәр ахшам батты бәгъремдә кояш» дигән моңлы классик төрек җырын бүләк иттем. Кичәдән соң таралышканда бер ханым җәһәт кенә минем янга килде дә: «Сезнең белән бик күрешәсем, танышасым килә иде. Исемем Рушания, мин Аяз Гыйләҗевнең туганы булам. Сөйләшеп алырга мөмкинме?» – диде. «Бүген, ни кызганыч, вакытым юк шул. Без берничә көн Чаллыда әле. Шылтыратышырбыз, хәбәрләшербез», – дип җавап бирдем. Телефон номерларыбызны алыштык.

Өйгә кайтканда остазым Аяз Гыйләҗевнең хатыны Нәкыя апага шылтыратып, Рушания ханым белән танышуыбызны сөйләдем. Ул бик сөенеп: «Рушания – Аязның бертуган абыйсы Азатның кызы ул. Үзе дә шагыйрә, язучы. Өч китап авторы», – диде.

Рушания Гыйләҗева белән иртәгәсен – 24 март көнне күрешергә сүз куештык.

Җомга кояшы да туды. Мин, сөйләшкәнчә, төгәл сәгать икедә Рушания ханым яшәгән фатирның ишеген шакыдым. Өйдә тагын бер кеше бар иде – Рушания ханым әнисен дә чакырган. Исәнләштек, таныштык. Әнисе Фидания исемле булып чыкты. Каршымда утыручы 88 яшьлек бу апа остазым Аяз Гыйләҗевнең җиңгәчәе дә, Нәкыя апамның килендәше дә иде. Рушания ханым мин килгәнче кайбер фотолар-


Бу хат Азатка гына.

«Азатка гына» дип башланган хат. 1952 ел

ны, хатларны күрсәтергә әзерләп куйган. Арада олуг әдипнең туганнары, әти-әнисе, килендәшләре, бала-чага белән күмәкләшеп төшкән сурәтләре дә бар. Шунда ук остазымның 1952 елда төрмәдән язган, «Бу хат Азатка гына» дип башланган, саргаеп бетсә дә, бүгенгәчә сакланып калган мәктүбен күрү, аны тотып карау бәхетенә ирештем. Аннары чәйләп-сөйләшеп утырырга кухняга уздык. Рушания ханым бик тәмле ризыклар пешергән, табыныбыз мул иде. Мин шунда остазым белән танышу тарихын, аның «Өч аршын җир» һәм «Җомга көн кич белән» әсәрләрен төрек теленә тәрҗемә итүем хакында сөйләдем. Фидания апа кырык ел татар телен укыткан. Тумышы белән Чистай Каргалысыннан икән. Сөйләшү барышында ул:

– Укытучылык эшемне Шыгырданнан башладым, – дигәч, мәрхүм Мөнир абый Нигъмәтне искә төшердем. Фидания апага да шул турыда әйттем. Бу хәл аңа да кызык тоелды, сүзен болай дәвам итте:

– Мин Шыгырданда 1951 елдан алып 1954 елга кадәр укыттым. Мине анда Фидания Әхмәтҗанова дип беләләр. *(Әле ирдә булмаган чагы. –* ***Ф.К.****)*

– Ркаил абый Зәйдулланың әнисе Гөлинә апа да Шыгырданнан бит, аны да укыткансыздыр әле, – дидем.

– Бәлки, – дип икеләнде ул, өздереп әйтә алмады. Алтмыш елдан артык гомер узган ләбаса! Мөгаллим кеше һәр укучысын исем-фамилияләп хәтерлимени инде?!

Рушания ханым әнисен бүлдермичә тыңлап утырды. Фидания апаның:

– Кызым, нигә китапларыңны Фатих бәйгә бүләк итмисең? – дип соравына, кыенсынып:

– Минем китаплар белән кызыксынырмы икән Фатих бәй? – дип җавап бирде.

– Ул нинди сүз! Бирсәгез, миңа кадерле бүләк булыр иде, – дип, үз фикеремне җиткердем.

Шуннан соң өч китабын да һәдия итте. Рәхмәт яусын!

Фидания апа кызы Рушания белән. 2017 ел

...Мин, гаять тәэсирләнеп, фатирга кайттым, икенче көнне түземсезлек белән Ркаил абыйның Чичкан авылында (Чуашстан Җөмһүрияте) яшәүче әнисе Гөлинә апага шылтыраттым:

– Сезне Фидания Әхмәтҗанова дигән укытучы укытмадымы?

– Әйе, Фидания апа укытты безне. Аны бик яхшы хәтерлим. Кара, чибәр генә бер апа иде.

– Мин Чаллыда әбиләрдә кунакта. Кичә Фидания апа белән таныштык, – дидем. Гөлинә апа өнсез калды.

...Менә хикмәт: Аяз Гыйләҗевнең җиңгәчәе Ркаил Зәйдулланың әнисенә татар теле укыткан! Фидания апа Шыгырданнан булса бер хәл иде әле! Әллә кайдагы Чистайдан бит ул. Шул ук көнне Ркаил абыйга шылтыратып, аңа да бу хәлне сөйләп бирдем. Яңалык аңа да кызык тоелды. Аяз Гыйләҗев бер язмасында болай дип искәртә: *«...Рөстәм Сүлти (ул да Шыгырданнан! –* ***Ф.К.****) яза, Ркаил Зәйдулла яза, аларның һәр язганы Ходай биргән талант югарылыгында калачак!»*[3]

...Без теге көнне Рушания Гыйләҗевада фотога төшми калганбыз. Дүшәмбе Казанга кайтасы. Бүген якшәмбе генә. Яңа танышларыма барып, алар хозурында сурәткә төшәсем һәм Фидания апаны укучысы Гөлинә апа белән телефоннан

[3] Аяз Гыйләҗев. «Ягез, бер дога!». – Казан: Татарстан китап нәшрияты, – 1997. – 255 б.

Безнең мирас №7 июль 2017

Күренекле шагыйрь Ркаил Зәйдулланың әнисе Гөлинә апа белән.
2014 ел, октябрь

булса да сөйләштерәсем килә иде. Яңа танышларыма шылтыратып, очрашу сорадым.

Фидания апа, калфаклар киеп, әзерләнеп куйган иде. Рушания ханым белән икәүләп каршы алдылар. Исәнләшкәч, залга күчеп утырдык. Мин, түзәалмыйча:

– Хәзер укучыгыз Гөлинә апага шылтыратып, сезне сөйләштерим әле, – дидем. Бу Гөлинә апа өчен дә көтелмәгән хәл булачак иде. Бераздан төребкәне Фидания апага суздым. Алар гәпләшә башлады.

Мин Рушания ханымга:

– Без тарихи мизгел кичерәбез. Без – алтмыш өч ел буе бер-берсен күрмәгән, бер-берсен ишетмәгән, барлык элемтәләре өзелгән укытучы белән укучы әңгәмәсенең тере шаһитлары. Бу – гаҗәеп вакыйга бит! – дидем.

Алар озак сөйләште. Мин ул минутларны камерага да төшереп алдым, фотога да. Төребкәне куйганнан соң, Фидания апа Гөлинә апаның телефон номерын дәфтәр битенә язуымны сорады. Аратирә шылтыратып-сөйләшеп торасы, элемтәдә буласы килә иде аның.

Аннан янә альбом карарга керештек. Фотоальбомда язмам өчен бик тә кирәкле, бик тә кызыклы, тарихи бер фотога юлыктым. Бу – Фидания апаның Шыгырданга килгән елда төшкән сурәте иде. Артына үз кулы белән болай язылган: «1951 ел, 20 октябрь. 9 сыйныф укучылары белән төшкән фото. ЧАССР, Чкаловский р-н., Чкалов (Шыгырдан) урта мәктәбе»...

Хөрмәтле укучы! Игътибарыңны язмамның башына юнәлтәсем килә. 19 марттан алып 24 мартка кадәрге биш көн эчендә кичергән вакыйгаларым Шыгырдан тирәсендә барды. Берсе дә алдан уйлап эшләгән эш булмады. Бакчы: минем бер ел элек «Безнең мирас»та дөнья күргән хатирәм быел март аенда «Авангард» газетасында басылып, Шыгырданга тарала. Бу хәбәр миңа 19 мартта килеп ирешә. 22 март көнне Чаллыга юл тотып, 23 март көнне Факил абыйның кичәсенә барам. Шунда, һич уйламаган җирдән, Фәүзия апа Бәйрәмова мине сәхнәгә дәшә... (Рушания ханым: «Сәхнәгә чыгармасалар, мин Сезнең залда утыруыгызны белмәс идем», – диде.) Аннары мине чәйгә дәшкән җирдән Рушания ханым иптәшкә дип әнисен чакыра. Моны укыган кеше: «Нинди очраклылыклар!» – дип әйтер, бәлки. Мин исә мәшһүр фәйләсуф Сократның сүзләрен кабатлыйм: «Галәмдә очраклылыкка очрау очрагы юк». Чыннан да, дөньяда һәрнәрсә Кодрәт иясе ишарәсеннән хәрәкәткә килмимени?!

Минем үз гомеремдә Шыгырданда булганым юк. Ләкин хәзер, баштан мондый вакыйгалар кичкәч, анда бармый калу ярамас. Фидания апаның да Шыгырданны күрәсе, хатирәләрен яңартасы килә. Киләчәктә морадыбызга ирешергә насыйп әйләсен иде! ■



Зәки Зәйнуллин. 1993

Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмнең агач сыны

Гармунчы Сиксәнкүз Равил Чижүк Әнвәрне җырлата.

Полковник, язучы, сынчы

Ләбиб Лерон

Кешегә ни җитми? Бу сорауга миллион җавап биреп булыр иде. Тик шулардан бары берсе генә күпләргә аеруча җитмидер, дип уйлыйм. Ул да булса – күңел тынычлыгы. Физик эш эшләгәннән яисә акыл хезмәте башкарганнан соң яраткан шөгыле белән мавыгудан тәм табучыны мин әнә шул күңел тынычлыгына ирешкән кеше, дип саныйм. Шагыйрь әйтмешли, ул шулайдыр әле – уйласаң...

Агачтан сын ясау белән мавыккан язучылардан мин әүвәл Миргазиян Юнысны гына белә идем. Бактың исә, Зәки абый Зәйнуллин да бу һөнәрнең остасы икән! Сүз дә юк, бер булганнан бар да була.

Зәки ага белән без 1989 елда, ул Ригадан Казанга күченеп кайткач таныштык. Дөресрәге, безне уртак әдәби остазыбыз һәм дустыбыз, хикәя остасы Мәгъсум ага Хуҗин таныштырды. Танышуыбызга кадәр үк, Мәгъсум агадан ишетеп, Зәки абыйның тормышыннан шактый хәбәрдар идем. Полковник. Ригадагы латыш һәм татар милли хәрәкәтләре активистларыннан берсе икән. Башкортстан тумасы (Зәки Зәйнуллин хәзерге вакытта туган авылы Эстәрлебашта

Язучы, һәвәскәр сынчы Зәки Зәйнуллинның эшләре

яши һәи иҗат итә). Үз башыннан кичкәннәрен бәян итеп, «язу яза» башлаган – «Чаян»га, шул басмаханәдә җаваплы сәркатип вазифасын башкаручы Мәгъсум абыйга адреслап, хикәя арты хикәя «яудыра» икән. Кыскасы, Мәгъсум ага әйтүенчә, киләчәктә олпат әдип булачак бик өметле әһле каләм...

Әдипләребез турындагы библиографик белешмәлектә (Татарстан китап нәшрияты, 2009) язучы Зәки Зәйнуллин хакында болай дип язылган: *«Зәки Зәйнуллин – әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе туплап килгән язучылардан, дөньяның яхшысына, яманына, тормыштагы һәр җитди үзгәреш-вакыйгага үз мөнәсәбәтен, фәлсәфи карашын ихластан кыю әйтә белә торган әдип»*. Миңа калса, «Полковникны озату» (документаль повесть, 1990), «Ат каралары»(1996), «Ата нигезе» (1997), «Агыйделнең аръягында» (тарихи роман-кыйсса, 1998), «Эстәрлебаш фетнәсе» (2002), «Арбалы үгез» (2003) кебек бихисап әсәрләр авторына бу бәяләмә бик туры килә.

Узган елларның берсендә, Башкортстанда йөргәндә юл уңае төшеп, Зәки аганың Эстәрлебаштагы «фазенда»сында булырга туры килде. Әлеге сыннарны тулаем шулвакытта күргәнсокланган идем.

Артык сүз куертып тормастан, Зәки Лотфулла улының аерым бер игътибарга лаек әлеге күркәм эшләрен «Безнең мирас» укучылары хозурына тәкъдим итәм. ■

Зәки Зәйнуллин «фазендасы»ндагы шалашы янында. 2017

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

КАЗАННАН УФАГА КАДӘР

Габдерәшит Ибраһимов

Казансу елгасы Иделгә кушылган урын

КАЗАННАН КИТЕП БАРЫШ

Сентябрьнең 16сында мин, Уфага китәр өчен, Казан пристанена килдем.

Биредә Уфага бара торган пароходлар аз түгел. Араларында иң яхшысы «Якимск» пароходлары булганга, бу фирманың пристанена бардым һәм шул ук минутта кузгалырга торган пароходка кереп, беренче каттагы бер кешелек каютага урнаштым. Рамазан ае иде. Вакыт инде шактый соң. Нәкъ кичке азан укылган вакытта, «Амур» пароходы, юлчыларын алып бетерде дә, шунда ук кузгалып та китте. Пароход шәһәр белән хушлашкандай бик ачы итеп кычкырткан саен, йөрәгем телгәләнгән кебек була. Казаннан китеп барабыз. Пароход та гүя аерылу хисенең авырлыгы астында изелә, йөрәк ачысы белән сызлана һәм инде көз башланганга, бу ел Казанга әйләнеп кайта алуы бик икеле булганын тоеп, мәңгегә аерылгандай бер-бер артлы ачы итеп сызгырта, кычкырта иде. Пароход

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

юлчыларының пристаньда калган якыннары белән кулъяулык болгап саубуллашуларын, хатын-кызларның яулык чите белән күз яшьләрен сөртеп-сөртеп алуларын күреп, мин дә тирән уйларга талдым. Шул ук вакытта Казанның инде ерагая барган мәчетләренә, манараларына карап моңсулана һәм эчемнән генә хушлаша идем.

ИМАМНАРГА КАДЕР-ХӨРМӘТ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ХЕЗМӘТЕ

Шулвакыт югары каттан Фатиха сүрәсе укыганнары ишетелде. *Ихдинассиратэл-мөстәкыйм,* диелүгә күтәрелеп карадым, берничә кеше җыелышып кичке намазларын кыла иде. Мин дә килеп аларга кушылдым. Намаз кылып бетерүгә ас катка төштем, ифтарга утырдым. Бер-ике кисәк ризык капкан гына идем, берәү килеп ишек шакыды. «Рәхим итегез!» – дидем. Ишектә бер әфәнде күренде:

– Мин Сезне каютама ифтарга чакырырга килгән идем, – диде.

– Рәхим итегез, ифтарны бергә генә ашыйк, – диюемә: «Ярар», – дип җавап кайтарды.

Өстәл янына утырыштык. Ашаганда кунагымның кем булуын һәм кайдан икәнен сорадым. Безнең юлдашыбыз Казан губернасы Чистай төбәгендәге бер авылның имамы булып чыкты. Безне дә ишетеп белә икән. Бераз сөйләшкәннән соң, кадерле кунагыбыз, заманадан зарланып:

– Голәмәгә кадер-хөрмәт азайды, милләт арасында әхлак бозыклыгы күбәйде... – дигән фикер әйтеп куйды.

– Голәмәгә хөрмәт азайдымы, әллә голәмәнең хөрмәте, дәрәҗәсе кимедеме? – дидем.

– Голәмәгә хөрмәт азайды, халык голәмә сүзенә колак салмый, голәмәнең кадере юк, – диде.

– Ник алай икән соң? Моның сәбәпләрен ачыкларга тырышканыгыз булдымы? Әлбәттә, бернәрсә дә сәбәпсез була алмас, – дидем.

– Элек халык арасында голәмәнең сүзе кабул ителә, үзе кадер күрә, бөек санала иде. Зәкят, гошер, сәдака мул иде, хәзер исә бай кешеләребез сәдака һәм зәкятләрен мәктәпләргә сарыф итәләр, голәмәгә бирмәс булдылар, – диде.

– Хәзрәт! Элек голәмә байлардан килгән акчаны шул ук мәдрәсәләргә, гыйлем эстәүче шәкертләргә сарыф итә иде, бөтен максатлары Ислам диненә хезмәт итү иде. Мәчетләрдә вәгазь сөйлиләр, нәсыйхәт әйтә торганнар иде. Шул рәвешле дин аякта нык торды һәм голәмә дә үз урынын, дәрәҗәсен саклый алды. Беләсезме, Чистайда никадәр шәкерт тәрбияләнә иде? Никадәр зур мәдрәсәләр төзелде? Ә бүгенге көндә ниләр бар? – дидем.

Безнең хәзрәт бераз инсафка килеп, кимчелекнең бер өлеше үзләрендә икәнен ачык кына итеп әйтмәсә дә, беркадәр таныгандай булды:

– Заманалар болайга әйләнеп китте шул, – диде.

– «Хәдис-е Шәриф»тә «Дәверне сүкмәгез...» дип әйтелгәнне белмисезме әллә? Замананың һич кенә дә катнашы юк. Чынбарлыкта, заманане бозучы да – голәмә үзе! Голәмә урын биләүне, баш булуны артык ярата башлады, алардагы бу ярату дингә хезмәт итүнең алдына ук чыгып басты. Голәмә, үз кулындагы нигъмәтнең кадерен белә алмыйча, гафләт эчендә яши бирде, җаһил улларын үз урыннарына утыртып калдырырга тырыштылар. Җаһил уллар чалма-чапан киеп алдылар да, галим аталарының урынына килеп утырдылар. Гыйлем һәм мәгърифәттән насыйпсыз кешеләр имам булды. Имамлык, муллалык хезмәт урыннары мираска әйләнде, җаһилләргә нәсел буенча күчте, гавәм белмичә дә калды – форсатлар кулдан ычкынды. Сез боларны күрә торып берни дәшмәдегез. Шуңа күрә килде бу хәлләр башыбызга. Иң төп һәлакәт – хезмәт урыннарының мирас саналып, лаеклысына түгел, ә башкасына бирелеп, ахмак угълы ахмакларның баш булуларында. Сез менә боларны уйламыйсыз, ә заманадан, тегесеннән-монысыннан

зарланасыз, бертуктамый: «Нәфесем, нәфесем...», дип сөйләнәсез, – дидем.

Безнең кунагыбыз башын бераз түбән иде, инсафка килеп:

– Аһ, әфәнде! Сүзләрегез бик дөрес. Мәүлам безнең хәлебезне ислах әйләсен – төзәтсен. Гафу итә күрегез, башыгызны авырттырдым, – диде.

– Зыян юк, фикерләр бәрелешүеннән хакыйкать барлыкка килә, мин канәгать калдым, – дидем.

Газиз кунагым, саубуллашып, үз каютасына китте, мин исә бу көрәшү аркасында бераз вакыт үткәрдем, аерылу моңсулыгын бераз онытып тордым.

Ястү намазыннан соң бераз китаплар караштырып алдым. Шулвакыт пароход хезмәткәрләреннән бер кеше килде:

– Әфәнде, сәхәр өчен берәр нәрсә кирәк булырмы, китертикме? – дип сорады.

Пароход хезмәткәрләренең бөтенесе дә христиан булганга, бераз сәерсендем:

– Сез сәхәр вакытында йокламыйсызмыни? – дидем.

– Әлбәттә, йоклыйбыз, ләкин Сез борсагыз, йокыбыздан уянып торырбыз, ни кирәк булса, китерербез һәм Сезне дә вакытында уятырбыз. Бу безнең вазыйфабыз, – диде.

– Рәхмәт. Бераз чәй, бераз ашамлык әзерләсәгез, әйбәт булыр, – дидем. Үзем исә уйлана башладым: «Йә Раббым, пароход хезмәткәре христиан, безне сәхәргә уятачак, ашарга китерәчәк, берничә вак акча өчен йокысын бүләчәк...»

Шулвакыт безнең хәзрәт килде:

– Әфәндем, безнең каютага рәхим итеп килегезче. Берәр чынаяк чәй эчәрбез, бераз сөйләшеп утырырбыз, – диде.

– Ярый, яхшы, – дидем. Хәзрәтнең икенче каттагы каютасына киттек. Безне сыйларга җыенуы аңлашыла: җиләк-җимеш, тәм-том, кайнатма кебек нәрсәләр әзерләгән иде. Тагын сөйләшә башладык:

– Хәзрәт, – дидем, – ничә ел имам булып торасыз?

– 18 ел булды, – дип җавап бирде.

– Алай булса, хәтерегез калмасын, хәзрәт, шул 18 ел эчендә мәхәллә халкы өчен ниләр башкардыгыз? Нинди хезмәтләрегез булды? 18 ел буе мәхәллә халкы Сезнең, гаиләгезнең көнкүрешен тәэмин итеп торган. Тормышыгызга беркем комачауламаган, тыныч кына яшәгәнсездер. Моңа җавап итеп, Сез мәхәлләгезгә нинди хезмәтләр күрсәттегез, нинди файда китердегез? – дидем.

– Җеназаларының намазын кылдым һәм кылдырдым. Туган балаларын дәфтәргә теркәдем. Никяхларын укыдым. Минем вазыйфам шулар, – диде.

– Мин Сездән үз мәнфәгатегез өчен башкарган эшләрегез турында сорамыйм. Киресенчә: «Милләт мәнфәгате өчен ниләр эшләдегез?» – дип сорыйм. Мәсәлән, Сезгә кадәр мәхәлләгездә мәктәп-мәдрәсә юк иде дә Сез килеп мәктәп ачтыгызмы? Яки мәчетләрдә үгет-нәсыйхәтләр бирдегезме, милләтне әхлак бозыклыгыннан арындырдыгызмы? Яки авылыгызның халкы фәкыйрь иде дә, Сез аларны эшләп табу, барлыклы яшәү юлына этәрдегезме? Хәзер аларның яшәү рәвешләре алга киттеме? Сез миңа менә шундый хезмәт һәм тырышлыкларыгыз турында сөйләгез, – дидем.

– Дөресен әйтергә кирәк, хәзерге көнгә кадәр боларның берсе дә миндә юк. Тик Сез миңа туры юлны күрсәттегез, мин бу фикерләрегезгә кушылам. Аллаһының рөхсәте белән моннан соң мәчеттә вәгазьләр сөйләрмен, мәхәллә халкын эшләп табыш алырга, тормышларын көйләргә чакырырмын, аңлатырмын. Миңа бик зур изгелек кылдыгыз, Аллаһ Сездән разый булсын, Сезнең бу ипле сүзләрегез миңа тереклек суы сипкәндәй булды, – диде.

Шулай итеп, бер ярты сәгать тирәсе хәзрәт белән сөйләшеп утырдык, аннан соң мин каютама кайтып ял иттем.

ТАТАРЛАРДА ЙОМЫРКА СӘҮДӘСЕ

17 сентябрь көнне өйләдән соң пароход палубасында утыра идем, бер кеше яныма килеп сәлам бирде. Мине танып

Казан пристане. 1907-1910 еллар

белә икән, сөйләшеп таныштык, Уфа кешесе икән. Нәрсә белән шөгыльләнәсез, дигән соравыма, сәүдә, дип җавап кайтарды.

– Нәрсә белән сәүдә итәсез? Ниләр алып, ниләр сатасыз? – дип сорадым.

– Иң зур сәүдәбез – йомырка сәүдәсе. Бөтен Уфа, Пермь төбәкләрендә йомырка җыябыз, аннары аны Петербургта, Лондонда, Берлинда сатабыз, – диде.

Бик нык аптырадым. Татар сәүдәгәре йомырканы Берлинга, Лондонга кадәр илтеп сатсын әле!

– Йомырканың бәясе иң кыйммәт дигәндә күпме була соң? – дип сорадым.

– Без йомырканы август башларында җыя башлыйбыз. Ул вакыт мең данәсе 15 сум була, август ахырларына таба 20 сумга кадәр күтәрелә. Ул бәягә дә алабыз, – дип җавап бирде.

– Август аенда йомырка буламы? – дидем.

– Иң сыйфатлы йомырка август аенда була. Язгы һәм җәй уртасына кадәрге йомырканы ерак җирләргә җибәрү мөмкин түгел, корый, кибә. Йомырка сәүдәсендә бәрәкәт тә бар, ләкин шул ук вакытта хезмәте дә күп, – диде.

– Никадәр йомырка җыярга була? Монда зур сәүдә була алуына минем бик ышанасым да килми, – дидем.

– Лондондагы «Робинзон» фирмасының йомырка сәүдәсендә барган еллык акча әйләнеше 35 миллион сумга җитә. Берлиндагы бер фирма бары тик йомырка җыю эшенә генә дә 80 мең сум акча бирә. Бу фирманың Русиядә 70кә якын филиалы бар. Алар биредә йомырка туплап, Берлинга җибәреп торалар, – диде.

Йомырка кебек гади нәрсәдән бу кадәр сәүдә булсын – миңа һаман да хыялдыр кебек тоела иде. Кеше мондый хәлләр турында ишеткән саен хәйран кала.

Һава торышы бик үк кулай булмаганга, пароход палубасында да бик озак юанырлык түгел иде, шуңа күрә вакытымны күбесенчә каютамда китаплар укып үткәрдем.

Төрекчәдән
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе.* ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАП СҮЗЕ

Тик Үгделмеш әйтте урныннан торып:
— Ничек китим инде сине калдырып,

Авыр хасталыкта ялгызың ятып,
Нишләрсең бу хәлдә, и, асыл затлым.

Тик янә Уйгырмыш әйтте: – Кайт инде,
Күп уйлама, угыл, минем кайгымны.

Иям үзе миңа юаткыч әле,
Күрә торып мине ташламас Тәңре.

Ходай кемне изге кылса олуглап,
Аның барча эше шуннан уң була.

Ни шәп әйткән тугры сүзле бер кеше,
Ашыкмаучан җете күзле ир кеше:

«Әгәр Тәңре Үзе ярдәмен итсә,
Ике дөнья бәхтен аладыр кемсә.

Төшсә бер инсанга Ходай рәхмәте,
Насыйп була ике дөнья рәхәте.

Рәхмәтеннән Ходай ташласа бүген,
Кеше кирәк бер эт, кирәк Күк бүре[1]...»

Сүзен кисеп: – Кардәш, – диде Уйгырмыш,
Кит инде, исән йөр һәм елама, хуш.

Уйгырмышны кочты шунда Үгделмеш,
Ачы яше белән болганды үбеш.

Елый-елый чыкты, күр, шуннан торып,
Атын менде, өйгә кайтты кайгырып.

Хафалы хәлендә керде ул өйгә,
Тынычлыгы китте кайгылы көйгә.

Назар сал – ни мескен Адәм баласы,
Һәр авыкта кайгы каплап аласы:

Ходай кемне изге кылса олуглап,
Аның барча эше шуннан уң була.

*Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санныннан басылып килә.

[1] Күк бүре – төрки халыкларның мифологик анасы исәпләнгән бүре. Гомумән, монда китерелгән җөмләнең мәгънәсе аңлашылып бетми.

Теләк эшкә ашса – сөенеч, көлеш,
Әгәр кайгы килсә, сагыш, үкенеч.

Сөйгәнен тапканнар сөенгән була,
Тик аерылу бар, кайгылар тула.

Күрешү шатлыгы шатландыра да,
Тиз үк аерылу килеп тора ла.

Ни бар аерылудан да авыр, каты?
Аның кайгылары – диңгезгә бату.

Тереләр аерылса табышыр тагы,
Эзләшеп-теләшеп кавышыр тагы.

Катыдан да каты аерылу – үлем,
Үлемгә юк дару, чара йә йолым.

Гади аерылу – якын йә ерак,
Үлеп аерылу – бу бит әлфирак[2].

Бу хакта әйтелгән охшаш шигырь бар
(Укысаң, мәгънәсен үзе ачыклар):

«Барыннан катырак аерылу – үлгәч,
Әлфирактан күрер күзләр яшь түгә;
Тереләй аерылсаң әле өмет бар,
Бармы өмет үлгәч кабат күрүгә?»

Ашап эчте, бераз тынып, Үгделмеш,
Намазын укыды моңайган килеш.

Кояш җиргә керде – яшерде йөзен,
Ә күк ул кояшның эзләде эзен.

Үгделмеш ятыйм, дип түшәк сорады,
Ятты – кайгысыннан күзен йоммады.

Торып, чыкты йортка, юылды яше,
Дөнья йөзе кара, гүя, хәбәши.

Керде, түшәгенә тагын авышты,
Җиңеләйгән кебек булды сагышы,

Ай чыкты да батты руми кызыдай,
Күк тагын каралды зәңги йөзедәй[3].

**«Әгәр Тәңре Үзе ярдәмен итсә,
Ике дөнья бәхтен аладыр кемсә».**

Йокысы килмәде. Карады күккә.
Күтәргән иде офыкта Өлкәр.

Күзен күккә текте, озак карады,
Ләкин төн төнәрде, һич агармады.

Ятып торды бераз, тагын уянды,
Зәңгәр күккә бакты, көтеп ал таңны.

Шәрыктан Каракош[4] чыгып үрләде,
Дошман үрт салгандай офык дөрләде.

Җидегән күтәрде башын тагын да,
Елдырык чүңкәйде Айгыр янында.

Җиргә кадәр төште Ирәнтез башы,
Кояш көчкә-көчкә чыгып күз ачты.

Үгделмеш юынды, пакьләп таранды,
Намаз кылды, вирден[5] кабатлап алды.

Алтынланды тәмам таулар, калкулар,
Ялкынланды җәйрәп яткан киң сулар.

Үгделмеш киенде, атына менде
Һәм сарайга, гүя, ашыгып килде.

Тиз генә атыннан төште һәм аны
«Кер әле», дип илбик чакырып алды.

Багып күрде илбик бу Үгделмешне –
Тәмам күңле төшек бер изге кеше.

Сорады илбик: – Йә, хәлеңне белгерт,
Сагышлы кебексең, болай шәп егет.

Нинди йөк күтәрдең күңлеңдә бүген?
Маңгаеңда сырлар – төйнәлгән төен.

Нигә ал йөзләрең агарып киткән?
Нигә дөнья сиңа, гүя, көл сипкән?

[2] Әлфирак – «күрешмәслек аерылу».
[3] Руми – Византияле (Руми кызы дип Византиядән сатарга китерелгән герман кызлары аталган), зәңги – негр (кол).
[4] Каракош, Елдырык, Айгыр, Ирәнтез – йолдыз (йолдызлык) атамалары.
[5] Вирд – көнлек гыйбадәтләр планы.

Төшсә бер инсанга Ходай рәхмәте,
Насыйп була ике дөнья бәхете.

Әле бәхет синнән йөз чөермәде.
Бу дөнья күзеңне яктыртыр[6] әле.

Уңайга әйләнер талигың синең,
Теләгәнчә туар аең һәм көнең.

Кашымны-күземне сиңа төймәдем:
Сине күргән саен тик сөенәмен.

Хәзерге хәлеңне күреп борчылам —
Кыяфәтең сөйли – кайгы бар сыман.

Нинди кайгыга син тарыдың, углым,
Миңа әйт, белим, и, гүзәл холыклым.

Сине күрсәм газап, кайгы эчендә,
Мин шат булалмыйм ич инде һич кенә.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавабән Үгделмеш шунда тел ачты,
Кардәшенең хаста хәлен аңлатты,

Үзенең барганын, ничек күргәнен,
Ничек нәсихәт вә үгет биргәнен..

Илбик башын бөкте һәм акты яше,
Әйтте: – Кызганыч ки изге бер кеше.

Гафу итсен Тәңре гөнаһын аның,
Аермасын әле тәненнән җанын.

Янә әйтте: – Ничек, белгәч шул хәлен,
Ни җаның белән син ташлап китәлдең?

Аны кем күзәтер, аш-суын карар,
Шул хаста хәлендә кемнәр дәвалар?

Ник анда калмадың янында торып,
Китсәң китәр идең алмаш калдырып.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СҮЗЕ

Җаваплап Үгделмеш әйтте бу сүзен;
— Әйттем мин аңар, и, белем диңгезе.

Мине кире какты, сүзне тотмады,
Кабат ныкышырга көчем җитмәде.

Илбик хәтта басты моны ишетеп
Ачуын белдерде (ләкин үз итеп),

Ул әйтте: – Үгделмеш, утыр акылга,
Аның өчен хәзер кат-кат кыл дога.

Ходай ярлыкасын ул Уйгырмышны,
Кичерсен аның бар язык кылмышын,

Алла ярдәм бирсен сиңа бу хәлдә,
Тәмугтан иминлек, оҗмахтан хәбәр.

Ишеген бикләп, син юлын кискәнсең,
Йөзен каплап, сүздән мәхрүм иткәнсең.

Сиңа һич ярашмый бу төрле кылык,
Акыллы сайламас мондый юл-юрык.

Сиңа, әйт әле бер, кем кулланды көч?
Кемнәр үпкәләде яки алды үч?

Ходайның хөкеме – кардәшең үзрә
Синең казаң тиде, хатаңны төзәт:

Ник уйлыйсын хәзер, нигә бу сыгыт?
Ташла моны, шәптән түгел бу кылык,

Тумыш затлар үлмеш һәм төшә менмеш,
Йөремешләр туктар һәм алыр бирмеш.

Кардәшең үлеме – сиңа бер гыйбрәт,
Тынычлан, терегә яшәргә кирәк.

Үлүчене күрсә тере калучы
Нәсихәт дип белсен аның язмышын.

Үлек әйтә кебек: «Менә күр мине
Үлем тотты килеп, бер тотар сине».

Бу хакта бар – укы шундый бер бәйтне
(Күңелгә алырлык, шактый гыйбрәтле):

Сөйгәнен тапканнар сөенгән була,
Тик аерылу бар, кайгылар тула.

[6] Күз яктыру (яктырту) – КБ-тә күп тапкыр кабатланганча, «шатлану, шатландыру»; бу тәгъбир Себер татар сөйләшләрендә киң таралган.

«Сиңардан элегрәк үлгәннәр меңдер,
Алар, гүя, үгет бирәләр: – Бер күр.

Гафиллектә көйләр сызгырып йөрдең,
Үлем безгә килде, сиңа да килер».

Үгделмештән илбик сорашты шунда
Ничек үлгән, фәлән-төгән турында.

Сөйләде Үгделмеш хәбәр килгәнен:
Үлгәндә васыять итеп биргәнен.

Әйтте: – Миңа менә кардәш калдырган
Бар мирасы аның шул инде, туган,

Ал илбик, берсен ал, комарткы итеп,
Ярап куяр бәлки, бәхеткә илтер.

Кулын сузды илбик, алды таякны,
Һәм әйтте: – Бәхеткә булсын комарткы.

Кардәшең рәкъвәсе булсын үзеңә
Карап-карап ал бу серле күзгегә.

Рәкъвәне кулына алды Үгделмеш,
Күңле тулды, күздән яше түгелде.

Илбик әйтте: – Нинди гыйбрәтле бу көн,
Бигрәк безнең өчен – уйлан һәм үкен.

Яшәде үзенчә, үлде бер төрле,
Һаман дөнья шулай бара, фикерлем.

Ни ди, ишет, берәү – юньле һәм иплe
(Акыллы рәвештә булган эшлекле):

Күп булса да артмас дөнья әйбере,
Аз булса да җитә, белсәң кадерен.

Дөньяның җәфасы мең, вафасы бер,
Ничек үткәрсәң дә үтәдер гомер.

Үлемнән соң малдан нинди файда бар?
Сөенерләр, бәлки, сине җыйганнар[7]

Күрешү шатлыгы шатландыра да,
Тиз үк аерылу килеп тора ла..

Катыдан да каты аерылу – үлем,
Үлемгә юк дару, чара йә йолым.

Дөнья малын ташлап качты кардәшең,
Чыпта киде, арпа ашап яшәде,

Кичендe ничек тә, бер дә үлмәде,
Аны җыючыга[8] берни калмады.

Тырышты ул көн-төн, җиңде хисләрен,
Һәм аңа тимәде тормыш хәстәре.

Әзерләнеп шулай, котылды бүген.
Безнең алдыбызда – чишелмәс төен...

Илбик зарый кылды мең сүзе белән,
Җаны-тәне белән, чын күңел белән.

Шуннан торды илбик, сәрайга китте.
Бүлмәсенә керде. Сагышлы иде.

Сагышланды бик-бик Үгделмеше дә,
Кайгы басылды тик гомер үтүдән.

Бераздан кайгысын онытты. Инде
Ашап эчте, янә көлде, сөенде...

Башчылардан ни шәп әйткән берәүсе
(Белек илә ил-көн эшен эшләүче):

«Сагыш-кайгы ничек әсир итсә дә,
Көлер бер көн күзең, күп яшь түксә дә.

Әзәлдән бирле бер шундый канун бар:
Яманмы-яхшымы, җуядыр еллар».

Үгделмеш тә кайгы чорын озатты,
Чара-тәдбир табып кылды хезмәтне.

Дәртле, тырыш иде, тынмады һич тә,
Таңнан төнгә чаклы булды ул эштә.

Чакырды илбик беркөн Үгделмешен,
Сорашты ил хәлен, үзенең эшен.

Әйтте: – Ил вә халык хәзер ни хәлдә,
Ничек үтә вакыт ошбу көннәрдә.

---

[7] Җыю – монда «күмү, яшерү» (татар сөйләшләрендә дә бар).
[8] Җыючы – күмүче.

**Тумыш затлар үлмеш һәм төшә менмеш,
Йөремешләр туктар һәм алыр бирмеш.**

Син миңа күз-колак, бар эшләремне
Сиңа тапшырдым мин. Әйт нишләвеңне.

Күпме көннәр булдың кайгы-сагышта,
Бу хәл чагылмыймы эшләгән эштә?

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – И, Илбик,
Халык хәле әле шөкер итәрлек,[11]

Береннән-бере шәп белкә-галимнәр
Көндәлек ризык та тапмый үлделәр.

Бүген, күр, гүяки тумаган алар,
Кара җир катында үлеп яталар.

Ни төрле, ни төсле хәлләр кипты, күр,
Җара җир аларны җийде-ипты, күр.

Җитеш сәрай, урда, каршилар ташлап,
Җара җир түшәнеп яталар аста.

Өне юк, тыны юк – йокыдалармы,
Ничек хәлләре – кем белә аларны.

Алар бүген мохтаҗ изге догага,
Куллары җитми ич бер эш кылмага.

Үкенеп яталардыр, күр, хәтем[12] теләп,
Хәер-дога көтеп, безне хәтерләп.

Бүген Тәңре бирде безгә бу көнне,
Аны форсат белик, азак үкенмик.

Ходай бирсен тәүфикъ калган гомергә,
Барча игелеккә, и, изге түрә.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СҮЗЕ

Үгделмеш, алкышлап, илбикнең сүзен,
Әйтте: – И, бәк, яшә озак һәм озын.

Дөнья синнән мәхрүм калмасын инде,
Ходай ыругыңны кисмәсен иде.

Теләк-арзуларың нинди булмасын,
Ача бирсен Тәңре сиңа капкасын.

Ниндирәк булса да теләккә юллар,
Киңрәк ачылсын ул капка, и, юмарт.

Сөенеп, мавыгып, яшә син озак,
Рәхәтлекләр күреп, и, холкы йомшак.

Ни кызганыч булыр синең кебекләр
Үлеп, сөякләре җиргә күмелсә.

Нишләмәк кирәк ки, Тәңре дөньясын
Бу төрле түрәткән, и, ил патшасы.

Үлсә дә ул тере – синдәй һәр кеше:
Аңар тигән изге рухның өлеше.

Кирәк үл, кирәк ки яшә күп-озак,
Изге атың инде җәелде ерак,

Сөючеләрдән аз сөймәгәннәрең,
Соңгылары бетсен, киңәйсен җирең.

Җир үпте – сүз кисте һәм торып китте,
Атын менеп чапты өенә тикле.

Аттан төште, керде өйгә Үгделмеш,
Ашап эчте, тып-тын ятты беркилеш.

Иртән иртүк торып эшен башлады —
Күрсәтмәләр бирде, үзе эшләде.

Телен, күңлен дөрес тотып заң бирде,
Кәкреләрне туры юлга күндерде.

Шулай төзәтелгән саен дөньялар
Үгделмешкә яуды хәер-догалар.

Үлде шундый күпләр, калды исәннәр,
Аларның үрнәге калыр ил-көндә.

Уйлап кара әле мондый кешене:
Фәрештәме әллә, гади кемсәме?

**Үлүчене күрсә тере калучы
Нәсихәт дип белсен аның язмышын.**

---

[11] 6166 нчы кушыктан соң 6167 һәм арытабан кушыкларның темасы кискен үзгәрә: күрәсең, арада күп кенә кушыклар төшеп калган (сәхифәләр югалган).
[12] Хәтем – үлгәннәр рухына игелек теләп укылган дога, намаз һ.б.

Әгәр алар булса гади бер инсан,
Әйтеп бир – бүгенге кешегә ни сан?[13]

Әгәр без дә кеше исемен йөртсәк,
Аларны фәрештә дип атау кирәк.

Аларның кылык вә кылмышларын мин
Ишетеп, и хуҗам, үрнәк алыйк, дим.

Аңлылар аңлый һәм белекле белә:
Дөнья мәңге калыр, тик кеше үлә.

Ирешелгән хәлнең кадерен белик,
Тагать кылыйк – тимәс бүтән мөмкинлек.

Моннан да мәгънәле нәсихәт бармы?
Хәтерлә элекке шул олыларны.

Калыр карши, урда, сәрайлар бергә —
Аларны өстерәп булмый кабергә.

Ничә кирмән, урда, ныклы туралар[14]
Тора-бара кара җиргә керәләр.

Ничә шәһәр, ил, баг чәчәклекләрен
Корытты, күр, үлем, и, холкы терем.

Ничә карши, урда, сәрайлар
Шул миңа кинәнеч – сиңа калалар.

Сансыз чирү башы – җиһангир кайда?
Гаскәре калды, тик үлгәч ни файда.

Кайда ул сок әмир – «җирем аз», диде,
Күп илләр яулады, нәфсе зур иде.

Кайда кешедән җир талаган бәндә?
Бер өем җир баскан аны үлгәндә.

Кайда ул – мөселман канын түгүче?
Нигә җиргә керде? Кайда шул көче?

Кайда шул зат – кеше рәнҗетеп йөрде?
Үзе рәнҗетелеп кабергә керде.

**Күп булса да артмас дөнья әйбере,
Аз булса да җитә, белсәң кадерен.**

**Ниндирәк булса да теләккә юллар,
Киңрәк ачылсын ул капка, и, юмарт.**

Кайда ул – дөньяны яулыйм, дип йөрде,
Дөнья торып калды, ул инде үлде.

Кайда ул – мал-туар җыйгач һәр җирдән,
Ике кисәк бүз дә аңар бик җиткән?

Кайда ул – һәр төштән җир сатып алган?
Үзеннән хәбәр юк, җирләре калган...

Менә шулай тора дөнья хәлләре,
Фәһем белән уйла, аңларсың барын.

Рәхәте – мәшәкать, шатлыгы – хәстәр,
Кадере – арзанлык, кызыгы – хәтәр.

Башыңа ни төшсә дә шыңшыма син,
Рәхәт артса, бел ки – алда түләрсең.

Ни ди, ишет, әнә, бер укытучы:
—И, син, мәшәкатьтә сабыр кылучы,

И, нигъмәт иясе, шөкер кыл ашка,
И, михнәт иясе, сабыр кыл эшкә.

Сабыр кылсаң, михнәт нигъмәтең булыр,
Шөкер кылсаң, нигъмәт гел артып торыр.

... И, белкә, назар сал бүгенге чорга:
Бүтән булды бары, бүтәнчә тора.

Гыйлемленең кадре юк – ул бер читтә,
Акыллы телсездәй – сүз ачмый хәтта.

Илдә начар кеше бигрәк күбәйде,
Юаш инде түзә, башын күтәрми.

Чәлә мөҗтәһитләр[15] намазсыз булып
Батыр дип атала, йөретә золым.

Фискы-фәсәтчене «ирән», диделәр,
Буза эчермәгән «саран», диделәр.

Дәвамы бар ■

[13] Бу сәтырлар ошбу китапның Баласагун дәүләтенең ахырында язылуына дәлил: Йосыф хасс хаҗип элекке идарәчеләрне идеаллаштырып искә ала.
[14] Кирмән - «кремль», урда – «гөмбәзле сәрай», тура (татар сөйләшләрендә дә бар) – «кирмән башнясы».
[15] Чәлә мөҗтәһит: чәлә – «тулы түгел», мөҗтәһит – «дин өчен көрәшүче».

Дуслар арасында. 1930 нчы еллар

ФӘТХИ БУРНАШ
(1898-1942)

«Яңалиф» журналының 1929 елгы 12 һәм 15 нче саннарында Фәтхи Бурнашның бөтен иҗат эшчәнлеген колачлаган «Сарайлар, ханнар, кенәзләр, мәчетләр шагыйре» дигән күләмле мәкалә басылып чыга (авторы – Фатих Сәйфи-Казанлы). Шул ук вакытта башка матбугат басмаларында да әдипне ачы тәнкыйтьләп язган материаллар күренә башлый. 1930 елның 17 июнендә Бурнашны, «уң тайпылышта, буржуаз милләтчелектә» гаепләп, партиядән чыгаралар. ВКП(б)ның Үзәк Контроль комиссиясенә апелляция язып, шул елның көзендә үк партия сафына кире кайтарылуына ирешсә дә, «солтангалиевче» ярлыгы аның исеменә мәңгелеккә ябышып кала.

Утызынчы еллар ахырында аеруча кызу темп белән барган репрессия чаралары золымына дучар ителгән татар язучылары арасында Фәтхи Бурнаш соңгы корбан булган, дияргә мөмкин. Аны 1940 елның 24 августында Югары Осландагы җәйге дачасында язып-эшләп утырган җиреннән алып китәләр. Тикшерүләр, сорау алулар 1941 елның гыйнварына кадәр дәвам итә. Әдипне шул ук, моннан ун ел элек энәсеннән җебенә кадәр тикшерелеп, җәзасы күрелгән «гөнаһлар»да – милләтчелектә, әсәрләре белән «солтангалиевчелек» идеяләрен таратуда, «солтангалиевчеләр»гә матди ярдәм күрсәтүдә гаеплиләр. Матди ярдәм шул: әдип хөкем ителгән нарком-

просс хезмәткәре Борындыковның эшсез, ач калган хатынына 50 сум акча бирә. Бу хәл... 1929 елда ук була.

Җинаять эшен карарга тиешле Татарстан Югары мәхкәмәсе кушуы буенча Фәтхи Бурнаш әсәрләренә экспертиза ясала. Составына Татарстан китап нәшрияты хезмәткәрләреннән Н.Терентьев, А.Камалетдинов, И.Гази, Язучылар оешмасыннан Х.Хәйри, Т.Имаметдиновлар кергән бу комиссия, кайбер кимчелекләрне күрсәтеп, «тулаем алганда, Фәтхи Бурнаш әсәрләрендә советка каршы тенденцияләр юк», дигән гомуми нәтиҗә ясый. Шуңа да карамастан, Югары мәхкәмәнең җинаять эшләре буенча Махсус коллегиясе 1941 елның 24 гыйнварында, ягъни әдипнең кулга алынуына нәкъ биш ай тулган көндә, Бурнашны «ун елга ирегеннән, шуннан соң өч елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәргә» дигән карар чыгара. Тоткынның кассация сорап язган гаризасы РСФСР Югары мәхкәмәсе тарафыннан кире кагыла, әдип этап белән Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсендәге «Безымянный» лагерена озатыла.

Биредә Фәтхи Бурнаш Ильенков фамилияле тоткын белән дуслаша. Шулкадәр төрле, шулкадәр үзгә ике кешене нәрсә якынайткандыр, әйтүе кыен, ләкин хакыйкать – хакыйкать булып кала: алар бергә ашый, бергә йоклый, сәясәткә кагылышлы мәсьәләләр, Бөек Ватан сугышы фронтындагы хәлләр турында ачыктан-ачык сөйләшәләр. Күпмедер вакыттан соң, Ильенковны лагерь иерархиясе буенча күтәрәләр – ул төзү эшләре десятнигына әверелә. Ике «дус»ның арасы салкыная. Озакламый әдип гомеренең икенче – соңгы – фаҗигале акты уйнала...

1942 елның 12 гыйнварында «тоткын Бурнашев», саксызлык күрсәтеп, тоткын Свиридовның котелоктагы ашын түгеп җибәрә, ике арада низаг туа, болар янына башка тоткыннар йөгереп килә. Арада Ильенков та була. Шул ук көнне әдип отряд җитәкчесе урынбасарына «Ильенков белән Свиридов мине кыйнады» дигән эчтәлекле мөрәҗәгать тоттыра. Ләкин ул кәгазьнең могҗизалы рәвештә эзе югала. Аның урынына әллә кайдан гына 1941 елның 24 сентябрендә үк Ильенков тарафыннан язылган үзгә «документ» «йөзеп» чыга һәм «эш» папкасына теркәлә: анда Бурнашның «сугыш шартларында советка каршы коткы сүзләр таратуы» «фаш ителә».

Нәтиҗәдә, Махсус киңәшмә 1942 елның 15 июль утырышында язучыны атарга хөкем итә. *«Карар алдан ул билгеләп куелган була инде. Гаепләү нәтиҗәсен раслаган кешеләр аны болай формалаштырып куялар: «Гаепләнүче Бурнашевка карата иң югары җәза чарасы – ату куллануны тиеш табабыз».*

Судны көтеп, Ф.Бурнаш ярты елдан артык камерада интегә. Үзенә үлем карары чыгарылачагын ул, һичшиксез, сизгән. 1942 елның 15 июлендә – «Фәтхелислам Закирович Бурнашевны атарга» дигән хөкем карары чыгарыла һәм, әйткәнебезчә, ул 1 август көнне үтәлә...

Ике җинаять эшендә дә Ф. Бурнашның фотолары теркәлгән. Аның беренчесе язучы кулга алынгач ук төшерелгән. Икенче фото, күрәсең, җәза алдыннан алынган. Алар бер-берсеннән җир белән күк сыман аерылып торалар. 1940 елгы рәсемдә Ф.Бурнаш чигелгән чәчкәле ак күлмәктән, аны бик тиз танып була. Бөтен мәһабәт гәүдәсендә, йөз сызыкларында ниндидер сәер тынычлык: әйтерсең лә ул үзенә ташланган мәгънәсез гаепләрнең тиздән кире кагылачагына ышана. Ә 1942 елда төшерелгән фотода язучыны тануы бик авыр. Каткан телогрейкадагы, баш киемсез, битен сакал-мыек баскан бу кеше – кайчандыр танылган драматург һәм шагыйрь Фәтхи Бурнашмы соң?! Ләкин бу чынлап та ул: кайчандыр чибәр булган кеше бөтенләй беткән, йончыган, шешенгән күзләрдә тормыш нуры сүнеп килә, бөтен кыяфәтендә ниндидер битарафлык... Болар – физик һәм мораль яктан кыйналулар нәтиҗәсе.

Хәзер Фәтхи Бурнашның соңгы елларын каплап торган кара пәрдә алып ташланды. Ләкин сораулар тагын да кала әле. Бурнаш кебек кеше лагерьда да, төрмәдә

дә язмыйча кала алмас, һич югында, аның кыска-кыска шигырьләре булырга тиеш. Кайда алар?

Бүген шунысы ачык: Ф.Бурнаш беркайчан да ханнар, сарайлар шагыйре булмады, ул бөтен иҗатын аларга түгел, ә туган халкына багышлады. Халкыннан күпме генә аерырга тырышсалар да, ул аңа кире әйләнеп кайтты. Бүген кат-кат басыла торган әсәрләре, күптомлы китаплары, сәхнәләрдә уйнала торган пьесалары, дәреслекләргә кергән шигырьләре булып әйләнеп кайтты ул...» *

Ләкин репрессия органнары Фәтхи Бурнашның атып үтерелүе турындагы фактны да туганнарыннан озак еллар буе яшереп тоталар – энесе Вафа, улы Рөстәмнең 1956 елгы реабилитация вакытында сорап язган гаризаларына: «Хезмәт белән төзәтү лагерендa җәза срогын үткәндә Фәтхи Бурнаш 1942 елда икенче тапкыр ун елга ирегеннән мәхрүм ителде һәм 1946 елның 1 августында төрмәдә үпкә эмфиземасыннан үлде», – дигән ялган җавап бирәләр. Шул ялганны раслап рәсми хат тапшыралар. Бары 1988 елда гына, Фәтхи Бурнашның тууына 90 ел тулу уңае белән КГБ архивына керү мөмкинлеге туып, язучының язмышына бәйле төгәл фактлар ачыклана.

***

Югарыда, махсус комиссия Бурнашның иҗатын тикшерә һәм, кайбер кимчелекләрне санамаганда, әдипнең эшчәнлегенә сәяси күзлектән уңай бәя бирә, дидек. Бу урында шул «кимчелек»нең берсенә – «Чаян» журналының 1929 елгы 10 санында «Фәтхи Бурнаш» имзасы белән басылып чыккан һәм шагыйрьнең язмышын хәл итүдә аяныч роль уйнаган «Шанлы дәүләт» шигыренә тукталыйк.

Комиссия нәтиҗәсе буенча, бу әсәр нәкъ менә «контрреволюцион эчтәлекле» һәм «милләтчеләрне хуплап, большевикларга каршы язылган», дип табыла. Ләкин эш шунда ки, Бурнаш әлеге шигырьнең үзенеке булуын танымый, хәтта теше-тырнагы белән моңа каршы килә, ул миңа пародия рәвешендә язылган булырга тиеш, дип раслый. Мәхкәмә аптырап калмый, вазгыятьтән «тиешле» нәтиҗә чыгара: «Шигырьнең контрреволюцион эчтәлеген инкарь итмәгән хәлдә, Бурнашев үзенең авторлыгын инкарь итә. Ләкин басылып чыккан әсәргә карата үз вакытында һичнинди мөнәсәбәт белдермәве аның шигырь эчтәлеге белән килешүен күрсәтә...» Тикшерүчеләр гонорарның кемгә күчерелүен тикшереп тормый. Фәтхи Бурнаш Гази Касыймнан шикләнүен белдерсә дә, ни аны, ни ул елларда «Чаян»да эшләгән Гадел Кутуйны, ни баш мөхәррир Сафа Борһанны сорау алуга чакырмыйлар.

Шигырь үзе дә, «Шәрык гөлләре» исеме белән оешып бетәргә тиешле поэма да, әдипнең бернинди китабында урын алмауга карамастан, тарих өчен Фәтхи Бурнашныкы булып кала...

*Ф.Баһаветдинов, А.Әхмәдуллин. Фәтхи Бурнашның соңгы еллары. «Сүнмәс утлар балкышы» китабыннан. – Казан: Идел-Пресс, 2006. – Б.226-227.



Ике фото... Алар бер-берсеннән җир белән күк сыман аерылып тора

ШАНЛЫ ДӘҮЛӘТ
(«ШӘРЫК ГӨЛЛӘРЕ» ПОЭМАСЫННАН КЫЙТГА)

1
Тузды Болгар иле, сынды ханлык,
Килде читләр Казан тәхтенә.
Тынды тыштан, эчтән янды халык
Тәкъдир биргән ачы бәхтенә.

2
Әй Ходаем, безне читкә ташлама,
Бирмә көч Ислам диненнән башкага,
Большевиклардан бушансын таш кала,
Бирмә көч Ислам диненнән башкага.

3
Рус җирендә данлы Чыңгыз әүлады
Урнашып ятырларны читкә каулады,
Большевиклар әйләнеп төште кире,
Селкетте бар Җир йөзен Чыңгыз иле,
Һәрбере куркып Туранга дан тулы
Мал белән кәрван йөридер көн-төне.

Әдәбият

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.223-224.
2. Когда на сцене погас свет.../ Ф.Н.Багаутдинов, И.И.Илялова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С.92-96.
3. Рафаэль Мостафин. Һәммәсен исемләп искә алыйк. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014.
4. Фәтхи Бурнаш. Шанлы дәүләт. // Чаян ж., 1929. – №10.

***Рүзәл Мөхәммәтша** әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2017

ТАТАР ХӘРБИ РАЗВЕДЧИКЛАРЫ

Рәис Зарипов

Үзебезнекеләр битарафлык күрсәтсә дә, милләтнең яңадан-яңа каһарман шәхесләрен дөньяга танытучылар бар. 2012 елда дөнья күргән хәрби разведкага багышланган саллы хезмәтне (Энциклопедия военной разведки. 1918 – 1945 гг. – М.: Кучково поле; Ассоциация «Военная книга», 2012. – 976 с.) әзерләүче авторларны нәкъ менә шундый затлар исемлегенә кертергә мөмкин. Болар – махсус хезмәтләргә багышлап дистәләрчә китап чыгарган ***Александр Колпакиди*** *һәм* ***Михаил Алексеев*** *белән* ***Виктор Кочик****. Әлеге китапта, нигездә, СССР хәрби разведкасы җитәкчеләренең һәм югары чиндагы хезмәткәрләренең кыскача биографияләре белән танышырга мөмкин. Шунысы куанычлы: белешмәлектә татарлардан да хәрби разведка белән бәйле 4 генерал, 7 полковник, 4 подполковник, 2 майор һәм 1 капитан турында биографик язмалар бирелгән. 1918 елдан алып Бөек Ватан сугышы тәмамланган елга кадәр чорда кардәш башкортыбыздан да бер хәрби разведчик булуын ассызыклап үтү мөһим. Ул – Ырынбур губернасының Шенгарская (?) авылында туган майор* ***Дәүләтша Насыйров****.*

Шундый җитди хезмәттә урын алган татар каһарманнары кемнәр соң алар? Әүвәл – 1896 елда Казан губернасының Мамадыш өязенә керүче Югары Утар авылында (Татарстанның хәзерге Саба районы) туган хәрби разведка генералы, хәрби фәннәр докторы **Минзакир Әпсәләм улы Әпсәләмов** турында кыскача мәгълүмат. Авыл мәдрәсәсен тәмамлап, экстерн рәвештә укытучы һөнәренә имтихан тапшырган егетне 1914 елда патша армиясенә алалар. 1915 елдан хәрби хезмәттә: 35 нче запастагы Себер укчы полкында – рядовой, унтер-офицер. 1918 елдан – кызыллар ягында, 1919-1922 елларда РККАның Хәрби академиясендә укый. Шул вакытта ук, укуын өзә-өзә, чит илләрдә махсус бурыч үти. СССРның хәрби җитәкчесе дәрәҗәсенә ирешкән Минзакир Әпсәләм улы 1920-1941 елларда – хәрби разведкада: Кызыл Байраклы Кавказ армиясенең Разведка бүлеге башлыгы (1927-1931), СССРның Ирандагы хәрби атташесы һәм хәрби разведка резиденты (1933-1937), М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә 2 нче махсус курс факультеты һәм разведка кафедрасы башлыгы (1938-1940). Шул чорда махсус бурыч үтәү өчен чит илдә «командировка»да булуын да ассызыклау кирәктер. Кызыклы бер өстәмә: *«Кафедра башлыгы булып торган чорда Әпсәләмовның эшчәнлеге уңай бәяләнә»*. Бу – 1941 елның гыйнвар

Уртада – Шамил Гыйниятуллин. 1930 нчы еллар

Минзакир Әпсәләмов. 1960 нчы еллар

аенда НКВДның Дәүләт куркынычсызлыгы Баш идарәсенең махсус бүлеге (ОО ГУГБ) тарафыннан бирелгән белешмә. Ул заманда канлы репрессияләр үткәрүче төп оешмадан андый бәя алу, әлбәттә инде, алтын бәясенә тиң. 1935 елда – полковник, 1939 елда – комбриг, 1940 елда генерал-майор званиесенә үрләтелгән якташыбыз – совет-фин сугышында Төньяк-Көнбатыш фронтның Разведка бүлеге башлыгы. Бөтен фронтның разведкасы белән оста җитәкчелек иткәне өчен беренче мәртәбә Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. 1941 елның июнь-июль айларында Көньяк-Көнбатыш юнәлештә сере әлегәчә ачыкланмаган махсус бурыч үтәгәннән соң, Кызыл Армиягә күчерелә: Урал һәм Көньяк Урал хәрби округларында запастагы һәм уку-укчы бригадалары белән командалык итә. 1943 елның февраль аеннан – кабат фронтта: әүвәл 18 нче укчы дивизия командиры урынбасары вазифаларын башкара, ноябрь аеннан командир итеп үрләтелә. Биредә танылган хәрби разведка генералының командирлык сәләте тулысынча ачыла. Бер генә мисал: Кызыл Байраклы, Суворов һәм Кутузов орденлы 18 нче укчы дивизия мактаулы исемгә һәм ике орденга нәкъ менә Минзакир Әпсәләмов командалык иткән 9 ай эчендә (25.11.1943-25.08.1944) ирешә. 25 август көнне ул үз дивизиясен полковник Петр Полувешкинга тапшы-


Благодарность Верховного Главнокомандующего Маршала Советского Союза товарища СТАЛИНА

Приказами Верховного Главнокомандующего Маршала Советского С
И. В. СТАЛИНА генералу армии Мерецкову, Вам, красноармей
Абсолямову Касиму Абсолямовичу, участнику боев за освобожд
Советского Заполярья в соединении генерал-майора Абсалямова ОБЪЯВЛ
БЛАГОДАРНОСТИ: за освобождение района Никелевого производства и
ленных пунктов Никель, Ахмалахти и Сальмиярви (приказ от 23 октября 194
за овладение городом Киркенес (приказ от 25 октября 1944 г.), за освобожд
Печенгской области (приказ от 1 ноября 1944 г.).

Командир соединения
генерал-майор (Абсалямов)

Начальник штаба
полковник (Поликарпов)

ра, чөнки ике көн алда гына аны Карелия фронтының 14 нче армиясе составында оешып килүче 131 нче укчы корпуска командир итеп билгеләү турында Боерык дөнья күрә. Әмма якташыбыз үзе оештырган корпус белән бер ай чамасы гына командалык итеп өлгерә. Менә-менә Заполярьены һәм Норвегиянең төньяк районнарын гитлерчылардан азат итүне күз уңында тотып әзерләнгән Петсамо-Киркенес операциясе башланырга торган кызу көннәрнең берсендә, төгәлрәге, 21 сентябрьдә генерал Әпсәләмовны 31 нче укчы корпус командиры итеп билгелиләр. Бер ай чамасы сузылган операция барышында Минзакир Әпсәләмов шәхси батырлык һәм гаярьлек үрнәкләре күрсәтә, бу сугышлар барышында аның гомумгаскәр бәрелешләре асылын яхшы аңлап эш итүе һәм корпус частьлары белән тәвәккәл идарә итүе бөтен тулылыгы белән ачыла. Бу операция вакытында үз карамагындагы гаскәрләр белән оста командалык иткәне өчен якташыбыз 1944 елның 2 ноябрендә I дәрәҗә Богдан Хмельницкий ордены белән бүләкләнә. Тагын бер көннән СССР Югары Советы Президиумының генерал-майор Минзакир Әпсәләм улы Әпсәләмовны чираттагы – өченче Кызыл Байрак ордены белән бүләкләү турындагы Карары басылып чыга. Шунысы игътибарга лаек: генерал Әпсәләмов фәкать 1944 елда гына да ике Кызыл Байрак, I дәрәҗә Богдан Хмельницкий һәм II дәрәҗә Суворов орденнары белән бүләкләнә. 1945 елның февралендә исә Геройның күкрәгенә Ленин ордены тагалар.

Кызыклы бер мисал. Бу бәрелешләр барышында 31 нче корпус белән янәшә, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучы бер частьта, Минзакирның энесе Касыймның хезмәт итүе ачыклана. Нәрсә әйтсәң дә, туганлык хисләре дигән изге бер төшенчә бар: генерал энесен үз корпусына күчерә. Шуның нәтиҗәсе буларак, генералның Казанда яшәүче туганнары гаиләсендә тарих һәм истәлек өчен гаять кадерле бер документ саклана. Бу – 31 нче корпус командиры Минзакир Әпсәләмов кул куйган, шул хәрби берләшмә сугышчысы **Касыйм Әпсәләмовка** атап Югары Баш-

Сулдан уңга: 10 нчы кавалерия дивизиясенең штаб башлыгы Ш.Гыйниятуллин һәм дивизия командиры А.Кулешов. Пятигорск, 1932 ел

командующий Иосиф Сталин исеменнән юлланган Рәхмәт хаты.

Минзакир Әпсәләмов үзенең өч дивизияне берләштерүче 31 нче укчы корпусы белән 1946 елның апреленә кадәр командалык итә. Аннан соң, отставкага чыкканчы, СССР Кораллы көчләре Генштабы академиясендә җаваплы вазифалар били. Ленин, 4 Кызыл Байрак, I дәрәҗә Богдан Хмельницкий, II дәрәҗә Суворов, «Мактау Билгесе» орденнары, шулай ук Азәрбайҗанда алган Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм күп санлы медальләр кавалеры. 1969 елда милләттәшебезгә Ленинград өлкәсендәге Подпорожье каласының мактаулы гражданы дигән исем бирелә. Илнең күренекле хәрби җитәкчесе дәрәҗәсенә ирешкән хәрби разведка генералы Минзакир Әпсәләм улы Әпсәләмов 1981 елның 10 июнендә Мәскәүдә вафат була, кабере – хатыны һәм кызы җирләнгән Яңа Дон зиратында.

Ә менә китаптагы 1895 елда Самара өлкәсенең Бөгелмә өязе Керәҗле авылында (Керәҗле – хәзерге Ырынбур өлкәсенең Северный районына керә) туган генерал **Шакир Гыйниятуллин** турындагы язма бик үк тулы түгел. Аннан күренгәнчә, Шакир Нигъмәтулла улы кала училищесын (1908), Югары мөселман мәктәбен (1913), инструкторлар әзерләүче Югары мәктәпне (1918-1919), кавалерия курсларын (1924-1926), М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең төп факультетын (1928-1931) һәм РККА Генштабы академиясен (1938-1939) тәмамлый. Илнең иң югары һәм дәрәҗәле академиясендә укыганда полковник званиесе бирелә, 1940 елның 25 апреленнән – комбриг, 4 июненнән – генерал-майор. Кавалерия курсларын тәмамлагач, Урта Азия хәрби округына керүче 8 нче аерым Төркестан кавалерия бригадасының 84 нче кавалерия полкында штаб башлыгы һәм 83 нче (кайбер хезмәтләрдә – 80 нче) кавалерия полкында командир булып хезмәт итә. 1931 елның мартыннан – 10 нчы Төньяк-Кавказ дивизиясенең штаб башлыгы. Аннан инде, биш ел буена – РККАның Разведка идарәсендә (1940 елның июленнән – Кызыл Армия Генштабының

Разведка идарәсе): Монголиядә хәрби киңәшче һәм Разведка идарәсенең 9 нчы бүлеге башлыгы. 1939 елдан командирлар составы өчен ачылган Кавалерия курсларында укыту бүлеге башлыгы. Бөек Ватан сугышында катнаша: 10 нчы кавалерия дивизиясенең һәм 58 нче армиянең штаб башлыгы, 1942 елдан Кызыл Армия Генштабы Оператив идарәсенең Якын Көнчыгыш юнәлеше башлыгы вазифасын башкара.

Минвәгыйз Зәйнетдинов белән **Гөлнара Рәфыйкова** мәкаләсендә (Зайнетдинов М., Рафикова Г. Верный и лихой кавалерист // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2006. – №2. – С.90.) генерал Гыйниятуллинның аннан соң Генштабның офицерлар төркеме башлыгы урынбасары итеп билгеләнүе, 1943 елдан Кызыл Армиянең Баш кадрлар идарәсе карамагында булуы, шул чорда Ленин ордены белән бүләкләнүе һәм СССРның иң югары бүләген аңа Кремльдә ил «старостасы» Михаил Калининның үзе тапшыруы күрсәтелә. Шул ук журналда чыккан икенче бер язмадан өземтә: *«1941 ел ахырында Ш.Н.Гыйниятуллин – 58 нче резервтагы армиянең штаб башлыгы. Аннан соңгы ике елда Кызыл Армиянең Генераль штабында хезмәт итә. 1943 елның декабреннән – кадрлар идарәсе карамагында. Аннан соң нәрсә белән шөгыльләнүе билгесез. Әмма 1944-1945 елларда Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, Ленин орденнары белән бүләкләнүе мәгълүм.*

1946 елның 3 апрелендә вафат була» (Я.Гришин, С.Мэнди. О татарских военачальниках // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2012. – №1/2. – С.134 .).

Бу урында Шакир Гыйниятуллинның ике Кызыл Байрак (1922, 1923), Бохара Халык Совет Республикасының II һәм III дәрәҗәдәге Кызыл Йолдыз һәм Монголия Республикасының Поляр йолдызы орденнары белән бүләкләнүен искәртеп, башка чыганаклардан да кайбер өстәмәләр китереп үтү артык булмастыр. Мисал өчен, Кызыл Армия Генштабының 1942 елның 7 июлендәге (№188. ЦА МО РФ, ф. 16, оп. 1072сс, д. 7, л. 56 – 64.) һәм 9 июлендәге (№190. ЦА МО РФ, ф. 16, оп. 1072сс., д. 7, л. 75-83.) оператив сводкаларында өч имза бар: шуларның беренчесе – Генштабның Оператив идарәсе башлыгы урынбасары вазифаларын башкаручы генерал-майор Шакир Гыйниятуллинныкы. Аннан соң шул ук идарәнең бригада комиссары званиесендәге Хәрби комиссары Рыжков белән Мәгълүмат бүлеге башлыгы генерал-майор Платонов фамилияләре «ташка басылган».

Тагын бер кызыклы факт: 2015 елның март аенда **«Безнең мирас»** журналында ветеран журналист **Александр Филипповның «Җиңү алып килгән татар генералы»** дигән кызыклы һәм фәһемле язмасы дөнья күрде. Билгеле булганча, 1941 елның июль ае ахырында Сталин тарафыннан Генштаб башлыгы кәнәфиеннән төшерелгән армия генералы Георгий Жуков урынына югары хәрби белемле, стратегик фикерләү куәсенә ия, гаятъ дәрәҗәдә зыялы Советлар Союзы Маршалы Борис Михайлович Шапошников билгеләнә. Ләкин сәламәтлеге начараю сәбәпле, 1942 елның май аенда ул үз вазифасыннан китә һәм аның урынын Генштабның Оператив идарәсе белән җитәкчелек иткән генерал-полковник Александр Михайлович Василевский били. Шул җәһәттән, Александр Филиппов мәкаләсеннән бер өземтә: «Оператив идарәдән аның *(Василевскийның. – **Р.З.**)* китүе Генштаб өчен бик авырга туры килә. Аның начальниклары булып ярты ел эчендә генераллар А.И.Бодин, икешәр тапкыр А.Н.Боголюбов, В.Д.Иванов, алар арасында вакытлыча П.Г.Тихомиров, П.П.Вечный һәм Ш.Н. Гыйниятуллин эшләп алалар» (Филиппов А. Җиңү алып килгән татар генералы // Безнең мирас. – 2015. – №3. – 56 б.).

Димәк, генерал-майор Шакир Гыйниятуллин берара Кызыл Армия Генштабының Оператив идарәсе башлыгы урынбасары һәм башлыгы булып торган. Тагын бер саллы чыганактан күренгәнчә, генерал Гыйниятуллинны офицерлар корпусының җитәкчесе итеп тә үрләткәннәр әле. Тарихи

Ш.Гыйниятуллин хатыны һәм кызы белән. Мәскәү, 1930 нчы еллар

дөреслекне нигезләү өчен, Кызыл Армия Генштабының Оператив идарәсендә җитәкчеләр алмашыну вакыйгасы башланып киткән вакытта, ягъни 1942 елның июнендә Якын Көнчыгыш юнәлеше башлыгы вазифасына керешкән комбриг Сергей Матвеевич Штеменко (генерал-майор – 23.11.1942, генерал-лейтенант – 4.04.1943, генерал-полковник – 17.11.1943, армия генералы – 12.11.1948) мемуарыннан өземтә китерү артык тоелмас: *«Югалтулар артык күп булу сәбәпле... Генштаб җитәкчелеге гаскәрләр белән элемтә тоту өчен махсус командирлар төркеме оештырырга мәҗбүр булды. Әүвәл алар Оператив идарә карамагында иделәр, ә соңрак Б.М.Шапошников тәкъдиме белән аларны бездән алдылар һәм мөстәкыйль төркем итеп үзгәрттеләр. Ставка ул төркемне Генераль штабның офицерлар корпусы дип атады. Шунысы әһәмияткә ия: Кызыл Армия тарихында беренче мәртәбә «офицер» сүзе кулланылды... Генштабның*

офицерлар корпусына җитәкче итеп гаять дәрәҗәдә намуслы һәм эш сөючән генерал-майор Н.И.Дубинин билгеләнде. Алга таба аны Опертаив идарәнең икенче бер ветераны генерал-майор Ш.Н.Гыйниятуллин алыштырды» (Штеменко С.М. Генеральный штаб в годы войны. Кн. 1. – М.: Воениздат, 1985. – С.184.).

Тормышының шактый өлешен хәрби разведка белән бәйләгән өченче татар генералы – **Фирьяз Рәхим улы Ханцеваров**. Әлбәттә инде, энциклопедиядә совет чорында фамилиясе сер итеп сакланган генерал-майор Ханцеваров турында мәгълүматның бик аз күләмдә булуы гаҗәп түгел. Ул 1926 елның 21 апрелендә Көнбатыш Казакъстанның Урда авылында туа, сержантлар мәктәбен, Ярославль хәрби училищесын һәм Ленинград хәрби-инженерлар элемтә академиясен тәмамлый. Техник фәннәр докторы (1971), профессор (1973), генерал-майор (1978). Стратегик максатлардагы Ракета гаскәрләре институтында һәм космик гаскәрләр институтында фәнни хезмәткәр, идарә башлыгы (1958-1974), аннары – 10 ел буена Генштабның Баш разведка идарәсе (ГРУ) аппаратында җаваплы вазифалар били. 1984-1988 елларда – СССР Фәннәр академиясе аппаратында.

1996 елда Халыкара энергия-мәгълүмати фәннәр академиясе президенты, Россия Технология фәннәре академиясе академигы, хәрби-космик гаскәрләр һәм ГРУ генералы Фирьяз Ханцеваровның Мәскәүдә яшәүче татар галимнәре белән Татарстанның ул чактагы Хөкүмәт җитәкчесе **Фәрит Мөхәммәтшин** үткәргән очрашуда катнашуы – аның үз милләтен санлавына һәм «чабаталарын түргә элгән» кайбер кемсәләр өчен үрнәк булырлык бер дигән мисал. Дөрес, ул әле аннан өч ел алда армия генералы Мәхмүт Гәрәев тырышлыгы белән Мәскәүнең «Президент-отель» кунакханәсендә оештырылган татар генераллары очрашуына да килә. Нәкъ шулчакта татар генераллары һәм адмираллары турында берсеннән-берсе саллырак мәкаләләр язган һәм аларны туплап китап чыгарган күренекле журналист **Нургали Булатов** каһарман милләттәшебез белән әңгәмә кору җаен таба. Әлбәттә инде, үзенең туганы, чыгышы белән Казаннан булган Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербургтагы Информатика һәм автоматлаштыру фәнни-тикшеренү институты директоры, академик, генерал-майор-инженер **Рафаэль Йосыпов** ярдәме белән.

Әүвәл генерал Фирьяз Рәхим улы туган авылның 1924 елгача Ханская ставка исемле кала статусында йөрүен һәм 1897 елдагы халык санын исәпкә алу мәгълүматларыннан күренгәнчә, анда 1378 кыргыз-кайсак, 685 татар, 416 рус һәм 66 украин яшәвен ассызыклап, Нургали ага китабыннан бер өзек китерик: *«Фирьяз Рәхим улы... эшче гаиләсендә туа. Аңа бер яшь дигәндә көтмәгәндә әтисе вафат була. Шуннан соң аларның сигез кешелек гаиләсе башта Красная Куткага (Саратов өлкәсе), аннары Мәскәүгә күчә, тормышның барлык михнәтләрен татый»* (Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. – Казан: Идел-Пресс, 2000. – 126 б.).

Фирьяз атлы татар баласы 14 яшендә Мәскәүдә һөнәр училищесын тәмамлап, токарь булып эшли, 17 яше тулуга, фронтка җибәрүләрен сорап, кат-кат хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итә. Әмма яу кырына омтылучы егетне армиягә фәкать 1944 елда гына алалар, Ярославль хәрби-пехота училищесын тәмамлагач, 7 ел буена илнең көнчыгышында һәм Польша белән Чехословакиядә хезмәт итүе мәгълүм. 1953-1958 елларда академия тәмамлый һәм төрле хәрби-тикшеренү оешмаларында эшли. Фәнни хезмәткәрдән СССР Оборона министрлыгы Генштабы Баш разведка идарәсе башлыгының фән буенча урынбасары һәм шул ук министрлыкның фәнни-тикшеренү институты башлыгының урынбасары дәрәҗәсенә ирешә. Төп шөгыле – фән, космос өлкәсе һәм хәрби разведка хезмәте.

Хәрби-космик гаскәрләр һәм ГРУ

генералы Фирьяз Ханцеваровның, хәрби разведкада хезмәт иткән чорында генерал-майор званиесе бирелү кебек мөһим вакыйгадан башка, 10 ел буена ни белән шөгыльләнүен һәм тагын нинди уңышларга ирешкәнен ачыклау мөмкин булмаса да, фән өлкәсендәге казанышлары турында шактый күләмдә мәгълүмат бар һәм алар хәйран калырлык. Боларын Ханцеваровны якыннан белгән, Халыкара энергия-мәгълүмат академиясенең Татарстан бүлеге президенты, фәлсәфә фәннәре докторы **Равил Исхаков** «Эниология» дигән мәкаләсендә («Звезда Поволжья». – 2007. – 13-19 декабрь) тарих өчен ташка басып калдырды. Узган гасырда тарихка СССР белән АКШ арасында «салкын сугыш» чоры булып кереп калган сәяси-идеологик каршылыклар вакытында Фирьяз Рәхим улы космик процессларны системага салып өйрәнү буенча үзенең фәнни мәктәбен булдыра. Милләттәшебез җитәкчелегендә һәм аның шәхсән катнашында илнең оборона куәтен ныгыту максатларыннан чыгып дәүләт югарылыгында 30 зур фәнни-тикшеренү эшләре алып барылуы да сер түгел хәзер. Шуңа да, фәнни-техник эзләнүләрендә ирешкән уңышларын исәпкә алып, «СССРның атказанган уйлап табучысы» дигән мактаулы исем бирелүе һич тә гайре табигый хәл түгел.

Ханцеваровның абруе шулкадәр югары була ки, ул берьюлы өч махсуслашкан докторлык һәм гыйльми советта, шулай ук СССР Югары аттестация комиссиясенең (ВАК) эксперт советында әгъза булып тора. Космик чыганаклар Баш идарәсе вәкиле буларак, Фирьяз Рәхим улы – дөньяда беренчеләрдән булып айның безгә күренми торган ягының космик фотосурәтләрен өйрәнгән һәм совет махсус программасы буенча шул күренешләрне күзәткән галим. Болардан тыш, хезмәт вазифасы буенча бик еш Байконур космодромында галәмгә ракета очыру барышында катнашучы генерал Ханцеваров күп космонавтлар белән таныш та булган әле. Зур хәрби галим һәм ябык хәрби учреждениеләр җитәкчесе буларак, ул СССР Министрлар Советында еш була һәм Хәрби-сәнәгать комплексы мәсьәләләрен тикшерүдә катнаша. Милләттәшебезнең А.Н.Косыгин, Г.Е.Агеев кебек илнең югары дәүләт һәм хәрби эшлеклеләре, совет фәнен җитәкләүче академиклар М.В.Келдыш, Е.П.Велихов, И.В.Образцов һ.б. белән шәхсән даими очрашып торуы мәгълүм. Бер уңайдан, Фирьяз Ханцеваровның энергия-мәгълүмат алмашу өлкәсендәге феноменнарны өйрәнү буенча яңа фәнни-техник юнәлеш булдыруның башында торуын да искәртү мөһим. Шунысы бар: ул 1989 елда Бөтенсоюз күләмендә гамәли эниология ассоциациясен («ЭНИО») оештырып, аның президенты булу белән генә чикләнми, ә бәлки бу өлкәдә озак елларга сузылган эзләнүләрен өзлексез дәвам итүе нәтиҗәсендә, тагын бер елдан Энергия-мәгълүмат фәннәре академиясен оештыручыларның берсе һәм аның тәүге президенты буларак, фән дөньясында яулаган абруен тагы да ныгыта. Ә инде янә биш елдан академиянең халыкара статуска (МАЭН) ия булуы Ханцеваровның дөньякүләм танылу тапкан галим дәрәҗәсенә ирешүенә һәм аның абруена турыдан-туры бәйле.

Фирьяз Ханцеваров. 1990 нчы еллар

Дәвамы бар. ■

Безнең мирас №7 июль 2017

УТЛЫ КИСӘҮ

Лерон Гыйльфанов

(Истәлекләр, уйланулар)

АВЫЛДАШ ЯЗУЧЫЛАР ТУРЫНДА

Авылдашым Харрас Әюпов гаиләсе безнең өйдән ерак түгел генә яшәде. Әтиләре (Гыйльмегали исемле иде) сугыштан яраланып кайтып, колхозның нәсел айгырларын – пожарный атларын карады. Харрас, бәләкәй булса да, әтисе янында арбага утырып йөри иде. Урта мәктәпне Күбәктә бетерде. Казанда югары белем алды. Районга кайтып, газета редакциясендә эшләде. Яңадан Казанга күчеп, язучы-шагыйрь булып китте. Ул әле миңа каениш тә тиешле, апасы Хәкимә белән тормыш арбасын бергә тартып барабыз. Шунысы аяныч: 60 яше тулу белән гаиләсен, безне ятим калдырып, түп йортка китеп барды. Мәңгелек урыны – авылыбыз зиратында. Акыллы, тәртипле кеше иде, тавышын күтәргән чагы булмады. Чишмә суын бик ярата, киткәндә чишмә суын зур шешәләргә тутырып алып китә иде. Язмыш шулай кушкандыр. Бәхил бул, Харрас, урының җәннәттә булсын.

Харрас Әюпов атка кечкенәдән үк мөкиббән була

Башы журналның быелгы 2 нче санында.

Авылдашлар: Илгиз Низамов (сулда), Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Лерон Гыйльфанов. 2016 ел

Икенче авылдашым – язучы-шагыйрь Мөҗәһит Әхмәтҗанов. Алда аның әтисе Заһит абый турында язып үткән идем. Менә шул Заһит абыйның баш баласы инде Мөҗәһит. Артык күп яза алмам, чөнки белгәннәремне тезеп китсәм, сәгатьләр буе язарга кирәк. Кыскасы, Мөҗәһит – авылымның, районның иң дәрәҗәле кешеләреннән берсе. Үсеп җиткәч, Дусай авылының булган кызы Бания белән тормыш корып, икесе дә яшь буынга белем бирде. Өч баһадир ул үстереп-укытып, олы юлга чыгардылар. Мөҗәһит үзе дистә еллар Мөслимдә урта мәктәп директоры булып та эшләде. Күп китап авторы. Язган һәм нәшер ителгән китапларын миңа да бүләк итә. Авылда төп йортны да ташламыйлар. Бания белән икесе дә төпле акыл ияләре. Авылның киләчәге алар кулында. Зиратта өмә булса, Мөҗәһит Мөслимдәге ике улын да алып кайта. Әти-әниләрен күп еллар тәрбия кылып, соңгы юлга озаттылар. Ходай алдында йөзләре якты. Олыларның бәхиллеген алып калу – бик зур нәрсә ул. Аларга теләгем шул: озын гомер, тыныч тигез тормыш, гаилә бәхете, саулык насыйп булсын! Язган каләменең очы сынмасын, һәрчак файдалы эш эшләсен. Мөҗәһитләрнең гаиләсе бар кешегә үрнәк. Мин аларның балаларының, оныкларының ярты-йорты урыс сүзен кертеп сөйләшкәнен белмим. Боларда чын татарлык күренә. Мондый гаиләләр күбрәк булса, милләтем бетмәс, дип өметләнергә була.

Ә чиратта – минем бердәнбер улым – Лемон Леронов. Ул, Ләбиб Лерон тәхәллүсен алып, татар әдәбиятында юмор остасы, шагыйрь һәм драматург буларак танылды. Хәзерге вакытта «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире булып эшли.

ХАСТА АВЫЛЫМ

Коточкыч чирләргә дучар булды авылым. Мин бәләкәй чакта юк иде алар.

Авылымның беренче чире. Безнең өйнең каршы ягына яңа мәктәпне Зәйнак Вәлиев председатель чагында 1964-1968 елларда салдылар. Мәктәп директоры Салихов абый иде. Мәктәп ихатасын әйләндереп тоткач, аның тирәсенә «кытай чаганы» (тагын ничек дип аталадыр ул, белмим) утырттылар. Бу агач безнең авылда бөтенләй юк иде. Шуннан аларның орлыклары бөтен авылны басты, мәңге бетмәс чиргә әйләнде. Ник шул вакытта матур һәм юньле агач утыртмаска иде инде?!

Мәктәпнең урам як, ал өлешен башка йортлардан алга чыгарып салдылар. Безнең күрше өч йорт урам аркылы күпкә кимеде, янгын мәсьәләсендә дә куркыныч.

Авылымның икенче чире. Монысы – шайтан таягы. Ул, кыргый агачлар кебек, ор-

лыкларын бик тиз тарата, тамырдан үрчи. Монысы да мин белгән елларда юк иде. Боларны хайваннар да ашамый. Безнең районда бу шайтан таягын беренче мәртәбә Мөслимгә олы юлдан узганда Метрәй авылы янындагы су буенда, ферма тирәсендә күрдем. Бу турыда, ник боларны бетермиләр, дип, Яңа Карамалыдан укытучы Кәримов абый язып чыккан иде. Аннан соң бу шайтан таягы берничә ел эчендә бөтен районны басып алды. Моны бетерү турында уйлаучы юк. Кызганыч.

Безгә ике йорт аша күршем Шәрипов Гаян агай озак еллар колхозда эшләп, гаилә корып яшәде. Тумышы белән Яңа Уразмәттән иде. Аның белән озаклап дөнья, сугыш хәлләре турында сөйләшеп утырган бар. Бер аягының тездән түбән өлеше пешкән помидор сыман булып, төзәлмичә интегеп яшәде, аксаклап йөри иде. Балта эшенә бик оста иде. Колхозда төзелештә эшләде. Йорт салганда, кешеләргә дә булышты. Җитмеш яшен тутырып бетермичә, төп йортка «кайтып китте».

Авылымның тагын эш сөйгән бер кешесе бар иде. Исеме Мирсәет иде аның, туган елы 1928 булса кирәк. Бик оста аучы иде ул. Күп эшләрдә эшләде. Соңгы вакытта ул Мизхәт агай белән «Беларусь» тракторында хезмәт куйды. 1960-1970 еллар арасы, өченче декабрьләр тирәсе иде шикелле. Ул көнне иртән көн әйбәт була. Кичкә бозылып, көчле буран чыга. Иртән Мөслимгә машина белән ит наряды өчен маллар төяп алып китәләр. Маллар өчен печән төяп, Мирсәет агай кабинасыз «Беларусь» белән Мөслимгә юл тота. Исән-имин печәнне бушатып, кич белән авылга кайтырга чыга. Олы юлда аны Газраил саклап торган. Кайту юлында Яңа Усы авылын чыгып урманга кергәндә агач күпер бар иде. Шунда Мирсәет агай тракторы белән күпергә керә алмый, көчле буран булгач, трактор, кирегә борылып, күпер астына китә. Авылга кайтмагач, Фазаел агай, Тимерхан аны икенче көнне тракторы астыннан табып ала, ул үлгән була инде. Мирсәет абыйны алып кайтышырга мин дә бардым.

Башлангычтан алып җиденче сыйныфны бергә тәмамлаган дустым Миргазиян Закиров бар иде. Ул соңыннан Васил дустым Әхмәтҗанов (булачак композитор, «Озата барма» дигән атаклы җырның көй авторы) белән Минзәләдә педучилищеда укып, югары белемгә ия булды. Пенсиягә чыкканчы укытучы һәм соңыннан Сал. Муханда мәктәп директоры булды. Пенсиягә чыгу белән йөрәк чиреннән кинәт кенә төп йортка китеп барды. Олы абыйсы Камчатка ягына китеп, кире авылга кайтмады. Исеме Фәттах иде аның. Миргазиянның тагын бер энесе Галәетдин бар иде, эшкә киреләнеп тормады, авылда күп эшләрдә эшләде. Елын әйтә алмыйм, үзенә 55 яшьләр булгандыр, көз көне Төмән ягына гаиләсе белән чыгып китте һәм бер-ике айдан үзе генә авылга кайтып күренде. Аны азаккы күреп калуым шул булды. Киткәч, озак та тормый мәңгелеккә күчкән. Аларның бар иде тагын ике апасы. Ата-ана йортын тараткан бала-чага Аллаһ каргышы ала, дип бер әйткән идем бугай инде. Төп йортны нигезенә хәтле сүтеп-төяп, Миргазиян Муханга алып китте, бер-ике елдан үзе дә бакыйлыкка күчте. Менә нинди язмышлар, әмма дөресе шул. Хәзер аның төп йорты урынында агачлар, кыргый үләннәр үсә.

Авылымда нигезе таралган берничә йорт бар. Әле балалары да исән. Йорт урынын әйләндереп куйсалар да әйбәт булыр иде, юк шул, дөнья куалар. Кая барганнарын гына белмиләр! Авылымның үткәне һәм киләчәге күз алдымда тора. Соң, мин ни эшләтим боларны? 80 яшьнең өстендә бит инде...

Газраил мине берничә тапкыр алып китәргә килде. Дүрт тапкыр суга батып үлә яздым. Бер тапкыр басуда җир сөргәндә үз-үземне таптатып үтерә яздым. Ходай саклады инде. Аллага шөкер, әткәй һәм бабам гомерләрен бергә кушсаң, шуның хәтле яшәдем бу дөньяда. Шөкер Аллаһка, әниемә һәм Хәкимәгә – яшәргә көч биргәннәре өчен... Бу дөньяда шуңа шатмын. Үсмер чакларда туйганчы икмәк ашап эшли алмадык. Әмма икмәк үстерүдә үземнән өлеш кертүемә бик сөенәм. Ач булмасыннар, ашап үссеннәр

Мәктәп кенә түгел, бу парталар да юк инде хәзер

һәм файдалы эш эшләсеннәр. Ә бар бит әзер ризык ашап та кешеләрне талау, кыйнау, үтерү, дәүләт милкен туймас хәлдә үзенеке генә итү. Менә боларга йөрәк әрни инде.

Авылымнан дистәләгән яшьләр сугыштан соң шахталарга – Кемерово өлкәсенә (Кузбасс), Донбасска китте, араларында урыслашып китүчеләре дә булды. Кайберләренең исемнәрен әйтеп узыйм әле. Нияз аганың абыйсы Вәкил, Гариф агай – безнең күрше Илгизнең әнисе белән туганнар, безгә кардәш, Гаттаров абыйның энесе Рифкать. Миннән бер яшь кече Разин гаиләсе белән Кемеровога китте. Мәрхүмнәре дә бар инде, кызганыч авылдашларым. Авылдашым Нәҗип агайның ике улы, бер кызы Донбасска юл тотты. Кайчакларда кайткалап, авылның хәлен белеп киткәлиләр инде. Менә шулай бәхет эзләү, акча артыннан туган җиреңнән аерылу. Ә бит шушы чыгып киткәннәрнең бер генә баласы авылда калса да, монда эш булып яшәсәләр, авылым юкка чыгу хәленә җитмәс иде. Адәм баласы, дөньяга килеп, ник шулхәтле туган җирдән читләшә соң?! Чыгып китеп, әти-әнисен дә соңгы юлга озата алмыйлар, ләкин бит андыйлар үзләре дә чын бәхет тоеп яшәми. Казан шәһәрендә гомер иткән булып та, ата-ана нигезенә кайтып баш ия белмиләр. Туң-таш йөрәкләр, дияр идем аларны. Әй, язмыш уйлары кая гына алып китми!..

Авылымның өч бензовоз шоферы – Хәбибулла агай, Әнвәр агай, Рафаель агай озак еллар шул бер эштә эшләде: колхозларга ягулык (горючий) ташыдылар. Бик эшчәннәр иде. Ул чакта Күбәккә бик күп укучы йөри иде. Менә шушы шоферлар балаларны бензовоз өстенә тотындырып (югыйсә, аларга кеше йөртү тыела бит), иртән дистәләгән баланы эшкә барышлый Карамалыга кадәр алып төшәләр иде. Бу көнгә берсе генә (Рафаэль агай) исән. Рәхмәт аларга, урыннары җәннәттә булсын. Минем белгәнемчә, әти сугышка киткәч, күпмедер вакыттан соң, авылга тимерче булып эшләргә Мөслимнән Галимҗан исемле агай гаиләсе белән килде. Күпме эшләгәнен хәтерләмим. Алар безнең белән янәшә генә яшәде. Бер олы кызы һәм ике малае (Риф, Алмаз) бар иде. Галимҗан агай эшкә булган кеше иде.

Икенче гаилә – авылдаш Габдулла агай гаиләсе. Аларның өе Хәбибулла агайлар янында, чокыр буенда иде. Бер кызлары һәм бер малайлары (Рәмзи) бар иде. Габдулла

агайның малае Рәмзи, тимерче агайның малайлары янына килеп, уйнап, бергә тимер мич өстенә бәрәңге кискәләп кыздырып ашыйлар иде. Менә бер тапкыр Галимҗан агай эштә чагында 3 малай кыздырып бәрәңге ашап алалар. Төрле уеннар уйныйлар. Менә берчак Риф исемле малае өйдә әтисенең корылган мылтыгын алып атып җибәрә. Шушы атудан Рәмзи үлә, энесе яралана. Уен фаҗига белән тәмамлана. Шуннан Габдулла агайның башыннан зур кайгылы көннәр үтә. Үзен сугышка алмаганнар иде. Колхоз икмәк сукканда, хатын-кызлар носилка белән саламны читкә алып барып өяргә куялар иде. Менә шушы саламнарны Габдулла агай агач сәнәк белән эскерткә ата иде. Язмыш аны бик сынады.

Авылымда төрле язмышлы кешеләр яшәде. Күпләре мәрхүмнәр инде. Безгә дә төп йортка китәргә вакыт җитә. Алай да бар кеше, шул исәптән өстәге тиран, кешеләрне кол итүчеләр дә, халыкның байлыгын талаган оятсыз бәндәләр дә үлемнән качып кала алмый, ул барын да тигезли. Монысы әйбәт.

«Утлы кисәү»нең кайбер өлешләрен искә төшерәсе килә. Түрештән 67 югары белемле кеше чыкты, диеп язган идем инде. Төрле профессия кешеләре. Яшь буынга төпле белем бирүдә төп роль укытучыдан тора. Моны дәлилләп, бер мисал китерәм: сугыштан соң безнең авылга ирле-хатынлы Салихов абыйлар килде һәм пенсиягә чykканчы укыттылар. Икесе дә бик тәртипле иде. Болар инде башлангыч белемне төпле итеп, җиренә җиткереп бирделәр. Мин әйтер идем, мондыйлар ул чорда районда берничә генә булгандыр. Ни гаҗәп, аларга бернинди мактаулы исемнәр бирмәделәр, хәтта Хәсән ага пенсиягә чыкканда районнан мәгариф бүлеге вәкиле дә килеп бер мактау сүзе әйтмәде. Ә бу җыелышта Хәсән ага турында авылдашлар миңа сөйләргә куштылар. Мин бу бурычны исән-сау башкардым. Клуб тулы иде. Авылдашлар алдан барысы да акча белән ярдәм итеп, Хәсән абыйларга телевизор бүләк иттек. Бик күңелле кичә булды. Икесе дә соңгы көндә авылыбыз зиратына җирләнделәр, урыннары җәннәттә булсын. Алар укыткан мәктәп яртылаш сүтелеп, ихатасы ташландык хәлдә, безнең өйгә каршы як урамда. Авылдан сугыш узып киткәнмени... Хәзер клуб, кибет, мәктәп юк инде. Ә мәктәп ишегалдында ауган коймалар, киселгән агачлар, өстән киселгән агач төпләре тора. Әй, язмыш!.. Шулай итеп, авылым азакказ сулышын сулый инде. Ә авылымның төзелә башлавына 2021 елда 100 ел була. Болар бар да дөрес.

Бу язмам дустым һәм хезмәттәшем, бик күп тракторларны иярләп, колхоз һәм район күләмендә танылган шәхес Миргали (фамилиясен хәтерләмим) турында. Ул үзе Күбәк авылыннан, Күбәк урта мәктәбен яхшыга укып бетерде. Миргали әнисе белән генә үсте. Армия сафларында хезмәт итеп кайтты. Армиягә хәтле дә тракторда эшләп китте. Аннан кайткач, гомеренең соңгы көненә хәтле колхозда тракторда эшләде. Авырганда да эшен калдырмады, гадел, тырыш, ярдәмчел иде. Ни кызганыч, бу тормыштан иртә, 50 яше тулгач та китте. Аны Күбәктә җирләделәр. Соңгы юлга озатырга Түрештән җәяү төштем. Анда соңгы хушлашу сүземне әйттем. Миргалине озатырга халык күп килгән иде. Район җитәкчелегеннән дә кешеләр бар иде. Урыны җәннәттә булсын.

Арттан ияреп йөргән «утлы кисәү»нең тагын бер өлешен языйм әле.

Ул ничек итеп өйлек агач әзерләвем турында. Армиядән кайтып эшли башлагач, яңа өй салырга агач алыр өчен, урманнан зелпе агач тамыры җыеп, лесникка документын бирдем һәм ул Өске урманда бер җирдә усак агачлары күрсәтте. Яңа Уразмәттә эти ягыннан туган тиешле яшь укучы бала белән кул пычкысы ярдәмендә буралык агач кистек. Берничә көннән шул бала белән ат җигеп, агачларны озын арбага төяп, авылга алып кайттык. Бер өлеше урманда калды. Үзем тракторда эшлим. Кабат урманга керергә вакыт табып булмый. Менә беркөн, агачлар исәнме икән, дип, кискән

Депутат-шагыйрь Роберт Миңнуллин Түреш халкы алдында чыгыш ясый. Утырганнар (сулдан уңга): Фоат Садриев, Хәерзаман Идиятуллин, Харрас Әюпов. 2000 нче еллар

җиргә мендем. Ни күрим, кискән агачлар урынында юк. Нишләргә, кайда эзләргә агачларны? Авылда хуҗалык сарыкларын «Ушаков» яки «сукыр» Салихҗаннар гаиләсе көтә иде. Урманга бер менгәндә, шушы агайны көтү белән очраттым. Һәм аннан бу тирәдә берәр агач төяүчене күрмәгәнме икәнен сорадым. Ул әйтте: Күбәктән Әхтәм бабай агач төяп китте, диде. Ул чагында кохоз рәисе «утызменче» Ихсанов фамилияле иптәш иде. Исемен хәтерләмим. Бик кешелекле, эшен булсынга дип башкаручы намуслы җитәкче иде ул. Авыл советы рәисе замандашым Диктатның әтисе Гали агай иде. Боларны җәяү йөртеп, икесен дә табып, Ихсанов агай бишекле «Урал» мотоциклы белән өчебез Күбәккә шул Әхтәм картларга төштек түбән очка. Ишегалды себерелгән, чиста. Ихсанов агайлар эшнең нәрсәдә икәнен әйттеләр. Әмма Әхтәм карт кире кага. Бер кырда агач өеме ята иде. Менә шуларны актарып карадылар Ихсанов абыйлар. Шушы агачлар астында минекеләр ята иде. Яңадан үзенең каян алып кайтканын әйтте. Әмма агачларны бирмәде. Агачлар киселгән тирәдән шул санда агач кисеп куярмын, диде. Калган агачларны яңадан алып кайтып бетердем. Ул кешенең исем-фамилиясе Хафизов Әхтәм. Колхозда эшләмәде. Авыл советында, «Урожай» колхозында, Сал.Муханда совхозда парторг булып эшләде. Миннән урлаган агачларны пилорамда ярдырып, өй түбәсен япты. Ә мин бик рәнҗедем бу башкисәргә. Елын әйтә алмыйм, берничә елдан йорты-ихатасы янып көлгә очты, яңадан икенче урынга йорт корды. Менә бурлык-комсызлык һәм кеше рәнҗетү нәрсәгә китерә. Мин үз көчем белән хезмәт итеп мал таптым. Дәүләт, колхоз, кешеләр байлыгына кызыкмадым. Күп кешеләргә печән, утын, агач ташыдым. Тиресләр түктем. Бу бит әле совет чоры иде, ә хәзер башкисәрләр адым саен. Кирәк икән, көпә-көндез юк итәләр. Үтерү, көчләү, сую, капчыгы белән акча урлау. Ата – баласын, бала әти-әнисен суя... Акчаны миллионнар белән генә талап яшиләр. Өстәге түрәләрнең күбесенә – кеше һәм дәүләт талаучыларга закон юк. Нигә аларның кулларын кисмәскә? Менә АКШ, Кытай, гарәп илләрендә мондый вәхшиләргә законнар катгый. Халык болай озак яши алмас. Әгәр әти-әниләр теге дөньядан кайтсалар, әйтер сүз тапмыйча шаккатып торырлар иде.

Безнең мирас №7 июль 2017

Киленнәрдән килгән гөсләләр

(Бер фото эзеннән)

Эльмира Каюмова

Билгеле булганча, гөслә – күп кыллы чиртмәле музыка коралы, бүгенге көнгәчә Казан арты керәшеннәрендә сакланып калган. 2013 елның җәендә, гөсләдә уйнау традициясен тирәнтен өйрәнү максатыннан, Балтач якларына юл алдым. Фәнни сәяхәт вакытында Югары Субаш авылында бер истәлекле фоторәсемгә тап булдым. Кызыксына башлагач, халык сәнгатенә кагылышлы әһәмиятле мәгълүматлар ачылып китте. Шул чактыгы эзләнү нәтиҗәләре белән уртаклашам.

Әлеге фото Казан телевидениесендә 1987 елда төшерелгән булса кирәк (әмма төгәл елын белүчеләр юк). Шулвакытта Балтач районы осталары башкалабызга отчет концерты белән килгәннәр иде. Аулак өй күренешендә 3 гөсләче дә катнашкан булган. Алар белән якынрак танышыйк.

Сул як кырыйда – Антонида Васильева (1929-1995), авыл халкы аны Туйна апа дип йөртә иде.

Уртадагысы – Миңнегөл (Мария) Николаева (1934-1996), Арча районы Сәрдәбаш авылында туып, 1956 елны Югары Субаш авылына кияүгә чыга. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп китик: бу төбәк керәшеннәрендә мөселман татарларына хас исемнәр таралган. Кайберәүләрнең ике исеме дә була (мөселманча һәм христианча).

Уң як гөсләчесе – Анфиса Федорова. Ул 1927 елда чиктәш Мари Иле Республикасының Новый Мир авылында дөньяга килә, гаилә корып җибәргәч, Югары Субаш авылына күченеп килә. Экспедиция барышында бу данлыклы башкаручы белән аралашу бәхете дә тиде. Олы яшьтә булып, авырып торуына ка-

Хәлил Фәезов – Ю.Субаш мәдәният йорты директоры, «Туганайлар» керәшен фольклор ансамбленең җитәкчесе. Уңда – Геннадий Дмитриев, Ю.Субаш мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе

Сулда – гөсләче Анфиса Федорова. Уңда – Эльмира Каюмова. Ю.Субаш авылы

рамастан, әңгәмә корыр өчен тиз генә киенеп-ясанып, яшь кызларча җыенып та куйды. Чынлап та, халык аны яратып Матур Әмпис, дип юкка гына атамаган. Шулай ук бу – сәхнәдә күп чыгыш ясау тәҗрибәседер.

Бөтен гөсләләр бер төрдә һәм кулдан ясалган. Югары Субашта аларны җитештерүче җирле оста да – Ананий Семенов (1914-1986) булган.

Сораштырып йөргәч, барлыгы 11 гөсләченең исемнәре билгеле булды (иң өлкәне – 1895 елгы). Ләкин субашлылар фикеренчә, гөсләне аларга тирә-як керәшен авылларыннан (Сәрдәбаш, Новый Мирдан) киленнәр алып килгән.

Матур Әмпис артында басып торган тальянчы – Николай Федоров. Алар еш кына икәү бергә уйнарга ятраткан-нар (гөслә белән гармун дуэты).

Фоторәсемдәге курайчы махсус игътибарга лаек. Ул – Радик Фролов, музыка укытучысы. Заманында мәктәптә курай түгәрәген, авылда исә тынлы оркестр оештырган шәхес! Өрмә уен коралларын да үзе ясаган.

Арттагы рәттә баян тотып төшкән кеше – Радик Дмитриев (1955 елгы), хәзер Казанда яши. Янәшәдә (иң кырыйда) аның энесе – Геннадий Дмитриев (1963 елгы), Субаш мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе, төрле музыка коралларында уйный белә. Шулардан: курай, кубыз, гармун, баян, сорнай, бәрмә музыка уен кораллары, ә соңгы елларда гөсләне дә үзләштергән.

Чарада күпчелек Югары Субаш вәкилләре катнашты. Алардан тыш, икенче рәттә карадан киенгәне – Балтачтан Рамазан бабай (тальянчы, гармун ясаучысы) һәм аның янәшәсендә – Радик Михайлов (күренекле шәхес, озак еллар буе районда мәдәният бүлеген җитәкләп, җирле фольклор традицияләрен саклауга саллы өлеш керткән кеше).

Сүземне төгәлләп, шуны әйтәсем килә: без еш кына шартлар, матди ярдәм булмавына зарланып, хөкүмәтне яки кемнедер гаепләргә яратабыз. Ә күп нәрсә үзебездән тора лабаса! Хәтта бер генә кешедән дә! Субашлылар, бернигә дә карамыйча, авылларында менә дигән иҗади тормыш белән яшәгәннәр, хәзер дә шулай гөрләп яшиләр. Үзләре сәләтле, үзләре актив! Элеккеге мәдәният йорты башлыгы Илья Васильевны (фотода ул уңнан икенче) җылы сүзләр белән һаман искә алалар. Хәзерге директоры да – Хәлил Фәезов (1967 елгы), «Туганайлар» керәшен фольклор ансамбльнең җитәкчесе, уңышлы эш алып бара.

Э.Каюмова фотолары ■

Безнең мирас №7 июль 2017

БАР ДӨНЬЯГА ГАШЫЙК ҖЫРЧЫ

Алсу Хәкимова

Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев – Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләүче моңлы тавышлы олпат җырчы. Шуңа өстәп, дөньяны бөтен нечкәлеге белән сиземләүче шагыйрь дә ул. Шигырьләрендә, матбугатта әледән-әле чыга килгән мәкаләләрендә җан чисталыгына, рухи байлыкка, гүзәллеккә, матурлыкка мәдхия җырлый.

– *Георгий абый, Сез филармониянең яшь җырчылары өчен әйдаман, аларның икенче әтиләре сыман...*

– Хактан да, безнең әдәби-музыкаль лекторийда күбесенчә яшьләр эшли. Аларга кирәк чакта (бигрәк тә татар халык җырларын, татар композиторлары әсәрләрен башкарганда) киңәшләремне бирәм. Бүген тамашачы яхшы җырга, чын тавышка сусаган. Безнең концертларда халык җырлары да, классик арияләр дә яңгырый. Яшь тамашачыларда зәвык тәрбияләү дә эшчәнлегебезнең бер юнәлеше булып тора. Шуңа күрә, ел башыннан ук балалар белән мәш киләбез. Сәнгать җитәкчесе Владимир Васильев быелтыр «Буратино» музыкаль әкиятен сәхнәләштергән иде. Быел да зур уңыш белән узган Яңа ел тамашаларында мин Шүрәле сыйфатында катнаштым. Анда

килгән сабыйларның, әти-әниләренең күзендә сөенеч-шатлык күреп, мин дә сөендем, мин дә шатландым.

– Сез, филармония концертларыннан тыш, хөкүмәт дәрәҗәсендә уза торган төрле мәдәни чараларда да еш чыгыш ясыйсыз.

– Җитәкчеләр алдында да җырларга туры килә. Заманында Татарстан хакимияте А.Лукашенко, С.Кириенко, С.Шахрайлар белән уздырган очрашуларда чыгыш ясадым. Нигездә, татар халык җырларын башкардым. Узган ел Казанга эшлекле сөйләшүгә килгән казакъ, кытай, әрмән җитәкчеләре хозурына чакырдылар. Программада утызга якын татар җыры иде. Җырлап бетергәч, яныма бер кытай кешесе килде дә: «Без һушсыз калдык, яшьләр болай җырлый алмый», – дип рәхмәт белдерде. Аңа карап Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов: «Бездә алтын бәһасенә торырлык җырчылар бар, дип әйттем бит мин сезгә!» – дип елмайды.

Шулай ук, әдәби-музыкаль чараларда, искә алу кичәләрендә еш катнашам. Форсат тууга, туган ягыма – Мамадышка кайтырга тырышам. Якташларым белән чиксез горурланам. Алар да мине хөрмәт итә кебек.

– Туган авыл сагындыра, димәк?

– Аның һәр тарафын, һәр почмагын тоеп-сагынып, шунда үткән балачак мизгелләре белән илһамланып яшим. Владимирга еш кайтырга тырышам. Үзем салган йортым бар. Кышын кайткач мичкә ягып җибәрәм дә, ут йөгергән утын пүләннәренә карап, балачак елларын искә төшерәм. Әтиемнең күмер төшкәнен күзәтүен, әниемнең мич алдына чуен белән карабодай боткасы куюын яки бәрәңге тәгәрәтүен күз алдымнан кичерәм. Элек-электән күрше-күлән безгә җыелырга ярата иде. Нардуган, Яфрак бәйрәмнәрендә өйдә тәмле ризыклар пешерелә, ишегаллары җыештырыла. Ә туйлар ничек матур үтә иде бездә! Теләкләрне җыру җырлап җиткерү, такмак әйтү... Алар барысы да хәтердә матур-матур сәхифәләр булып калганнар.

Безнең авылны һәрьяктан урман каплаган. Бөдрә таллар, зифа каеннар сак-сак атлап өйалдыбызга килеп керер сыман. Кучтырай сукмагыннан узганда табан аслары кытыклана, янәшә үскән кыңгырау чәчәкләре зеңләп-зеңгелдәп торган кебек иде. Озын тупыллар, шомыртлар арасында утырган Сәрки Питеренең бакчасын койма аша гына күзәтә идек. Бик каты әче алмасы бар иде аның. Шайтан котырткандырмы, кайчагында шул алма артыннан бакчага да кереп чыккалый идек. Чишмәләр күп иде бездә, челтерәүләре әллә каян ишетелеп тора иде. Бөтнекләр үсә иде...

Авылда «Алпар тугае» дигән җәйләү, шунда ук кечкенә инеш тә бар. Бала-чага шунда су коена иде. Аннары аякларны салындырып үзара гәпләшеп утырабыз: «Җир читееракмы икән?» Берсе: «Күрше авыл Үсәлидән соңдыр», – ди. Икенчесе-өченчесе: «Безнең туганнар Казанда, безнеке Әлмәттә», – ди. Ахырдан, «Гриша дәдәйнең машинасыннан башка җир читенә барып булмый», дигән нәтиҗәгә килә идек.

– Сез, җырчы буларак, илебезне иңгә-буйга узган кеше, үзгә илләргә дә шактый сәфәр кылдыгыз... Сабый чакта тынгы бирмәгән сорауга җавап тапкансыздыр, шәт?

– Шөкер, Ленинградтан (хәзерге Санкт-Петербург) алып Владивостокка кадәр араны уздым. Соңгы ун ел эчендә Американың, Төркиянең иң зур шәһәрләрендә җырчы Резеда Галимова, музыкантлар Кирам Сатиев, Рөстәм Вәлиев белән чыгыш ясарга туры килде. Татарстанның халык уен кораллары дәүләт оркестры белән Көньяк Кореяда, Казакъстанда булдык. Җир түгәрәк икән. *(Көлә.)*

Мин кечкенәдән рәсем ясарга яраттым. Табигать кочагында үсүем дә моңа тәэсир иткәндер. Алтынчы сыйныфны интернатта торып укыдым. Атна ахырында таң белән уянам да болын буйлап авылга йөгерәм. Ноябрь башы, җиргә кырау төшкән. Авылга җитәрәк, күз алдыма баскан манзараны күреп

туктап калам: минем каеннарым апак бәскә төренгән – сулышым белән җылытасы, иркәлисе килеп китә. Мин аларны үземчә рәсемгә төшерәм, күңел дәфтәремә сеңдерәм.

– Табигать турында шулкадәр яратып сөйләгәннән соң җырчы булып китүегез һич тә гаҗәп тоелмый...

– Телем ачылганчы ук «җырлый» башлаганмын. Сыер саварга баручы апайлар мине кәнфит-перәннек биреп, төрлечә юмалап җырлата торган булган. Мәктәптә укыганда җырлаттылар инде, билгеле. Укытучым Роза Шаһиевна башлангыч сыйныфларда ук: «Минем музыка факультетында укучы сеңелем бар, сиңа Казанга, аның янына барырга, җыр буенча китәргә кирәк», – ди иде. Ул безгә матур китаплар укый, табигатькә алып чыга иде. Үсәлигә укырга төшкәч, Мәрьям апа Мозаффарова мәкаләләр язарга бирә башлады. Рәсемнән безне күренекле нәкышче, рәссам Нәҗип Нәккаш укытты. Ул миңа: «Рәсем ясарга осталыгың бар», – ди иде. Гомумән, шөкер, укытучылар миндәге сәләт орлыкларын күреп, ничек тә шуны үсенте итәргә, тормышта куллана белергә өйрәтте. Рәхмәт аларга!

– Зур сәнгать дөньясына аяк басуыгыз кайчан һәм ничек булды?

– Мәктәпне тәмамлаган елны «Комсомол җыры – 75» конкурсына Казанга юлладылар. Жюри алдында «Туган җирем Татарстан», «Комсомолка Гөлсара» җырларын башкарып, дипломант исеменә ирештем. Шулчакта Миңгол абый Галиев күреп алып, консерваториягә укырга керергә киңәш итте. Авыл баласы бит – анда керер өчен имтихан тапшырырга кирәклеген кем белсен! Печән-утын әзерләп бетергәч кенә, җырлап карыйм әле, дип, Казанга юл тоттым. Миңгол абый: «Имтиханнар күптән тәмамланды бит», – дип уфтанып, мине Нәҗип Җиһанов янына алып китте. Икенче сентябрь көнне килгәч, күрәм: биш кеше утыра, Җиһановтан кала берсен дә белмим. Рөстәм Яхинның «Күзләрем тик сине эзлиләр» һәм татар халык җырын «Су буйлап»ны башкаргач, Нәҗип ага: «Каян өйрәндең бу җырларны?» – дип сорады. «Радиодан ишеттем дә, отып алдым», – дип җавапладым. Ул: «Без сине алабыз, тавышың матур. Кызганыч, соң килдең, тулай торакта урыннар юк инде, икенче елга гына булачак», – диде. Торыр урын булмагач, «авылда мунча да өлгертәсе бар иде әле», дигән сылтау табып, Миңгол абыйдан чемоданымны «урлап» качтым. Шул кызудан армиягә киттем.

– Армия белән җыр ничек яраша алды соң?

– Хәрби хезмәтне үтәгән җирдә татар егетләре берничә генә иде. Шуңа күрә, рәхәтләнеп татарча сөйләшергә ирек бирмәделәр. Урыслардан качып, казарма артында гына рәхәтләнеп татарча сөйләшәбез, татарча җырлыйбыз. Көннәрдән беркөнне безнең взводны ашханәгә нәрәткә куйдылар. Мин аш бүлеп торырга тиеш идем. Зур бүлмә. Беркем дә юк. Шунда онытылып җырлый башлаганмын. Артыма борылып караган идем – ун-унбиш кеше җыелып мине тыңлый икән. Икенче көнне командир чакырып алды: «Матур җырлыйсың икән, җырла әле», – диде. Мин: «Урысча бер генә җыр беләм», – дидем. «Син миңа татарча җырла», – диде ул. Безнең полкны Германиягә җибәрергә тиешләр иде, бу вакыйгадан соң командир: «Син монда кирәк, җырчы егет», – дип, мине беркая да җибәрмәде.

Тормышымда миңа яхшы кешеләр генә очрап торды. Армиядә хезмәт итеп кайткач, Түбән Кама нефтехимия заводына эшкә урнаштым. Казаннан телеграмма килеп төште. Нәҗип Җиһанов укырга чакырып язган. Баргач та: «Кая югалдың син, керәшен малае, сине укырга алган идек бит», – дип шелтәләп алды. Шулай итеп, яңадан имтиханнар биреп, консерваториягә укырга кердем. Бу юлы тулай торакта куыш табылды инде.

– Һәм, укып бетергәч, филармониягә эшкә алдылар?

– Анда да укытучымның киңәшеннән башка булмады. Әлфия апа Заһидуллина мине үсендереп: «Сине анда көтәләр», –

дип, җитәкләп диярлек алып китте. Килеп кердек. Әлфия апа ары чаба, бире чаба – безне беркем дә күтәреп торган кебек күренми. Директор: «Лекторий тулы, кая алыйм мин аны?» – ди икән. «Ярар, татар халкына кирәкмәсә, Башкортстан, Свердловск аны хәзер тартып алыр. Әмма бер дә читкә җибәрәсе килми иде», – ди икән Әлфия апа. «Әйдә, комиссия җый, алайса», – дигән директор. Унлап кеше алдында дистәдән артык катлаулы арияләр, халык көйләрен башкардым. Бермәлне карасам – Илгиз Мәҗитов елап утыра. Аннары олы гәүдәле бер кеше мине кочаклап алды да, кулымны кысып, күздән югалды. Ул директор Марат Таҗетдинов булып чыкты. Әлфия апага: «Үз акчамны түләсәм түлим, алабыз бу егетне», – ди икән. Шулай итеп, мин Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең әдәби-музыкаль лекториенда эшли башладым. Ул чакта бүлектә кырык дүрт кеше идек. Һәрберсе асыл сәнгать осталары: Венера Шәрипова, Айрат Арсланов, Гали Ильясов, Нажия Теркулова, Әлфия Галимова һ.б. Бер гаилә булып тату эшләдек. Атна-ун көннән соң мине директор Краснодар шәһәренә җыр конкурсына җибәрде. Баянчы Нәҗип Бәдретдинов белән: «Без барыбер үтмибез инде», – дигән фикердә йөзеп йөргәндә, кинәт, икенчесе турга да, өченчесенә дә уздык. Казанга диплом белән кайткач, директор, уңышыма сөенеп, миңа йөз илле сум оклад язды. Кайберәүләр дистә еллап эшләсә дә, айга йөз сум гына ала иде ул чакта. Шөкер, эшчәнлегем шулай уңышлы башланды.

Тора-бара шәхси тормышымны да көйләргә вакыт җитте. Скрипкачы кыз Әдилә белән радиода танышып, очраша башладык, күп тә үтми өйләнештек. Ул вакытта кооператив фатир бирәләр иде, фатирлы булдык. Бер-бер артлы балалар туды.

Музыкаль гаилә

– Сезнең гаиләне «музыкаль гаилә» дип атарга мөмкин. Җәмәгатегез Әдилә ханым озак еллар Татарстан Республикасы симфоник оркестрында эшли. Улларыгыз да музыкант түгелме?

– Ике улым да консерватория каршындагы музыка мәктәбендә скрипка классында белем алды. Үзләре өчен уйныйлар, әмма тормыш итәр өчен башка һөнәр сайладылар. Аларның хезмәт сөючән, игелекле булуларын күреп куанам.

– Георгий абый, Сез язмышыгыздан канәгатьме?

– Мин язмышыма – җырыма чиксез рәхмәтлемен. Бу хисләр шигырьләремдә дә чагыла. Кайбер хыяллар чынга ашмаса да, үз урынымны таптым, дип саныйм. Авызымны ачып кына, әзергә-бәзер бер телем икмәк тә капмадым. Барысы да Ходай биргән сәләтем, хәләл көчем белән эшләп алынган. Шуның белән горурланам да. ■

Безнең мирас №7 июль 2017

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

«Мичкәле арбаны тартып баручы ике ир-ат». Королева Матильда гобелены. Франция. XIV-XV гасырлар

ТӘГӘРМӘЧ – «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә: «Күчәрдә әйләнеп, арба, автомобиль, вагон һ.б.ш.ны хәрәкәтләндерергә хезмәт итә торган (кигиле яки тоташ) түгәрәк; көпчәк». Тау ягы керәшеннәре сөйләшендә – *йөгөртмә.*

Тәгәрмәч безнең эрага кадәр 4 нче меңьеллыкта Борынгы Шәрыкта уйлап табылган (уртасы тишекле агач бүкән). Кыргыз телендә *чәләк* – агач чиләк, *тәгәрмәч көпчәге* (Р.Әхмәтҗанов). Моннан без «чиләк» сүзенең башта куыш агачны белдергәнен һәм, икенчедән, беренче тәгәрмәчләрнең чыннан да куыш агачтан гыйбарәт булганлыгын чамалыйбыз. Кигиле һәм бөгеп эшләнгән тугымлы тәгәрмәч исә б.э.га кадәр 2 нче меңьеллыкта барлыкка килә. Соңгы вакытларда тәгәрмәчне, имештер, башкортларның элгәрләре уйлап тапкан, дигән әкәмәтрәк «фөкер»нең фәнгә катнашы юк.

Арба тәгәрмәче агачны бөгеп эшләнгән тугымнан, агач бүкәннән һәм аларны тоташтыручы агач киги-тырнаклардан тора. Ныклык өчен тугымга коршау-шин беркетәләр. Тәгәрмәч

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

бүкәненең дә һәр ике ягына коршау сугыла, куышлыгына ике яклап тимер алка кагып кертелә.

Түгәрәк сүзе дә шул тамырдан. «Тәгәр» белән «чыгыр» арасы да ерак түгел шикелле. Каюм Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда очрый торган *күк тигерәсе* күк тәгәрмәче, күк чыгыры, ягъни күк гөмбәзе мәгънәсендә.

Диалектта *тәгәр* сүзе дә бар, ул кечкенә тәгәрмәчкә карата әйтелә. Сөйләмдә тәкермәч варианты күзәтелә.

//Эздән тайган галәм арбасында / Зыр әйләнә дөнья тәгәрмәче... Йолдыз Миңнуллина. Тимерле тәгәрмәч – тимер коршаулы тәгәрмәч. Моннан электә тимер коршау сугылмаган тәгәрмәчләр дә булганлыгын аңлыйбыз.

ТӘКЪДИР *г.* – **1.** Фәләк, язмыш, күрмеш *(диал.)*, кадәр; нәсыйб (насыйп), очрак.

«Тәкъдир – булмастан борын булачак нәрсәнең булуын тәгаен кылып куюю димәкдер». «Аллаһы Тәгалә һәрбер нәрсәне вә һәрбер эшне булмастан борын үзенә мәгълүм булган рәвешчә такъдир кылып куймышдыр». «Бәндәләр һәрбер кылган фигыльләрен үз ихтыярлары илә кәсеп кылсалар да, аларга куәт бирүче Аллаһы Тәгаләдер». (Ризаэддин Фәхреддин буенча.)

Ки тәкъдир булмагай тәбдил – тәкъдирдә язылган үзгәрми. Г.Кандалый.

Тәкъдирдә ни язылса, ана карынында ук шул килер. Хәдис.

Аллаһы Тәгалә җан яратуны тәкъдир иткән икән, шул эш булмый калмас. Хәдис.

Сакланып кына тәкъдирдән котылып булмый. Хәдис.

Бетердем шиңдереп төрле гүзәл чәчкәмне барсын да Явыз тәкъдир, каты тәкдир, суык тәкъдирем астында. Тукай.

Коръән Кәримдәге «Комлык» сүрәсенең 9 нчы аятендә болай диелгән: *«Әйткел: Мин пәйгамбәрләрнең тәүгесе түгелмен һәм миңа үзем белән яки сезнең белән ниләр булачагы билгесез».* Ләкин Мәүлана Мөхәммәд Али, Пәйгамбәргә теге яки бу фирканең ахыргы язмышы бөтен ваклыкларына кадәр генә билгеле булмаган, дип яза.

Шәгъбан аеның 15 нче көненә каршы төндә яфракларына якты дөньядагы кешеләрнең исеме язылган тормыш агачы селкенә дә исеме язылган яфрак коелып төшкән кемсә шушы ел дәвамында үләчәк, дигән ышану бар. Тагын кара: ***Кадер.***

//Тәкъдири хата – язмышны хәл итә торган хата, русча – *роковая ошибка.*

2. Берәүнең эшләгән эшен тану; бәя бирү, бәя билгеләү; ихтирам итү; презентация (Фатих Кәримидә – *прэзэнтә итү*). *Танытма* сүзе дә кулай шикелле. *//Тәкъдир ителү* – тиешле бәясен алу. *Гаяз әфәндене без дә тәкъдир итүчеләрдәнмез, ләкин аны тәнкыйть кабул итмәслек бер харика, бер могҗиза диеп белмибез.* Җамал Вәлиди. *Чыкты ахры бездән дә бер бөтен кеше; Яхшы аңлап, тәкъдир итү читен кеше.* Тукай. *Ниһаять, Р.Мәрдановның үзеннән элек иҗат иткән авторларның хезмәтләренә карата игътибарлы булуы да тәкъдиргә лаек.* Миркасыйм Госманов.

ТӘРҖЕМӘ *г.* – Бер телдән икенче телгә күчерү, авыштыру, аудару. *Рәҗәмә* (кайтаваз, кайтып яңгырау, эхо) тамырыннан. *//Хәрфиян тәрҗемә, хәрфи тәрҗемә* – хәрефкә хәреф (сүзгә-сүз) тәрҗемә (русча – *буквальный перевод, дословный перевод*). *Тәрҗемәче* – тылмач, телмәрче, тәрҗеман. *Синхрон тәрҗемә* – турыдан-туры телдән тәрҗемә (мәс., дипломатиядә тылмачлык).

Керәшеннәрнең дини текстларында *тәрҗемә итү* мәгънәсендә фәкать күчерү сүзе генә алынган (русча «перевод» сүзенең калькасы).

*Тәрҗемә*нең күплек саны шәкеле – *тәраҗим.* ■

Безнең мирас №7 июль 2017

СҮЗ ТУРЫНДА БЕР-ИКЕ СҮЗ

Гомәр Бәширов

Мәдәни үсешебез телнең сафлыгын күз карасы кебек саклау, һәр сүзнең кадерен белеп, аның дөрес әйтелүенә, матур яңгыравына ирешүгә омтылу кебек югары баскычка менеп җитмәгәндер әле. Тел белән ваемсыз эш итүләр колакны тырный, күңелне рәнҗетә торган сүз бозулар, матбугатта булсын, сөйләм телендә, аерым язмаларда булсын, кызганычка күрә, әледән-әле очрап кына тора. Соңгы елларда каяндыр сүзләрне кыскартып язу чире килеп чыкты. Моның белән мәктәп балалары гына түгел, хәтта зурлар да авыргалый. Миңа килгән бер хат шушылай тәмамлана: «К. с. б-н Зөлфия». Бу табышмакны үзем генә чишә алмагач, мин Зөлфиягә хат яздым. Ул моңа бик гаҗәпләнде. «И, абый, шуны да аңламыйсызмыни? Без барыбыз да хәзер шулай кыскартып язабыз бит инде. «Комсомол сәламе белән...» дигән сүз бит ул!» – дип җавап бирде. Шушы инструкциягә таянып, мин бүтән кыскартуларның хәзер үзем генә серен ачарга өйрәндем. Мәсәлән, сиңа җибәргән хатның ахырына «Т. с. б-н» дип куялар икән, һич тә шикләнмичә әйтергә мөмкин, ул инде «туганлык сәламе белән» дигән сүз була икән. Билгеле, монда кыскартуларның һәммәсе турында да сүз бармый. Төрле оешмаларның, эш коралларының, фәнни хезмәтләрнең һәм башкаларның катлаулы исемнәрен кыскартып, җыңелләйтеп язу һәм телдән әйтү бик табигый бер хәл. Мәсәлән, комсомол, колхоз кебекләре күптән үк телгә керде. Заманында хәтта ТБУМ кебек сәеррәк яңгыраган исемне дә һич кыенсынмыйча яза һәм әйтә идек. Ләкин үзара мөнәсәбәттә куллана торган мондый гади сүзләрне дә шундый ук юл белән кыскарту һич тә килешми. Ул сөйләмнең матурлыгын боза, җөмләне гарипләндерә. Сөйләгәндә дә, укыганда да сүзләр, җөмләләр музыка кебек матур һәм ягымлы ишетелергә тиешле.Чыннан да, әгәр әйбәт фикер дөрес итеп язылса, җиренә җиткереп һәйбәт итеп укылса, ул күңелләргә тирәнрәк сеңеп кала.

Аерым кешеләрнең хатларында яки язмаларында тел бозулар ул әле бер хәл. Әмма газета-журналлар, радио һәм телевидение аша халык белән сөйләшү мең мәртәбә җаваплырак һәм хөрмәтлерәк. Кызганычка күрә, тел бозулар, аерым сүзләрне яки төшенчәләрне ялгыш кулланулар боларда да еш очрый. Мәсәлән, Алан дигән авыл исемен, нигәдер, ахырына йомшаклык билгесе куеп, Елань дип язгалыйлар һәм шулай әйтәләр дә. Арча районындагы Күлтәс авылын Көлтәс дип, ул авылдан чыккан борынгы галимне Күлтәси диясе урында Көлтәси дип язганнары бар. Шул ук Арча районында бик борынгы Курса авылы бар. Телевидениедә шул колхозның вәкиле чыгар алдыннан экранда: «Корса колхозы партоешма секретаре Кашшапов сөйли», – дигән язу пәйда булды. Бердән, «о» хәрефе белән язганда, бу исем Курса урынына татар телендә Корса дип укыла, димәк, бөтенләй башка мәгънә килеп чыга. Икенчедән, бу авыл исемен ялгыш язу һәм бозып әйтү бик гаҗәпләндерә.

Чөнки Курса – кайдадыр бик ераклардагы урман арасында яшеренеп калган нәни бер торак пункт кына түгел. Ул – Казанның борын төбендә генә яшәп ятучы бик мәшһүр авыл. Аның исеме матбугатта бик күптәннән кабатлана. Ул авылдан бик күпләргә билгеле булган, исеме дәреслекләрдә кабатлана торган мәгърифәтче Курсави чыккан. Балалар язучысы Госман Бакиров та шул авылда туып-үскән. Гомумән, авыл, елга, күл, урманнарга кушылган ялгызлык исемнәренә бик сак булу таләп ителә. Аларның язылышында яки әйтелешендә һич тә хата җибәрелмәскә тиешле, чөнки андый исемнәр мәңгелек паспорт урынына йөри. Ул исемнәр бик борынгы тарихи язмаларда, дәүләт күләмендә әһәмияте булган төрле рәсми документларда шулай теркәлгән. Дәүләт тарафыннан чыгарыла торган географик һәм башка карталарда да шул исем генә басыла. Алар буенча галимнәр халыкның, гомумән, шул тирәнең бик борынгы тарихын өйрәнәләр. Авыл исемнәрен хөкүмәтнең фәкать иң югары органнары гына үзгәртергә хаклы. Мәсәлән, Казан янындагы Собакино авылы исеме, Арча районында Коллар авылының исеме, инкыйлабтан соң, РСФСР хөкүмәтенең махсус карары белән генә үзгәртелде.

Газета-журналларда яисә радио-телевидениедә эшләүчеләрнең хәзерге әдәби һәм сөйләм теленең нечкәлекләренә игътибар итмәүләре нәтиҗәсендә дә күп кенә хаталар киткәли. Мәсәлән, «фәлән автомобиль сәгатькә фәләнчә тизлектә йөри», «агрегат минутка фәләнчә деталь бирә», «туку станогы минутка фәләнчә метр тукыма эшләп чыгара», дип язалар. Хәлбуки, болар берсе дә дөрес түгел. Әдәбиятта кабул ителгән кагыйдәләр буенча – сәгатенә, минутына, секундына дип язылырга һәм шулай укылырга тиешле. Яисә, мәсәлән, Гаффарның «Кешегә бәла килсә...» дигән мәкаләсендә: «Бәхетле яшәлгән шушы матур тормыш безнең куллар белән яуланган ич, шуның өчен егерме миллион кешебез шаһит киткән». – дигән сүзләр

Кайда гына яшәмәсен кеше, нинди генә телдә сөйләшмәсен, аның олы хөрмәт белән әйтә торган ике сүзе бар: туган ил, туган тел. Бу ике гыйбарә берсенә-берсе аваздаш булып ишетелә. «Туган тел» дисеңме, үзеннән-үзе туган ил күңелгә килә. Алар телгә алыну белән, күңелләрдә якынлык, кардәшлек хисе, туган иленә һәм халкына тирән мәхәббәт тойгысы уяна.

язылган. «Казан утлары» журналында да «шаһит» белән «шәһид»не бутаулар очраштыргалый. Бер генә хәрефне дөрес язмау һәм дөрес итеп әйтмәүдән нинди зур мәгънә хатасы килеп чыга! Чөнки «шаһит» ул «танык», «свидетель» дигән сүз, ә «шәһит» ул бөтенләй башка. Анысы хак эш өчен һәлак булучыларга карата әйтелә торган сүз. Газета-журналларда «к» белән «г», «х» белән «һ» хәрефләрен бутап язулар да очрый. Мәсәлән, «мәдхия»не «мәдһия» дип, «тәгъбир»не «тәкъбир» дип язу... «Фидакарь» сүзен «фидакар» дип бозып язгалыйлар. Классик әдәбиятны, гомумән, әдәби телне яхшы белүчеләрдә мондый хаталар, билгеле ки, ризасызлык тудырмыйча калмый. Халыкның мәдәни үсеше алга киткән бер заманда матбугат эшендә мондый саксызлык, гомумән, берничек тә килешми. «Белмәү гаеп түгел, белергә тырышмау гаеп», – диләр. Чыннан да, хата китмәсен өчен орфографик сүзлекне бер генә ачып карау да җитә бит. Сүземне тәмамлап шуны әйтер идем: халык матбугат сүзен ихтирам итә, радио һәм телевидение тапшыруларын, аларда һәммә сүзләрне дә дөрес язалар, дөрес укыйлар, дип, ихлас күңелдән ышанып тыңлый. Минемчә, зур ихтирамга лаеклы бик җитди ышаныч бу.

Татарстан радиосының «Тел күрке – сүз» тапшыруына нигезләп, басмага ***Рөстәм Акъегет*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2017

Яшә, авыл, мең яшә!

Азнакай муниципаль районы хакимияте башлыгы Марсель Шәйдуллин һәм тарих фәннәре докторы Рафаил Шәйдуллин

2017 елның 23-24 маенда Азнакай шәһәрендә «Көнчыгыш Татарстанда кеше һәм табигать. Юкка чыккан һәм тарихи авылларны өйрәнү, саклау һәм яңадан торгызу проблемалары» дигән темага Бөтенроссия (халыкара катнашу белән) фәнни-практик, тарихи-төбәкне өйрәнү конференциясе булып узды. Ул, Татарстан АССР төзелүгә 100 ел тулуга (1920-2020) әзерлек, ТРда Экология һәм иҗтимагый киңлекләр елы һәм РФдә Экология елы кысаларында Азнакай муниципаль районы хакимияте, Район Советы һәм Башкарма комитеты, Татарстан Республикасының фәнни һәм төбәкне өйрәнү җәмәгатьчелеге башлангычы белән оештырылып, Азнакай шәһәренә 30 ел һәм Азнакай төбәкне өйрәнү музеена 25 ел тулуга багышланган иде.

Конференциягә әзерлек һәм аны үткәрү барышында 89 доклад тәкъдим ителде. Пленар һәм 4 секция утырышында тарих һәм мәдәният, торак пунктларның үсеше проблемаларына, юкка чыккан һәм борынгы авылларны өйрәнү һәм яңалан торгызу мәсьәләләренә, музей-төбәкне өйрәнү эшенә, Татарстан һәм Идел-Урал төбәге уку йортларында фәннәрне укытуга багышланган 69 доклад һәм хәбәр тыңланды. Тулаем алганда, конференция эшендә, докладчылар һәм чакырылганнарны кертеп, 300ләп кеше катнашты. Алар арасында танылган фән докторлары һәм профессорлар Р.Ф.Гатауллин, Ф.Г.Сафин (Уфа), Р.В.Шәйдуллин, А.А.Борһанов, В.В.Хоменко, доцентлар В.Я.Әхмәтов (Уфа), М.Н.Солтанов (Бөгелмә), Т.А.Биктимерова, А.И.Бугарчев, Х.З.Баһаветдинова һ.б.лар бар иде.

***

Инде конференция кабул иткән резолюцияләрнең кайберләренә тукталып үтик.

Тарихи-мәдәни мирасны алга таба өйрәнү, саклау, пропагандалау һәм файдалану, Азнакай районындагы, Көнчыгыш Татарстан төбәгендәге һәм тулаем татар дөньясындагы борынгы (шул исәптән юкка чыккан) авылларның тарихын һәм мәдәниятен алга таба өйрәнү максатында, конференция материаллары җыентыгында басылган мәкаләләргә, докладлар һәм хәбәрләр буенча фикер алышуда кертелгән тәкъдимнәргә нигезләнеп, конференциядә катнашучылар карар кылды:

Шагыйрь Илдус Гыйләҗев (уңда)

Язучы, төбәкне өйрәнүче Мирсәй Гариф (уңда)

● *ТР районнары җитәкчеләренә галимнәргә һәм төбәкне өйрәнүчеләргә төбәкләр һәм торак пунктлар тарихын язу максатында археология, эпиграфия, архитектура һәм сәнәгать объектларын, архив һәм музей материалларын өйрәнү буенча комплекслы фәнни-тикшеренү эшләре үткәрүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.*

● *ТР районнары һәм РФ биләмәләрендәге татар дөньясы җитәкчеләренә юкка чыккан һәм юкка чыга баручы тарихи авылларның тарихын өйрәнү буенча актив фәнни һәм практик эшләр алып баруны, алга таба андый авылларның юкка чыгуына юл куймауны, социаль-икътисади, хуҗалык һәм туристлык кысаларында, биләмәләрен яңадан торгызуны тәкъдим итәргә.*

● *Билгелерәк тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрнең калдыкларын саклап калу максатында, районнар хакимиятеннән ТР Мәдәният министрлыгына алар тирәсендә саклау зоналары булдыру, саклау характерындагы чаралар күрүдә ярдәм итүне сорарга. ТР Мәдәният министрлыгыннан һәм районнар җитәкчелегеннән тарихи һәйкәлләр, каберлекләр һ.б.лар булган урыннарда сәнәгать, авыл хуҗалыгы һәм башка объектларны төзүгә юл куймау мәсьәләсен ныклы күзәтүдә тотуны сорарга.*

● *Район музейларына юкка чыккан, юкка чыга баручы һәм тарихи авыллар тарихы буенча һәм аларның кешеләре турында бөтен архив мәгълүматларын җыюны тәкъдим итәргә.*

● *Авылларны саклау һәм үстерү, аларның халкын бердәм итеп туплау максатында, тарихи халык җыеннары традициясен, халык мәдәнияте һәм үзидарәсенең бер өлеше буларак, яңадан торгызырга кирәк.*

● *Районнарның җитәкчеләренә һәм җирле халыкка юкка чыккан авыллар һәм ташландык урыннар зонасында экологик чаралар һәм эшләр үткәрүне тәкъдим итәргә. Бу экологик хәлне һәм табигый тирәлекне яхшырту мөмкинлеге бирәчәк.*

● *Милли авылларны һәм мәдәниятләрне саклау максатында, Татарстан һәм РФнең татар төбәкләре җитәкчеләренә һәм аларда яшәүчеләргә традицион милли һөнәрчелек һәм кәсепләрне, ат үрчетүне, умартачылыкны үстерүне, дару үләннәрен һәм башка файдалы үсемлекләрне җыю вә үстерүне һ.б.ларны тәкъдим итәргә.*

● *ТР ФА җитәкчелегеннән, галимнәрдән – тарихчылардан һәм төбәкне өйрәнүчеләрдән Көнчыгыш Татарстан һәм аңа чиктәш XVI-XIX гасырлар Көнбатыш Урал буе биләмәләрендә яшәгән татарларның, төбәкнең социаль катлаулары тарихын тирәнтен өйрәнүне активлаштыруны сорарга.*

Тулысынча beznenmiras.ru сайтыннан укырга мөмкин.

Тарих хәтере – мәңгелек

Гөлфия Мостафина,
Азнакай төбәкне өйрәнү музее фәнни хезмәткәре

Шәһәрләр һәм авыллар, торак пунктлар, халыкның, кешелек тормышының тарихы киләчәк буын хәтерендә калсын өчен, аны өйрәнү, саклау сорала. Музейлар әлеге тарихны барлый һәм саклый. Музей – үткәнне яктыртучы.

Азнакай төбәге – бай тарихлы як. Аның үткәне, бүгенгесе бар. Әнә шул үткәнне өйрәнеп, киләчәк буыннарга саклап калу максатыннан, Азнакайда музей булдыру фикере туды. 1990 нчы елларда Мисбах Муса улы Мәсәлимов, Азат Гарәфетдин улы Галимовлардан торган инициатив төркем оешты. Беренче эш итеп, алар «Маяк» газетасы аша район халкына музей фонды өчен экспонатлар җыюда ярдәм итүләрен сорап мөрәҗәгать белән чыктылар. 1992 елда оешып килүче музейның директоры итеп Гөлсем Хисамиева билгеләнде. 1999 елда музей тулы куәтенә эшли башлады.

Музейның яңа бинасы исә шәһәрнең иң матур урынында, яңа микрорайонда салынды. Музейны тантаналы төстә ачу 2016 елның 13 августында Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов, «Татнефть» ПАҖ генераль директоры Н.У.Мәганов катнашында булды.

Музей фондын XIX-XX гасырларга

кагылышлы 7 меңнән артык экспонат тәшкил итә. Алар биш төрле исемдәге экспозицияләргә урнаштырылды һәм фонд саклагычына куелды.

«Археология, төбәк табигате» дип исемләнгән беренче бүлектә районга беренче килеп утыручылар турында мәгълүматлар, археологик табылдыклар, файдалы казылмалар, төбәк табигате белән танышырга мөмкин. Районның тарихи, табигый мирасы саналган Чатыр тавы турында да шактый гына мәгълүмат алырга була. Әлеге тау Татарстанда иң биек ноктталардан санала, диңгез өслегеннән алганда 321,7 метр биеклектә урнашкан. Ул күп кенә сөзәклекләрдән тора, бакыр рудасы табылган ике мәгарәсе бар. Тауда байбаклар яши. ТАССР Министрлар Советы карары белән 1972 елда Чатыр тау табигать һәйкәле итеп расланды.

«Этнография һәм һөнәрчелек» дип аталган алдагы экспозиция безнең як халкының күпмилләтле булуы, һөнәрчелек белән шөгыльләнүе турында сөйли. Чыннан да, үзләренең хуҗалык ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, төбәктә яшәүчеләр агач эшкәртү, тимердән эш кораллары ясау белән шөгыльләнгәннәр. Һәр авылның үз балта остасы, тәгәрмәч ясаучылары булган. Агач кайрысы эшкәртү дә киң таралган. Авылларда су тегермәннәре эшләп килгән. Сәүдә итү төбәктә киң колач белән барган. Биредә төрле милләт вәкилләре яши. Татарлар, руслар һәм башка милләт вәкилләре үзара дус-тату көн итә. Стендта хатын-кызларның милли киемнәре куелу шуны дәлилли.

Азнакай төбәге – мәгърифәтле як. Беренче мәдрәсәләр Азнакай һәм Тымытык авылларында була.

Өченче экспозиция «1930-1960 елларда район тарихы һәм район Бөек Ватан сугышы елларында» дип атала. 1928 елларда районда хуҗалыкларны тоташ күмәкләштерү башланып, 1934 елларга тулысынча күмәкләштерелеп бетә. Фотосурәтләр, документлар шул хакта сөйли.

1941 елгы Бөек Ватан сугышы

илебезгә күп югалтулар китергән. Азнакай районыннан гына да Бөек Ватан сугышына 15 меңнән артык ир-егет һәм хатын-кыз алына. Шулардан 8 меңнән артыгы бөтенләй әйләнеп кайтмый. Хәбәрсез югалучылар саны да күп. Корал тотардай ир-егетләр сугышка китсә, тылда калган бөтен авыр эш хатын-кызлар, өлкәннәр, балалар җилкәсенә төшә. Стендларга, витриналарга урнаштырылган фотосурәтләр, документлар, хатлар, хәрби киемнәр, сугыш булган яклардан кайткан кораллар якташларыбызның күргәннәрен үзенә сеңдергән.

Районда барлыгы 13 герой исәпләнә. Шулардан дүртесе – Советлар Союзы Герое, сигезе – Социалистик Хезмәт Герое, бер – Россия Герое. Советлар Союзы Геройлары Ә.И.Вәлиев, П.З.Манаков, И.М.Никитин, Ф.Х.Әһлетдинов, Социалистик Хезмәт Геройларыннан Г.М.Баһманов, Ә.Г.Гарипов, В.Х.Хаҗиәхмәтовлар Бөек Ватан сугышында катнашкан. Тылда эшләгән фидакарьләрнең фоторәсемнәре, алар турында язмалар бар.

«Сугыштан соңгы елларда район тарихы. Танылган якташлар» исемле чираттагы бүлектә азнакайлыларның сугыштан соңгы елларда хезмәттә ирешелгән

уңышлары һәм иҗади эшчәнлекләре белән танышырга була. Шулай ук медицина, мәгариф, мәдәният тарихы киң яктыртыла.

Районның медицина тарихы үзенчәлекле. Төбәгебездә Сәпәй авылында тирә-юньгә танылган земский больница булуы билгеле. 1909 елда хастаханәнең беренче төзелеш эшләре башлана. Бөтендөнья сугышы башлану сәбәпле, төзелеш туктатыла һәм 1933-1934 нче елларда гына эш тәмамлана. Сәпәй хастаханәсендә 34 ел табиб-акушер булып эшләгән Г.Х.Хәсәншинага фидакарь хезмәте өчен Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә.

Азнакай районының шактый гына авылларында, шул исәптән, Азнакай, Тымытык авылларында да инкыйлабка кадәр 7 яшьтән 15 яшькәчә балалар мәдрәсәдә белем ала. Күп кенә авылларда башлангыч мәктәпләр ачыла. 1930 нчы елларда мәҗбүри җидееллык белем кертелә. Укыту Бөек Ватан сугышы елларында да тукталмый. Сугышка китеп, җиңү белән кайткан, мәктәпләрдә укытучылык эшен дәвам иткән якташларыбыз да хөрмәткә лаек. Алар турында фоторәсемнәр, истәлек язулары сөйли. Бүгенге көндә дә районда мәгарифнең абруе тирә-якка билгеле.

1964 елнын 10 августында Азнакайга КПСС Үзәк комитеты секретаре, Министрлар Советы рәисе Никита Хрущев килә. Районның уңдырышлы кукуруз басуы белән кызыксынганнан сон, Чатыр тау итәгенә урнашкан урманда оештырылган бәйрәм табынында катнаша. Әлеге урман, бүгенге көндә дә аның исеме белән бәйләп, «Хрущев урманы» дип йөртелә. Бу хакта фотосурәтләр, газета битләрендәге язмалар сөйли.

Узган 2016 елда районыбыз оешуның 85 еллыгын, районыбызның Актүбә бистәсенә 60 ел тулуны, быелның март аенда Азнакайның шәһәр статусы алуына 30 ел булуны зурлап билгеләп үттек.

Музей комплексы шәһәребез, районыбыз халкы һәм читтән килгән кунаклар өчен истәлекле урыннарның берсе санала. «Татарстанда музейлар язы», «Музейда көн һәм төн», «Музейда Җиңү көннәре», «Белем көне», «Сәнгать төне» акцияләре, «Өлкән яшьтәге кешеләр һәм физик мөмкинлекләре чикләләр декадасы» үтә. Шулай ук балалар өчен яңа ел бәйрәмнәре, туган көннәр, туй фотосессияләре, кул эшләреннән мастер-класслар үткәрергә мөмкин. Шәһәр һәм район авыллары буенча, төбәкнең тарихи һәм табигать һәйкәле булган Чатыр тауга экскурсияләр тәкъдим итә. Фондта булган экспонатлар, тарихи документлар белән танышу мөмкинлеге дә бар.

Музей фондында заманча автоматлаштырылган КАМИС системасы кертелде. Мәдәни-агарту эшчәнлеге белән таныштыручы электрон киоск булдырылды.

«Бөек Ватан сугышы виртуаль музее», «Берләштерелгән каталог» порталында эш алып барыла.

Бүгенге көндә Азнакай төбәкне өйрәнү музее районның тарихи-мәдәни мирасын саклаучы булып тора. Ул һәр елны үз эшен, хезмәтен яктырткан газета чыгара, халыкара фәнни-практик конференцияләр һәм семинарлар үткәрә. ■

«Архив эшен яңа югарылыкка күтәрергә кирәк»

(Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе ***Ирада Хафизҗан*** *кызы* ***Әюпова*** *белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон әңгәмәсе)*

– Ирада Хафизҗановна, архивта татар халкы тарихына бәйле материалларны туплау эше ничек куелган?

– Россия буенча барлык архивларны барлап, безгә архив эшен яңа югарылыкка күтәрергә кирәк. Мәсәлән, Пермь краенда архивлар бай, документларны саклау шартлары да яхшы, анда татар кулъязма чыганаклары да бар, әмма алар аның нәрсә икәнен белми, тасвирлау турында сүз дә бара алмый, белгечләр юк.

Күптән түгел Хабаровск шәһәреннән документлар кайтарттык. Ул – Манчжуриядәге татар мөһаҗирләренә караган чыганаклар. Заманында анда татарларның иҗтимагый оешмасы булган.

Хәзерге вакытта Президент ярдәме белән дә шундый элемтәләрне урнаштырып, татарга бәйле документларны бер урында тупларга уйлыйбыз. Алар цифрлаштырылган гына булса да, безнең өчен зур мәгълүмат ресурсы булып торачак.

Документлар эштә файдаланырга, фәнни әйләнештә булырга тиеш. Әгәр дә алар билгесез икән, мәгълүмат фрагмент характерында гына була. Һәрбер тикшеренүче үз темасы буенча материалны кайда таба алуын белергә тиеш.

– Казанда архивчы белгечләр җитәрлекме?

– Бездә эшләүчеләр архивчы да, тарихчы да һәм телне дә әйбәт белүче

булырга тиеш. Дөрес, Казанда бу юнәлештә эш берникадәр җайга салынган. Бездә гарәп язуын белүче, иске татар телен аңлаучы белгечләр бар. Ә башка төбәкләрдә исә эш катлаулырак. Мәсәлән, гарәп язулы чыганаклар алар өчен аңлашылмый торган дөнья. Төбәкара алмашуның да әһәмияте шунда: алар безгә мәгълүмат бирә, ә без белгеч хезмәтен тәкъдим итәбез.

Кайбер чыганаклар белән эш итү безнең көчтән дә килми. Әйтик, архивыбызда тибет, монгол, калмык телләрендәге кулъязмалар бар, ә алар белән эшләүче белгечләр Казанда әлегә юк.

– Архивка шәҗәрә төзер өчен, эш стажы, эш хакы турында белешмә алыр өчен мөрәҗәгать итәләрме?

– Әлбәттә. Бу сорау буенча дәүләт хезмәте порталында аерым алгоритм булачак. Дөрес, интернетта эшли белмәгән кеше өчен архивта бу юнәлештә эшләүче белгечләр бар. Архивтан белешмә алу өчен, гариза тапшырырга кирәк. Үзең белән паспорт һәм хезмәт кенәгәсенең күчерелмәсе булу мәҗбүри.

2011 елны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (ул вакытта – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе) белән Россия пенсия фондының Татарстан бүлеге арасында электрон рәвештә мәгълүмат алмашу турында килешү төзелде. Аның нигезендә Пенсия фонды архивтан кирәкле документларны сората. Пенсиягә чыгар алдыннан кешегә теге яки бу документ, йә эшләгән урыны турында мәгълүмат җитеп бетми икән, аңа моның өчен дәүләт архивына барып йөрмәсә дә була. Барысын да Пенсия фонды хезмәткәрләре дә сората ала, бу эшне күпкә тизләтә, халык өчен дә уңайлы.

Ә нәсел шәҗәрәсе буенча мәгълүмат бирү – түләүле хезмәт, чөнки күп очракта кеше ул эш белән үзе шөгыльләнә алмый. Халыкың 99 проценты иске татар графикасында язылган мәгълүматны укый белми.

– Мәгълүматны бозып бирү очраклары бармы?

– Ни кызганыч, бар. Бездән дөрес мәгълүмат алып, пенсия хисаплау бүлегенә документны үзгәртеп тәкъдим итүче намуссыз затлар да очрый. Ә бит архив белешмәсе – бик җитди документ.

Шуны да әйтәсем килә: хәзерге вакытта үзенең нәсел-нәсәбен белергә теләүчеләр бик күп. Бу – күңелле күренеш, ләкин совет заманына кадәрге генеалогик чыганаклар (метрика кенәгәләре, ревизия материаллары) иске язу белән язылган. Ул язуны тану өчен, беркадәр әзерлек зарур. Бу бигрәк тә гарәп имласында язылган татар метрика дәфтәрләренә карый. Кызыксынучылар, архивка килеп, ул документлар белән үзләре дә таныша ала, ләкин күпчелек очракта кешеләр әзерлекле белгечләргә мөрәҗәгать итә. Хәзерге вакытта нәсел агачы төзү эше белән шөгыльләнүче аерым шәхесләр дә, фирмалар да бар. Араларында эшләрен намуслы башкаручылар җитәрлек, әмма акча алып сыйфатсыз эшләүчеләре дә очрый. Шуңа күрә шәҗәрә төзү, башка темаларга караган мәсьәләләр белән турыдан-туры архивка мөрәҗәгать итүчеләр генә алынган мәгълүматның хакыйкый булуына ышана ала.

– Әгәр дә документлар читтә, мәсәлән, Уфадагы архив белән бәйле икән, бу очракта мәгълүматны сез соратып алырга тиешме, әллә алар үзләреме?

– Бу мөрәҗәгатьнең эчтәлегеннән тора. Әгәр ул социаль-хокукый, ягъни кеше хокукларын тәэмин итү белән бәйле мөрәҗәгатьләр булса (эш стажы, эш хакы, бүләкләүләр, репрессияләр һ.б.), бу очракта без гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне чит төбәкләрдәге тиешле архивларга үзебез юлларга тырышабыз. Ә инде кешегә йә оешмага Татарстан Дәүләт архивында сакланмый торган документлар нигезендә түләүле нигездә бирелә торган мәгълүмат йә документ кирәк икән (нәсел-нәсәпне ачы-

клау, җир бүлеп бирү, мал-мөлкәт белән бәйле һ.б.), ул вакытта алар тиешле архивка үзләре мөрәҗәгать итәргә тиеш. Бу очракта без мәгълүматның кайда булуы турында гына хәбәр итәбез.

– Татарстан архивында кул тимәгән нәрсәләр бармы?

– Фәнни әйләнешкә кертелмәгән чыганаклар, әлбәттә, күп. Фондларда нинди материал бар икәнлеге турында архивчылар яхшы белә. Аның бәясен, тарихи, әдәби процесстагы урынын билгеләү – башка мәсьәлә.

– Редакцияләрнең архивы юкка чыга бара. Без аны хәзер булдыра алган кадәр үзебезгә ташыйбыз...

– Безнең архивта тасвирланмаган фотолар шактый күп. Дөресрәге, без анда кем төшерелгәнен дә белмибез... Сезнең журнал битләрендә яки сайтында боларны ачыклау максатыннан уртак эзләнү эшен дә башлап җибәрә алыр идек...

– 1986 елны Нәкый Исәнбәт архивын ала алмаганнар иде, аны Йолдыз апа Исәнбәт бирмәде. Хәзер бу мәсьәлә ничек тора?

– Хәзер шәхси архивлар белән эшли башладык.

– Рәис Даутов, Хәсән Туфан архивлары югалу куркынычы алдында...

– Кызганыч, кеше архивларны зур авырлык белән генә бирә, нәтиҗәдә, тарихыбызның бер өлеше күләгәдә кала. Архивка эләккән документлар юкка чыгарылмый, аның саклану вакыты да чикләнмәгән.

– Язучыларга кагылышлы материаллар белән балконым, фатирым тулган. Мин аны хәзер сезгә бирәм икән, кирәк булса, кире барып алырга туры килүе ихтимал...

– Электрон коллекция дә ясарга була. Әгәр дә кеше үзендә булган шәхси материалларны архивка саклауга бирә икән, ул аннан файдалана ала. Сез, федераль канун нигезендә, бу чыганаклар белән бер гасыр яки илле яисә берничә ел дәвамында фәкать мин генә файдалана алам, дип, шул турыда килешү документында белдерә аласыз. Ул «Ләбиб Лерон» яки башка исемдәге фонд буларак саклана ала. Документларны тапшырганда аннан файдалану тәртибен Сез үзегез билгелисез. Бөтен таләпләрегезне дә күрсәтергә мөмкин.

– Үземдә сакланган материалларны тапшырсам, башкаларны да пропагандалый алыр идем, чөнки күп шәхесләребезнең архивы югала бара. Беркөнне Фатих Хөснинең өенә бардым. Кызы инсульт белән чирләп ята. Шәхси документлар белән танышканда аудиоязма килеп чыкты. Кызы: «Бирмим мин аны», – ди... Мин әйтәм: «Дөрес эшлисең!» Шуннан килене белән радиога барып, күчермәсен алырга булдык. Мондый документлар сезнең өчен дә кыйммәтле булыр иде...

– Кабатлап әйтәм: архивка бирелгән әйбер югалмый... Ләкин соңгы вакытта гы документларга килгәндә, аларны саклап калу мәсьәләсе бар. 1990 нчы еллардан башлап принтерда чыгарылган материаллар да киләчәккә сакланмый, чөнки алар, хәзерге касса чеклары кебек, тузан бөртегеннән җыелган. Касса чегындагы кара төс берничә айдан юкка чыккан шикелле, лазер принтерыннан чыккан документларның да каралары чагыштырмача тиз арада бетә башлый. Бу елларда басылган документларга караганда, XIX гасырдагылары яхшырак сакланган. Аудио һәм видеоязмалар да бик тиз туза, аларны мөмкин кадәр тизрәк цифрлаштырырга кирәк. Гомумән, шәхси архивны саклау аерым проблема. Дөрес, архивлар өйдә дә саклансын, әмма аның өчен хуҗа тарафыннан тиешле шартлар тудыру мөһим. ■

ЯДКӘРЛӘРГӘ – БЕР ГАСЫР

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондыннан

1917 елның 7 июле

КРЕСТЬЯН ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ БӨТЕНРОССИЯ СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ КРЕСТЬЯН ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАНТОН ҺӘМ ӨЯЗ СОВЕТЛАРЫНА ХАТЫ

Һәр хуҗалыкта һәм производствода кулланылмыйча яткан лом һәм калдыклар хәлендәге иске металлны авыл хуҗалыгы ихтыяҗларында куллану өчен, Җир эшләре министрлыгы, 19 июльдә (сугышның өч еллыгында) моның өчен «Тимер көне» билгеләп, халыктан бу металлны иректә җыюны максатка ярашлы дип тапты.

Крестьян депутатларының Бөтенроссия Советы Башкарма комитеты, Җир эшләре министрлыгының бу ниятенә теләктәшлек күрсәтеп, Сездән җыюны оештыруга һәм уңышлы башкарып чыгуга ярдәм итүегезне сорый.

Рәис имза
Сәркатип имза
ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 319б.

1917 елның 8 июле

ВАКЫТЛЫ ХӨКҮМӘТНЕҢ ЧИСТАЙ ӨЯЗ КОМИССАРЫНЫҢ КРЕСТЬЯН ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ЧИСТАЙ СОВЕТЫНА ХАТЫ

Бу көннәрдә Петроградта булган вакыйгалар уңаеннан, бөтен җәмәгать оешмаларына әлеге вакыйгаларга үз мөнәсәбәтләрен ачыклау һәм шәһәрдә дә, өяздә дә тынычлык һәм тәртип саклау чаралары планын эшләү өчен җыелырга кирәк. Оешмалардан Чистай шәһәр идарәсендә июль аеның 9ында – якшәмбе көн көндезге сәгать 3тә мөмкин кадәр тулы составта җыелуны сорыйм.

Өяз комиссарының ярдәмчесе имза
ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 322б.

1917 елның 13 июле

ВАКЫТЛЫ ХӨКҮМӘТНЕҢ КАЗАН ГУБЕРНА КОМИССАРЫНЫҢ МАМАДЫШ ӨЯЗ КОМИССАРЫНА ХАТЫ

Вакытлы хөкүмәтнең карары һәм Җир эшләре министрлыгының күрсәтмәсе буенча, Казан губернасында хәзерге вакытта авыл хуҗалыгы һәм җир исәбе алу уздырыла.

Документлар урыс теленнән тәрҗемә ителеп бирелә.

Безнең мирас №7 июль 2017

Исәпкә алуның төп бурычы булып гомумдәүләт азык-төлек планын төзү һәм аграр реформа үткәрү тора.

Зур дәүләт әһәмиятенә ия булган әлеге гаять мөһим мәсьәләне дөрес хәл итү өчен, чынбарлыкның тулы чагылышы булган төгәл мәгълүматлар бирүне исәпкә алу кирәк.

Халык өчен гаять мөһим булган азык-төлек һәм җир мәсьәләләрен хәл итәчәк Учредительное собраниенең сентябь аенда җыелуы исәпкә алуның әһәмиятен һәм аны ашыгыч үткәрергә кирәклеген тагын да арттыра.

Әйтелгәннәрдән чыгып һәм урыннарда халык тарафыннан кирәкле мәгълүматны бирүдә каршылыклар туу һәм шушы нигездә аңлашылмаучылыклар килеп чыгу мөмкинлеген игътибарга алып, Сездән исәпкә алуда катнашучы барлык затларга мөмкин булган бөтен ярдәмне күрсәтүне һәм Җәмәгать куркынычсызлыгының җирле комитетларына, комиссарларга, исәпкә алуда өзеклекләр һәм тоткарлыклар булдырмас өчен, хәзер үк тиешле күрсәтмәләр бирүне сорыйм.

Төп нөсхәсе белән дөрес:
Өяз комиссары имза
ТР ҮДА ТСД, ф.5599, тас.1, э.16, 16б.Күчермә.


Вх. № 514.
19 3/VII 17 г.

Чистопольскій Мусульманскій Комитетъ.
چستاى مسلمانلارينك
كاميتيتى
№ 20/377

Іюля 17 дня, 1917 г.

Въ Исполнительный Комитетъ Чистопольскаго Уѣзднаго Комитета Общественной Безопасности

338

Исполнительный Комитетъ Чистопольскаго Уѣзднаго Мусульманскаго Совѣта 17-го сего іюля согласно постановленію Чистопольскаго Уѣзднаго Комитета Общественной Безопасности обсудивъ вопросъ о рекомендаціи эмиссаровъ отъ мусульманъ постановилъ: рекомендовать въ эмиссары для пропаганды въ мусульманскихъ селеніяхъ слѣдующихъ лицъ: учителей-мугаллимовъ Ибрагима Багаутдиновича Камалютдинова и Махмуда Нажиповича Амирханова, которые могутъ выѣхать въ уѣздъ съ двадцатаго сего іюля.

Председатель Исполн. комит.

Секретарь:

Чистопольскій Мусульманскій Комитетъ

1917 елның 17 июле

ЧИСТАЙ ӨЯЗ МӨСЕЛМАН СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ РӘИСЕНЕҢ ЧИСТАЙ ӨЯЗ ҖӘМӘГАТЬ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ КОМИТЕТЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНА ХАТЫ

Чистай өяз мөселман советы башкарма комитеты июльнең 17сендә, Чистай өяз җәмәгать куркынычсызлыгы комитеты карарына ярашлы рәвештә, мөселманнардан эмиссарлар тәкъдим итү мәсьәләсен карап, карар чыгарды: мөселман авылларында пропаганда алып бару өчен эмиссарлар итеп шушы затларны тәкъдим итәргә: укытучы-мөгаллимнәр Ибраһим Баһаветдин улы Камалетдинов һәм Мәхмүт Нәҗип улы Әмирханов. Алар өязгә июль аеның 20сеннән чыга алачак.

Башкарма комитет рәисе имза
Сәркатип имза

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 338Б.

*Документларны басмага ТР Дәүләт архивы секторы мөдире **Римма Садыйкова** әзерләде.* ■

E-mail: prm.archive@tatar.ru
www.arhiv.tatarstan.ru

Кала тау

Бу төбәктә (Әтнә районы) туып үскән Әсгат Сәфәров 2000 нче еллар башында тауда гыйбадәт йорты төзетә. Аны 2015 елда генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин җитәкчелегендәге «ТАТТЕЛЕКОМ» ААҖ элемтәчеләре яңарта.

Җирле халык әлеге урынны «Ханнар зираты» дип йөртә һәм аны X гасырдагы Идел Болгарстаны идарәчеләре белән бәйләп карый. Казу эшләре вакытында ачыкланган материаллардан чыгып, галимнәр шәһәрлек әле IV-VII гасырларда ук җирле мәҗүси халык тарафыннан саклану урыны буларак файдаланылган, дип фикер йөртә. Соңрак, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында ул илнең төньягындагы татар дәүләт форпостларының берсе булып торган. Бу турыда Шиһабетдин Мәрҗани язып калдырган.

Шәһәрлектән 400 метр читтәрәк «Изгеләр зираты» һәм «Изге чишмә» бар. Чишмәгә 159 басмалы баскычтан төшәргә мөмкин. ■

ХӘТЕРНЕ ЯҢАРТУ – ОЯТ ТҮГЕЛ

Моннан 100 ел элек «Кояш» газетасында мөселманнарның фронттан качуы турында кечкенә хәбәр басылган булган. «Безнең мирас» журналы үзенең бишенче санында шул ук хәбәрне кабат бастыра. Тик бу хәбәр кайбер укучыларда ризасызлык тудыра: ничек инде мөселманнар фронттан кача ала, алар бит Россиянең тугрылыклы солдатлары, соңгы сулышына кадәр ватанын саклаган, мондый хәл алар арасында булырга мөмкин түгел!

Бер караганда, журналның оппоненты дөрес фикер йөртә шикелле. Чыннан да, Русия татар-мөселманнары тарихка батыр-кыю сугышчы буларак кереп калган. Бу хакта данлыклы хәрбиләрнең уңай бәяләмәләре сакланан. Тик тарихи вазгыятьне искә алмаган вакытта гына. Ә газетада басылган кыска хәбәр тарихта булган чын вакыйгага кайтаваз булып тора. Исегезгә төшереп китәбез, бу бит Беренче Бөтендөнья сугышы барган вакыт. Русия солдатлары 3 ел инде – окопларда. Шулар арасында бик күп мөселманнар да Алман, Австро-Венгриягә каршы сугыш алып бара. Күп кенә бәрелешләрдә җиңелүдән, кан коюдан, мәгънәсез сугышудан, корал, азык-телек җитмәүдән солдатлар инде гарык булган. Ризасызлыктан, гомуми рухи төшенкелектән котылу теләге белән, Февраль революциясе нәтиҗәсендә тәхеттән патша бәреп төшерелгән, яңа Вакытлы хакимият һәм Советлар үз властен урнаштыра башлаган бик катлаулы, билгесезлек хөкем сөргән вакытлар бу. Нәкъ менә шул билгесезлектән файдаланып, күп еллар фронтта кан койган солдатлар, командирлардан рөхсәт сорамыйча, үз теләкләре белән фронттан туган якларына корал белән кайтып китә башлый. Әлбәттә, фронттагы солдат массасының аерылгысыз бер өлеше булган мөселманнар да бу хәрәкәттән читтә калмаганнар. Фронттагы мондый хәлләр турында хәбәрләр Казанга да килеп җиткән һәм ул газетада чагылыш тапкан.

Биредә беркемдә дә гаеп юк, бу катлаулы, чын тормышның тик бер чагылышы гына. Әлеге хәбәр белән килешсәң дә, килешмәсәң дә, аны үзгәртеп булмый. Ул булган һәм без аны онытырга тиеш түгелбез. Бу вазгыятькә караш һәр кешенең үзеннән генә тора. Ә 100 елдан соң, әлеге вакыйга турында газета материалын кабатлап, мәртәбәле журналыбыз дөрес эшли: тарихи хәтерне яңарта. Без моның өчен журналга рәхмәтле булырга тиешбез.

Фәйзелхак Ислаев,
профессор, тарих фәннәре докторы ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның июль ае

Сәхифәне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Кадер көнендә кибетләр ябыла

Дүшәмбе көн, 3 июль 27 рамазан кадер көне бәйрәм булу сәбәпле, һәммә мөселман кибетләре ябык булачак.

Кояш. – 1917. – №1136. – 2 июль.

Бәхет сынау уены

Якшәмбе көн, 9 июльдә Черек күл бакчасында Казандагы (мөселман) хәрби комитет һәм (Бөтенрусия мөселман) укытучылары мәркәз бюросы файдасына бәхет сынаш уены булачак. Иң зур отышлар: иярле ат, ике сыер, самоварлар, ир һәм хатыннар өчен алтын-көмеш сәгатьләр, велосипед, тегү машинасы, граммофон, чайный һәм кофейный приборлар вә башка нәрсәләр. Билет бәһасе – 30 тиен. Уен вакытында бакчада духовой оркестр уйнап торачак. Уен нәкъ көндезге сәгать 11дә башлана. Мөдир – Габбас Сыябаков.

Шәкертләр сәяхәте

Бишбалтада Шәрәфетдин Абызов йортындагы кызлар мәктәбенең шәкертләре елдагыча сәяхәткә чыгып, Чистай шәһәренә барып кайттылар. Бу эшкә төрлечә ярдәмдә булган адәмнәргә, аеруча Чистай шәһәренең икенче мәхәллә мәдрәсәсенең идарәсенә тәшәккер итәбез. Нәҗип Абызов.

Кояш. – 1917. – №1137. – 7 июль.

Яңа имам

Яшь голәмәдән мәдрәсәи «Мәрҗания» мөдәррисләреннән Габделхәмид бине Борһан бине Шиһабетдин әл-Мәрҗани Казанның беренче мәхәлләсе – «Мәрҗани» мәхәлләсенә имамлыкка интихаб ителде [тәгаенләнде].

Милли мәктәп

Ягодная Слободада торучы мөселманнар, үзләрендә өч йөзгә якын уку яшендәге балаларга бер мәктәпләре булмавын искә алып, киләчәк уку елында ук мөселман балалары өчен ир вә кызларга махсус милли мәктәпләр ачарга тиешлеген белгезеп, шәһәр управасына гариза биргәннәр.

Мөселман әфитсәрләренә мөрәҗәгать

Бөтенрусия мөселман гаскәрләре шурасы Казан мөселман хәрби комитетына Русия армиясендә хезмәттә булган бөтен мөселман әфитсәрләренең санын алып, шуларның эспискәләрен төзү эшен тапшырды. Мөселман әфитсәрләренең санын, аларның кайда вә нинди хезмәттә икәнлеген белү киләчәк көннәребез өчен гаять мөһимдер.

Даталар иске стиль белән бирелә.

Икмәк

Азык җитештерү комитеты Казанда торучы халык өчен 15 июльдән 1 августка кадәр кара икмәкнең фәкать карточка белән генә биреләчәген игълан итә. Балаларга ак күмәч алу өчен бирелә торган карточка куе сары төстә булачак. Икмәкне шәһәр кибет-пекарня вә хосусый кибетләрдән алырга мөмкин. Бу кибетләргә һәм харчевняларга сатар өчен бирелә торган икмәкләр Воскресенски урамда, азык җитештерү комитеты бинасында бирелә.

Хисап вә тәшәккер

Казанда мәдрәсәи «Касыймия» мөгаллимнәре белән мөгаллимәләре берләшеп «Мөгаллимәләр курсы» ачып, бу көннәрдә шуның тукталу мәрәсиме булды. Курсның программасында күрсәтелгән фәннәр тәмам ителделәр. Шуның өстенә 8-9 кадәр балалы тәҗрибә мәктәбе ачылып, ибтидаи мәктәпләрдә укыла торган фәннәрнең, бигрәк тә ана теленең тәгълим [укыту] рәвешләре күрсәтелде. Җомга көннәрдә, җомгадан соң түбәндә зикер ителәчәк әфәнделәр тарафыннан төрле лекцияләр укылды. Госман Данбулатов «Авыл көнкүреше хакында», Тәккый Бәдигъ «Иске хөкүмәтнең ни өчен җимерелүе», Әхмәдҗан хәзрәт Мостафый «Хәрефләрнең тарихы», Нәҗип Хәлфин «Учредительное собрание һәм аңа сайлау» хакында 2 мәртәбә, Һашим Вәлиев «Умартачылык» хакында 4 мәртәбә лекция укып, Зеленый Долга алып барып, кәрәз ясату, бал аерту хакында тәҗрибәләр ясады. Җомга көннәрдә җомгадан алда шәһәрнең төрле урыннарында экскурсияләр ясалды: махсус юлбашчылар идарәсендә Аитова мәктәбе, сукырлар мәктәбе, музәханә, ботанический садка барып, һәр урында мәгълүмат алдылар.

Кояш. – 1917. – №1138. – 13 июль.

Социалистлар өчен иганә

Бу көн һәм иртәгә Мөселман социалистлар комитеты файдасына кружка белән иганә җыю көне. Җыеп йөрергә теләүчеләр көндез сәгать бергә кадәр язылa алалар.

Кояш. – 1917. – №1142. – 23 июль.

Гомуми хәрби съезд

Ильяс Алкин тарафыннан сайлау турында доклад укылып, түбәндәге карарлар кабул ителә: 1) Учредительное собраниегә сайлауда бөтенрусиядәге мөселман гаскәрләр катнаша; 2) мөселман гаскәрләре үзләрен һәм үзләренең кандидатларын үткәзер өчен, фәкать мөселман социалистлары группасына тавыш бирергә һәм алар белән блок ясарга, мөселман социалистлары булмаган җирдә нинди генә булса да социалистический группа белән кулга кул тотышып барырга тиешлеләр. Тәнәфестән соң Җиһангир Алкин тарафыннан хатын-кыз мәсьәләсе хакында доклад укылып, «Бөтенрусиядәге мөслимәләргә политический, кирәк гражданский эшләрдә гомуми хөррият һәм тигезлек бирелер», – дигән карар бер авыздан кабул ителеп үтә. Ахырында Кырым мөфтисе һәм татар батальоны гаскәре башлыгы Шабановларның хәбес [тотык] ителүе, 6 нчы армиядәге мөселман хәрби комитетларын таратырга бирелгән хәбәрләр хакындагы телеграммалар укылып, карарлар берләшкән мәҗлескә калдырыла.

Кояш. – 1917. – №1144– 27 июль. ■

ИЮНЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 5 июньдә «Безнең мирас» журналы редакциясе хезмәткәрләре Л.Лерон белән Р.Сәгъди Лаеш, Балык Бистәсе һәм Питрәч районнарында булып, җирле хакимият җитәкчеләре белән очрашты.

● 7 июньдә Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин журналистлар өчен ифтар ашы уткәрде. Әлеге ифтарда республикада чыгучы дәүләт һәм шәхси матбугат чараларыннан 50дән артык журналист катнашты. Кичәнең кунаклары арасында мөфтинең мөхтәсибләр белән эшләү буенча урынбасары Мансур хәзрәт Җәләлетдин, Татарстан Президентының матбугат үзәге җитәкчесе урынбасары Ләззәт Хәйдәров, «Эфир» телеканалының директорлар советы рәисенең урынбасары Самвел Оганисян, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон да бар иде.

● 7 июньдә, Татарстан Республикасында «Матди булмаган мәдәни мирас турында» дигән канун кабул ителүе уңаеннан, Татарстан Дәүләт Советында матбугат очрашуы булды. Әлеге чарада ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Гүзәл Шәрипова, Татарстанның традицион мәдәниятен саклау үзәге җитәкчесе Фәнзилә Җәүһәрова матди булмаган мәдәни мирас кануның мөһимлеге турында сөйләде.

● 7-14 июньдә Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты директоры Рафаэль Хәкимов җитәкчелегендәге галимнәр төркеме Польшаның Гданьск һәм Варшава, Алманиянең Мюнхен шәһәрендәге хәрби зиратларда җирләнгән татар каберлекләрен барлады. Шул эзләнүләргә нигезләнеп, Алман илендәге һәм Европадагы солдат каберлекләренең җыелма каталогын бастырып чыгарырга уйлыйлар.

● 9 июньдә башкалабызның «Татарстан халыклары дуслыгы йорты»нда «Татары Казахстана» дигән китапны тәкъдим итү чарасы оештырылды. Әлеге чарада Татар энцеклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры, галим Искәндәр Гыйләҗев, Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррир урынбасары Марат Закир, проект авторлары, танылган татар галимнәре, институт хезмәткәрләре һәм журналистлар катнашты.

Казахстан татарлары хакындагы язмаларны www.beznenmiras.ru сайтыннан табып укый аласыз.

● 13 июньдә «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Л.Лерон белән Р.Сәгъди Мөслим муниципаль район хакимияте башлыгы Рамил Хәмзә улы Муллин белән очрашып, эшлекле сөйләшү үткәрде.

● 13 июньдә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон һәм журнал хезмәткәре, язучы Рәдиф Сәгъди Уфаның «Ихлас» мәчетендә Мөхәммәт хәзрәт Галләм белән очрашты.

● 14 июньдә Эстәрлебашның (Башкортстан) Үзәк китапханәсендә «Безнең мирас» журналы редакциясе хезмәткәрләре – язучылар Ләбиб Лерон һәм Рәдиф Сәгъди белән очрашу булды.

● 14 июньдә Туймазыда «Төмәнәк» татар иҗтимагый тарихи-мәдәни үзәгендә «Безнең мирас» журналы редакциясе китапханәчеләр һәм җирле каләм әһелләре белән очрашу уздырды. Чарада редакция хезмәткәрләре Ләбиб Лерон белән Рәдиф Сәгъди, җырчы Фән Вәлиәхмәтов, «Төмәнәк» татар иҗтимагый тарихи-мәдәни үзәге җитәкчесе Фәнир Галимов катнашты.

● 17-23 июнь көннәрендә Болгар музей-тыюлыгының палатка лагере биләмәсендә «Болгар – туган тел» дигән III Төбәкара лагере эшләде. Анда Татарстанның бөтен районнарыннан һәм Россиянең уннан артык төбәгеннән 750дән күбрәк бала һәм яшүсмерләр әйдаманы катнашты.

● 20 июньдә «Безнең мирас» журналы редакциясе хезмәткәрләре Л.Лерон белән Р.Сәгъди Мамадыш, Чаллы, Алабуга, Менделеевск шәһәрләре һәм Тукай районы хакимияте җитәкчеләре белән очрашты.

Шул ук көнне Менделеевский районы Камай авылында булып, басмабыз журналистлары мәшһүр җырчыбыз Вафирә Гыйззәтуллинага нисбәтле эшлекле сөйләшүдә катнашты. Авыл китапханәсендә сакланган ошбу фотода: Әлфия Афзалова һәм Вафирә Гыйззәтуллина. Узган гасырның сиксәненче еллары...

«ТАТАРНЫҢ ТЕЛЕ ОЗЫН...»

(«Яшен» журналыннан)

ҮЗСҮЗЛЕ СӘМРУГ КОШЫ

Беркөнне төшемдә сәмруг кошы күрдем. Аның илә гомуми эшләр тугрысында бик озак низаглаштык. Ул мине һаман җиңә килде. Ахырдан мин аңар иске мәкальләрне әйтә башладым. Ул мин әйткән иске мәкальләргә каршы һәммәсенә яңаларны әйтә бара иде.

– Җилгә каршы төкермә, үзеңә кайтыр, – дидем.
– Заманга каршы барма, таптап калдырыр, – диде.

– Җиде кат үлчә, бер кат кис, – дидем.
– Җиде кат шартла, бер кат газета нәшер итә башла, – диде.

– Хатыннарның гакылы кыска, чәче озын, – дидем.
– Татарның чәче кыска, теле озын, – диде.

– Өе биек, өйрәсе сыек, – дидем.
– Догасы бөек, эше сыек, – диде.

– Чуртанның үзе үлсә дә, теше үлмәс, – дидем.
– Татарның үзе үлсә дә, тәгассыбы[1] үлмәс, – диде.

– Ат азгыны тайга иярер, – дидем.
– Яшь азгыны картка иярер, – диде.

– Эт өрер, кәрван җөрер, – дидем.
– Чын татар өрер, яшьләр йөрер, – диде.

– Ашап-эчеп, кием киеп кенә кеше булып булмый, – дидем.
– Ак яка киеп, төнлә йөреп кенә интеллигент булып булмый, – диде.

– Эт этлеген итми калмас, – дидем.
– Печән базары хулиганы кеше артыннан өрми калмас, – диде.

– Эт корсагына сары май килешми, – дидем.
– Чи татар күзенә матур кием килешми, – диде.

– Этнең койрыгын кем киссә, шул яхшы, – дидем.
– «Чи татар»ны кем алдаса, шул тәкъва[2], – диде.

[1] Тәгассыб – фанатизм.

[2] Тәкъва – дин кушканны гына эшләүче, диндар.

Ике хатын берлә тормыш

Биек тауның
башыннан
Күренәдер бер
авыл,
Хатын өстенә хатын
алсаң,
Менә шулай була
ул.

Ялт-йолт. - 1910.
- №4. - Б.4.

– Коега төкермә, суын эчәрсең, – дидем.
– Байларны сүгә күрмә, газетага нашир кирәк булыр, – диде.

– Карт этнең теше урынына эче эшли, – дидем.
– Урыс бүрекле чи татарның башы урынына аяклары эшли, – диде.

– Ашыккан ашка пешәр, – дидем.
– Ашыкмаган хәзерге татар хәленә төшәр, – диде.

Яшен. – 1908. – № 2. – Б.7–10.

*Сәхифәне **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Башкалабыз Казандагы Мәгубә Сыртланова урамы

«Безнең мирас»
елъязмасы / июль

● 810 ел элек (1207)

Ойрат кабиләсе юлбашчысы Хотуга бәк Чыңгыз ханга үзенең буйсынуын белдерә һәм, хөрмәт билгесе итеп, аңа ак лачын бүләк итеп җибәрә.

● 640 ел элек (1377)

Алтын Урда ханы Туктамыш Идегәй морзаның атасы Балтычакның («Идегәй» дастанында аның исеме Котлыкыя) башын чаптыра. Идегәй белән Туктамыш арасында егерме елга сузылган аяусыз көрәш башлана.

● 465 ел элек (1552)

3 июльдә 150 меңлек урыс гаскәре Казан тарафына кузгала...

● 295 ел элек (1722)

28 июльдә Россиядә беренче төрки-татар басмасы – Петр Iнең 1722 елгы манифесты бастырып чыгарыла.

● 215 ел элек (1802)

22 июльдә филолог, шәркыятьче галим, Петербург Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы Мирза Мөхәммәтгали Касыйм улы Казимбәк (1802-1870) дөньяга килә.

● 105 ел элек (1912)

15 июльдә очучы, Советлар Союзы Герое Мәгубә Хөсәен кызы Сыртланова (1912-1971) дөньяга килә.

● 95 ел элек (1922)

Һади Такташ «Урман кызы» әсәрен яза.

● 90 ел элек (1927)

4 июльдә Казанда Татар мәдәнияте йорты ачыла.

● 75 ел элек (1942)

4 июльдә Төньяк-көнбатыш фронтта атнага ике тапкыр татар телендә «Ватан өчен» газетасы чыга башлый. Редакциядә Г.Разин (Гомәр Бәширов) һәм Мирсәй Әмир озак вакытлы иҗат командировкасында була.

● 25 ел элек (1992)

24 июльдә Әмирхан Еники Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән матбугатта хат алыша. ■

Мирасворд

Шагыйрь Мостафа …

Ерак басуда эшләүчеләрнең күчмә өе

Г.Тукайның 1912 елда язган шигыре

Садә, Бакиров

Үзбәк күмәче

Татар халык әкияте

«… җиле» романы (Фоат Садриев)

Татарстанның халык шагыйре

Алтын Урданың Көнбатыш олысы идарәчесе

Ау эте (диал.)

Алтын Урда каласы

Чулманның уң кушылдыгы

Нуруллин, Камский

Төркем, партия (иск.)

Бөек Болгар дәүләтенә нигез салган хан

Мишәр абзые

Әти-әнисез

Әләк (диал.)

Һәдия Дәүләтшина романы

Җир, урын, төбәк (иск.)

Албаниядә административ-территориаль берәмлек

Элеккеге Төркиядә өстен хокуклардан файдаланган җәяүле гаскәри

Басуда ашлык көлтәләреннән ясалган зур өем

Биектау районындагы авыл

Шумер-аккад мифологиясендә кояш Алласы

Сарык, кәҗә тиресеннән эшләнгән йомшак күн

Бронза гасырда Скандинавиядә тараган музыка коралы

Дон казагы, Степан Разинның көрәштәше

Хан хезмәтендәге хәрби, башлыча аксөяк нәсел вәкиле

Берәр эш өчен кирәкле әйберләр, приборлар, җиһазлар

Михаил Лермонтов поэмасы

Чыр - …

Иран каласы

Киемнең эчке ягына тегелгән тукыма

Фәнзаман Баттал туган авыл

Рөхсәт, фатиха, ризалык (иск.)

Шаян эчтәлекле кыска эстрада пьесасы

Сирәк (ант.)

Zn

Вак сырлары, кытыршылары булган тыгыз тукыма

Татар ханлыкларында олыс, өлкә идарәчеләре дәрәҗәсе

6 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: «Авыл», Хөсни, «Әҗәт», «Фикер», «Мазепа», Зариф, Ломе, полк, вогул,ияр, лива, иганә, «Ялав», АКМ, Мәлих, Рауза, Окс, Яхин, гөрзи, аеру, Ләйлә, донг.

Өстән аска: Фигаро, «Вөҗдан», как, примус, Литке, Гали, паллама, кинә, прайд, Вәли, зело, Хафизова, ирән, Амо, Яхъя, Сок, Регул, арчи, Исрафилов.

Рәис Габдулла төзеде.

СОДЕРЖАНИЕ. ИЮЛЬ 2017

Историческое наследие: «Семья крещённых татар в начале XIX века» Р.Исхаков; «Казанский сабантуй в год революции»; «Арслан богатырь» К.Акъегет; «Единственный святой кряшен» В.Кузнецов; «Страшные и неспокойные годы» И.Тагиров; «Память сибирских простор» Ф.Завгарова, Г.Сунгатов.

Религиозное наследие: «От Казани до Уфы» Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Кутадгу билик» («Благодатное знание») Ю.Баласагуни; «По следам великого наследия» Т.Гилазов.

Татарский мир: «Узел Шигирдан» Ф.Кутлу; «Любовь и верность» А.Закирзянов; «Полковник, писатель, скульптор» Л.Лерон.

Художественное наследие: «Певец, влюбленный в этот мир» А.Хакимова; «Гусли, пришедшие с невестками» Э.Каюмова.

Эхо войны: «Татарские военные разведчики» Р.Зарипов.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов» А.Тимергалин.

100 лет назад…: «Казанские вести» в газете «Кояш»: июль 1917 года.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. JULY 2017

Historic heritage: «The Baptized Tatar families at the beginning of the 19th century» by R.Iskhakov; «The Kazan Sabantuy in the year of revolution»; «Arslan hero» by K.Akyeget; «The only sacred Kryashen» by V.Kuznetsov; «The year full of fears and worries» by I.Tagirov; «The memory of the Siberian vastnesses» by F.Zavgarova, G.Sungatov.

Religious heritage: «From Kazan till Ufa» by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U.Balasaguni; «On the way of investigating the great heritage» by T.Gilazov.

Tatar world: «Shigirdan village's knot» by F.Kutlu; «Love and fidelity» by A.Zakirzyanov; «The colonel, writer, sculptor» by L.Leron.

Artistic heritage: «The singer fallen in love with the whole world» by A.Khakimova; «The gusli taken from daughter-in-laws» by E.Kayumova.

The echo of the war: «The Tatar military scouts» by R.Zaripov.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin.

100 years ago…: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: July of 1917».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

«Чатыр тау».
Тимкин Р.Л.
Киндер,
майлы буяу.
Азнакай.
1992 ел

Илдус Гыйләҗев

ЧАТЫР ТАУГА МЕНСӘМ...

Чатыр тауга менеп күз сирпесәм,
Офыкларым йөз кат киңәйде.
Гомер буе йөртәм күңелемдә
Шул ноктадан карап күргәнне.

Чатыр тауга менеп бер җырласам,
Ак каеннар калды шаулашып.
Киталмадым ташлап мин аларны,
Яшәгәндә хисләр аңлашып.

Чатыр тауга менеп бер сызгырсам,
Байбаклары җавап кайтарды.
Чит җирләрнең оҗмах-җәннәтенә
Алыштырмам туган якларны.

Казан 91.5 FM
Болгар
радиосы

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

ИНДЕКС:

ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*